# ШУРА

№16
2017




Дини альманах

1908 нче елдан бирле нәшер ителә

ЭЧТӘЛЕК

ВӘГАЗЬЛӘР
Дин гыйлеме хакында . . . . . 8
Мигъраҗ – күккә ашу кичәсе . . . . . 11
Ни өчен күрәзәчеләр кайвакыт дөрес сөйли? . . . . . 16
Шәгъбан аеның фазыйләтләре . . . . . 21
Сатып алынган авыру . . . . . 27
Каберләрне зиярәт итү . . . . . 30
Гыйбадәтләребез җәннәт белән сөендерер . . . . . 35
Аллаһы Тәгаләгә ышануның баскычлары . . . . . 42
Хакыйкый тәкъва . . . . . 47
Кадер кичәсе . . . . . 54
Дөнья һәм ахирәт өчен тырышу . . . . . 59
Ураза гаетенең хөтбәләре
Гарәпчәсе . . . . . 64
Кириллицага транслитерациясе . . . . . 65
Татарчага тәрҗемәсе . . . . . 67
Ураза гаете вәгазе . . . . . 69
Вакыф . . . . . 74
Зикер вә шөкер кылуның әһәмияте . . . . . 78
СОРАУ-ҖАВАП
Мордар китү гөнаһы . . . . . 86
ҮРНӘК ЗАТЛАР
Әбү Гобәйдә Әмир ибн Габдуллаһ . . . . . 91
Гали ишан Әт-Түнтәри . . . . . 96
Хикмәтле остаз – Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин . . . . . 100
МӨСЛИМӘ
Исламда килен белән каенана мөнәсәбәтләре . . . . . 107
МИРАС
Агиев Фәхрелислам Нигъмәтулла улы . . . . . 112
Нигъмәтулла хаҗи . . . . . 117
Ислам тарихы . . . . . 135
ФӘН
Хәнәфи мәзһәбе . . . . . 146
«Хизбүт-тәхрир әл-исләми» партиясе . . . . . 149
Бөек илһам иясе . . . . . 154
Хөсәен ибн Әмирхан – XIX йөзнең гыйлемле шәхесе . . . . . 161
Коръән турында гыйлем . . . . . 174
ТАРИХ
Дүрт ягым кыйбла: Арчаның тарихи халкына бер сәяхәт . . . . . 182
УРАЗА
Уразаның әһәмияте . . . . . 190
Тәравих намазы . . . . . 208

НӘСЫЙХӘТ
Җәмгыять аңында мораль принциплар үзгәрү процессы
«… мин аларга җирдәгесен бизәп күрсәтермен…» . . . . . . . . . . 214
ЙӘГЕЗ, БЕР ДОГА
Мигъраҗ кичәсе намазы . . . . . . . . . . 227
Бәраәт кичәсе намазы . . . . . . . . . . 227
Кадер кичәсе намазы . . . . . . . . . . 229
Җеназа намазын уку тәртибе . . . . . . . . . . 230
ӘДӘБИ СӘХИФӘ
А. С. Пушкин «Пәйгамбәр» . . . . . . . . . . 236
«Коръән аятьләренә охшатулар» . . . . . . . . . . 237
М. Акъегет «Хисаметдин мелла» . . . . . . . . . . 244

**«ШУРА» дини альманах, №16**

апрель – июнь 2017
раҗәб 1438 – шәүвәл 1438

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 нче елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420111 Казан, Лобачевский урамы, 6/27 нчы йорт

Бәясе ирекле
2013 нче елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
12+

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 264-64-19 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Нияз Сабиров
Илдус Фәиз
Фәрид Сәлман

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП:**
Лилия Ильясова
Телефон: +7 (843) 202-07-74

**ДИЗАЙНЕРЛАР:**
Рөстәм Даутов
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Раушан Сәйфетдияров

**ӘДӘБИ РЕДАКТОР:**
Рәмзилә Шафикова

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нчы йорт
Тел./факс: +7 (843) 202-07-74
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

Типографиянең адресы:
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы
420066, ТР, Казан ш., Декабристлар ур., 2.
Тел./факс: +7 (843) 519-91-10
E-mail: idelpress@mail.ru

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 20.03.2017
График буенча: 20.03.2017

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

# Вәгазьләр

**Бисмилләһир-рахманир рахим.**

**Әссәләәмүгаләйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәракәәтүһ, мөхтәрәм дин кардәшләребез!**

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән Ураза гаете белән котлыйм! Динебезгә хөрмәт күрсәткән татарстанлыларга үземнең ихлас рәхмәтемне белдерәм.

Һәр мөселман өчен Ураза гаете иң мөбарәк бәйрәмнәрнең берсе. Мөхәммәд Пәйгамбәр ﷺ үзенең бер хәдисендә әйткән: «Әгәр минем өммәтем кешеләре Рамазанның савабы ни дәрәҗәдә зур икәнен белсәләр, алар Рамазан аеның ел буе дәвам итүен теләр иделәр». Икенче бер хәдистә исә болай диелгән: «Аллаһ юлында бер көн дәвамында ураза тоткан бәндәсен Аллаһ 70 еллык юл озынлыгы вакытка уттан саклар».

Соңгы елларда ураза һава температурасы иң эссе булган җәйге айларга туры килә, ә көн озынлыгы 20 сәгатькә кадәр җитә. Аллаһка шөкер, бернинди киртәләр дә Рамазан ае уразасын өзмәде! Дин галимнәре әйткәнчә, чын мөселманга гыйбадәт кылу өчен елның һәр вакыты яхшы, ә ялкау кешегә сәбәп табылып тора ул.

Татарстан мөселманнары Ураза бәйрәмен шатланып каршы алалар, чөнки хәдисләрдән билгеле булганча: «Ураза тотучының ике шатлыгы булыр: ифтар шатлыгы һәм Аллаһы Тәгалә белән очрашу шатлыгы». Ураза тотучыларга догалары кабул булып, белеп һәм белмичә кылган гөнаһлардан арынырга язсын! Аллаһ Раббыбыз гыйбадәтләребезне кабуллардан кылсын иде!

Ислам традицияләре, башка дөньяви диннәр кебек үк, гаделлек, мәрхәмәтлелек, игелеклелек кебек мәңгелек кыйммәтләргә нигезләнгән. Ислам милләткә, дингә бүлмичә һәркемгә мәрхәмәтле булырга, мохтаҗларны кайгыртырга өйрәтә. Изге Рамазан дәвамында күзәтелгән

исламның шушы мәңгелек кыйммәтләренә омтылыш алга таба да һәр мөселманның төп максаты булсын.

Раббыбыз татарстанлыларга ике дөнья рәхәтен бирсен, барлык традицион конфессияләргә тыныч һәм килешеп яшәргә, гыйлем белән өммәтебезне ныгытырга ярдәм итсен! Әмин!

*Ихтирам һәм изге догалар белән*

*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы*

*мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,*

*мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин*

*14 нче апрель вәгазе,*

*Раҗәб аеның 17 нче көне, һиҗри исәп буенча 1438 нче ел*

# Дин гыйлеме хакында

Дин-мөбиндә мөхтәрәм газиз кардәшләрем, ватандашларым, милләттәшләрем! Аллаһы Раббыбызның бетмәс рәхмәт-бәрәкәтләре, һәр ике дөньядагы сәламе җөмләгезгә булса иде. Җомга кичәләрегез мөбарәк булсын.

Хәзрәти Ибне Габбас ﵁ тапшырган бер хәдис-шәриф аша расүлебез Мөхәммәднең ﷺ түбәндәге сүзләре безгә ирешкән: «Пәйгамбәребез ﷺ: «Әгәр җәннәт бакчалары яныннан үтсәгез, уҗымын чүпләгез!» – диде. Сәхабәләр: «Йә Расүлүллаһ! Дөньялыкта җәннәт бармыни? Нәрсә соң ул җәннәт бакчалары?» – дип үзеннән сорадылар. Расүлүллаһ Әкрам җәннәт бакчаларын «гыйлем мәҗлесләре» дип ачыклады».

Элек-электән халкыбыз гыйлемне, гыйлем ияләрен хөрмәтләп, гыйлем эстәүне таләп иткән. Шуңа күрә дин кимсетелгән, денсезлек дәрәҗәле булган авыр заманда да халык берничек гыйлемнән аерылып тормады. Бүгенге әби-бабаларыбыз Ходай рәхмәте белән репрессиядән, сөргеннән котылып калган хәзрәтләребездән «Әлхәм», «Колһүәллаһ», «Йәсин», «Тәбәрак» һ. б. өйрәнделәр.

Ибне Габбас ﵁ сөйләгән хәдис-шәрифтә Пәйгамбәребез ﷺ: «Бәрәкәт олыларыгыз белән булыр», – дигән. Бәрәкәт кылган гамәлләрдә, ризыкта, берәр изге урында гына түгелдер. Халкыбыз һәрвакыт әүлияләрне, изгеләрне дәрәҗәләгән. Ул әүлияләрнең, изгеләрнең, олыларның яшьрәк буыннарга тапшырып калдырган гыйлемнәрендә дә олы бәрәкәт булган. Расүлүллаһ ﷺ: «Кем дә кем олы яшьтәгене хөрмәтләмәсә, кечкенәләрне җәлләмәсә, игелеккә өндәмәсә, инкарь ителгәннән тыелмаса – безләрдән булмас», – дип кисәткән була. Бу хәдистән олыларны хөрмәтләүнең иман төркемнәреннән берсе булуы күренә. Олылар-

ны хөрмәтләү – аларның гыйлемен дә хөрмәтләүдер. Локман ﷺ углын вәгазьләп: «Галимнәр мәҗлесенә бар, хикмәтле сүз сөйләүчеләрне тыңла! Аллаһы Тәгалә үлеп беткән калебне, нәкъ коргаксыган җирне мул яңгыр терелткән шикелле, хикмәт-гыйлем нуры белән терелтеп җибәрер», – дигән. Әхмәд-Зәки, Вафа хәзрәтләрнең вәгазьләре күпме юкка чыккан калебләрне терелткәннәр. Кизләү, Баллыкүлдәге ишаннарның бәрәкәте, гыйлемнәре, гыйлемнәренең бәрәкәтләре шулай буыннан-буынга тапшырып калдырылган... Бүген дә гыйлемне өйрәнәләр, өйрәтәләр. Тик нурлы йөзләр, чын гыйлем ияләре юк диярлек. Олылар фани дөньядан китеп баралар, яшь буынның гыйлеме – буш гыйлем генә. Бай мирасыбызга, олы хәзрәтләребезнең хезмәтләренә игътибар бирмичә, әллә кайдан килеп чыккан «мөгаллимнәргә» хәйран калып, гыйлем эстәүче белемнән мәхрүм булып кала. Гарәп телен дә өйрәнәләр, кадимчә дә, җәдидчә дә укыйлар, вәгазь дә сөйлиләр – тик тыңларлык нәрсә генә юк. Буш сүзләр, күңелгә үтмәс вәгазь файда урынына зарар гына китерә. Ни өчен? Гыйлем өйрәнүнең нияте нинди булган икән? Кем дә кем гыйлемне Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен түгел, ә дөнья малы белән кәсеп итү өчен өйрәнсә, Расүл Әгъзам: «Алар Кыямәт көнендә җәннәт күрмәс», – дип кисәткән. Мәдрәсәгә кемдер солдат хезмәтеннән калыр өчен, кемдер ата-анасының таләбе буенча, кемдер кызык өчен генә укырга кергән була. Кыямәт көнендә бер төрле төркем булыр, алар «гыйлем ияләре» булыр, ди. Берсеннән: «Нәрсә өчен укыдың, укыттың?» – дип сорагач, ул: «Гыйлем өйрәнеп, башкаларга да өйрәттем, Синең ризалыгыңны өмет итеп, Коръән укыдым», – диячәк. «Юк! Сүзең ялган! Гыйлем өйрәндең – үзеңә галим дип әйтсеннәр өчен генә, Коръәнне укыдың – үзеңә Коръән укучы дип әйтсеннәр өчен генә...» – диеп, ул риячыны, дин белән кәсеп итүчене бите белән җир өстеннән өстерәп китәрләр һәм җәһәннәмгә ташларлар...

Ләкин бөтен кеше дә гыйлемне дөньялык өчен өйрәнмәс. Аллаһы Тәгалә Үзе Кәләм-Шәрифендә: «Галим булучылар, чын гыйлем ияләре

Үземнән куркырлар», – дигән. Пәйгамбәребез ﷺ: «Миннән берәр аять, сүз ишетсәгез, аны башкаларга (ишетмәгәннәргә) җиткерегез!» – дип васыять кылган. «Мин сезгә юмартларның иң юмарты турында хәбәр биримме? Юмартларның иң юмарты – Аллаһы Тәгаләдер. Кешеләр арасында исә иң юмарты – миндер. Миннән соң исә иң юмарты гыйлем өйрәнеп башкаларга өйрәтүче кеше булыр», – дип, кемнең кем булуын ачыклаган. Әйе, чын ихлас белән гыйлем өйрәнеп, башкаларга да өйрәткән мөселман юмартлардан булыр. «Кеше гыйлем таратудан да артыграк сәдака тарат-мас», – ди Расүл Әс-Сәкаләйн ﷺ.

Менә шулай, бер яктан, уҗым чүпләүчеләр булыгыз, дип өндәгән Пәйгамбәребез ﷺ, икенче яктан, өйрәнгәнне таратырга да кушкан. Берәү Расүлуллаһ ﷺ янына килеп, нәрсәдер сораган була. Расүлуллаһ: «Син сораган нәрсә миндә юк, ләкин фәләнгә барсаң, сораганыңны табарсың», – дип, сораучыга юл күрсәтә. Шуннан: «Кем бер игелеккә дәлил (күрсәтүче) булса, шул нәкъ әлеге игелекне эшләгән кеше шикелле әҗерле булыр», – ди. Шулай, һәр иман әһеле дөньялыктагы җәннәт бакчаларыннан гыйлем уҗымын чүпләп йөрергә тиештер. Олылардан алган гыйлемнең кадерен белеп, бәрәкәтеннән файдаланып, олы мирасыбызны киләсе буыннарга да тапшырып калдырсак, сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Әл-Мостафа ﷺ васыятьләрен үтәүчеләрдән булырбыз. Кем исә Пәйгамбәрне ﷺ якын күрсә, аны Аллаһы Тәгалә якын күргән булыр. Аллаһы Тәгаләне якын күрүче исә дөнья-ахирәт бәхетенә ирешер.

*Фәрид хәзрәт Сәлман,*
*Изге Коръән вә Пакь Сөннәт*
*өйрәнү үзәге мөдире*

*21 нче апрель вәгазе,*

*Раҗәб аеның 24 нче көне, һиҗри исәп буенча 1438 нче ел*

# Мигъраҗ – күккә ашу кичәсе

Аллаһы Тәгалә олуг нигъмәте Коръәни Кәримендә Мөхәммәд Пәйгамбәрнең ﷺ күккә ашуы – мигъраҗы – турында болай әйтә:

سُبْحَانَ الَّذِي أَسْرَىٰ بِعَبْدِهِ لَيْلًا مِّنَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ إِلَى الْمَسْجِدِ الْأَقْصَى الَّذِي
بَارَكْنَا حَوْلَهُ لِنُرِيَهُ مِنْ آيَاتِنَا ۚ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ ﴿١﴾

**«Үзенең колы Мөхәммәдне бер кичтә Мәккә шәһәрендәге мәсҗид Хәрамнан Коддус шәһәрендәге мәсҗид Әкъсага кайтаручы Аллаһы Тәгаләне һәр кимчелектән пакь дип белегез! Без Коддус шәһәренең тирәсен бәрәкәтле кылдык, Мөхәммәдне шулай кодрәтебез белән йөрттек, гаҗәп галәмәтләребезне күрсәтер өчен, әлбәттә, Аллаһ һәр сүзне Ишетүче вә һәр нәрсәне Күрүчедер».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:1

Раҗәб аеның 26 нчы көненнән 27 нчесенә каршы кич – Мигъраҗ кичәсе. Нинди кичә ул? Ни өчен бу бәйрәмне 2 миллиардка якын мөселман кардәшләребез шатланып, дулкынланып каршы ала? Мигъраҗ – ул «күккә ашу» дигән мәгънәне аңлата һәм Мөхәммәднең ﷺ тормышында бу төнге сәфәр (исра) иң олуг могҗиза булып исәпләнә. Пәйгамбәрлекнең 10 нчы елында Мөхәммәдне ﷺ тәрбияләп үстергән агасы Әбү Талиб үлеп китә, аңа таяныч булган хатыны Хәдичә (رضي الله عنها) вафат була, һәм шуннан соң да Мөхәммәдкә ﷺ бик күп авырлыклар күрергә туры килә. Мөхәммәднең ﷺ бу елы бик авыр була. 621 нче елда бер төнне Мөхәммәд ﷺ ястү намазыннан соң Кәгъбәдә гыйбадәт кылган вакытта Җәбраил фәрештә Бурак

дигән ат белән килеп (ул оча торган җан иясе), аңа әйткән: «Әй Мөхәммәд, Аллаһ Тәгалә беркемгә насыйп итмәгән шәрәфне сиңа насыйп итте. Сине янына чакыра», – дигән. Һәм канатлы тылсымлы атка атландырып, күз ачып йомганчы Гарәбстаннан изге Коддус (Иерусалим) шәһәренә яшен тизлегендә китереп җиткергән[1]. Моңа әүвәл, әлбәттә, акыл белән ышанып булмый, фәкать иман белән генә ышанылыр иде, ләкин бүген зәгыйфь адәм балалары уйлап тапкан ракеталар да бу араны 5 минутта үтәләр!

Әл-Әкъсага җыелган барлык пәйгамбәрләр Мөхәммәдкә ﷺ оеп намаз укыйлар. Соңрак Җәбраил Мөхәммәднең ﷺ алдына 3 савыт китереп куя. Берсенә – су, икенчесенә – сөт, өченчесенә – хәмер салынган була. Мөхәммәд ﷺ сөт салынган савытны ала, фәрештә: «Әй Мөхәммәд, син вә өммәтең дөрес юлда! Исерткеч эчү хәрам», – дип кычкырып җибәрә. Шул мизгелдә күктән яктылык баскычы төшерелә һәм бу баскычтан Мөхәммәд ﷺ вә фәрештә күккә күтәрелә. Мөхәммәд ﷺ 7 кат күк ишеге аша үткәндә һәр капуста үзенә кадәр җир йөзенә килеп киткән пәйгамбәрләр белән очраша. Күкнең 1 нче капусы ачыла, күрәләр: алар алдында атабыз Адәм ﷺ – сәлам бирешәләр. Адәм уңга карый да, елмая, шатлана, чөнки уңдагылар – изгеләр, тәкъвалар, әүлияләр. Сулга карый да, өзелеп-өзелеп елый, кайгыра. Сулдагылар – залимнәр, кәферләр, гөнаһлылар. Күкнең 2 нче катында Гайсә вә Яхъя عليه السلام белән күрешеп бер-беренә изге теләкләр әйтәләр. Күкнең 3 нче катында тулган ай кебек күркәм Йосыф عليه السلام белән сәлам алышалар. 4 нче кат күктә Идрис عليه السلام белән күрешәләр. Күкнең 5 нче катында Мусаның عليه السلام ир туганы Һарун пәйгамбәр عليه السلام белән очрашалар. Күкнең 6 нчы катында Муса عليه السلام белән күрешәләр, үзе намаз укый, үзе елый – өммәтендәге Бәни Исраил кавемендә иманнарына гөнаһ катыштырган бәндәләр өчен Аллаһ Тәгаләдән гафу үтенә. Күкнең 7 нче катында Әл-бәйтел мәгънур бинасына аркасы белән сөялеп утырган Ибраһим عليه السلام белән сәламләшәләр. Мөхәммәд

[1] Имам Мөслим җыентыгы, 429 нчы хәдис

ﷺ бу мөкатдәс бина тирәли 70 мең фәрештә тәваф кылганын күрә, алар һәр көн яңарып торалар.

Җәбраил ﷷ күкнең иң өске катына җиткәч, миңа тагын да үтәргә рөхсәт юк, ди. Мөхәммәд ﷺ Аллаһ Тәгаләгә бихисап күп пәрдәләр аша якынаюын сизә, бик тә курыккан хәлдә сәҗдәгә китә, Аллаһ Раббымызга мактаулар укый. Шул мизгелдә Аллаһыдан вәхи килә. Мөхәммәд ﷺ Аллаһ Тәгаләгә: «Әт-тәхиятү лиЛәһи вәссәләвәтү вәт-таибәт», ягъни «тел гыйбадәтләре, тән гыйбадәтләре, мал гыйбадәтләре – һәрбарчасы да Аллаһ Тәгалә өчен», – дип хәмед әйтә. Аллаһ Тәгалә бераздан: «Әс-сәләмү галәйкә әййүхән-нәбиү вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү», – дип җавап бирде, ягъни «әй пәйгамбәребез, сиңа Аллаһ Раббыңның сәламе, рәхмәте вә бәрәкәте булсын», – диде. Моңа каршы Мөхәммәд ﷺ: «Әс-сәләму галәйнә вә галә гибәдил-ләһис-салихиин», ягъни «сәлам безгә дә һәм Аллаһ Тәгаләнең һәрбер изге бәндәсенә булсын», – диде. Шуннан соң фәрештәләр: «Әшһәдү әллә иләәһә илләллааһ вә әшһәдү әннә мүхәммәдән габдүһү вә расүлүһ», ягъни «шәһадәт бирәбез Аллаһ Тәгалә барлыгына вә берлегенә, Мөхәммәд ﷺ Аллаһының расүле вә илчесе икәнлегенә», – диделәр.

Намазларда укыла торган дога нәкъ менә Аллаһ Тәгалә белән Мөхәммәднең ﷺ кара-каршы сөйләшүеннән чыккан дога. Кайбер галимнәр әйтәләр: «Аллаһ Тәгалә белән Мөхәммәднең ﷺ сөйләшү вакытында 99 мең сүз әйтелгән», – диләр. Мөхәммәд ﷺ бу төнге сәфәрендә җәннәт вә җәһәннәмне үз күзләре белән, җаны, тәне вә гакылы белән күрә. Җәһәннәмнең җитәкчесе Мәликнең йөзендә ул елмаю әсәрен күрми. Анда Мөхәммәд ﷺ дөньяда исерткеч эчеп йөрүчеләрнең үлек канын эчүләрен күрә. Ятим хакын ашаучыларның утта янган ташларны авызларына тутырганын күрә. Гайбәт, сүз йөртүчеләрнең утта кыздырылган кайчылар белән ирен, авызларын кискәннәрен күрә. Мөхәммәд ﷺ өммәте өчен Аллаһыдан гафу сораган һәм мигъраҗ теләгән. Аллаһ Тәгалә мөэминнәрнең мигъраҗы намаздыр, дигән. «Өммәтеңә 50 вакыт намазны фарыз итәм», – дигән

Аллаһ Тәгалә. Кайтканда Мөхәммәдкә ﷺ Муса ؑ очрады һәм киңәш биреп, өммәтең 50 вакыт намаз укый алмас, Аллаһыга кайт, киметүне сора, диде. Мөхәммәд ﷺ 9 тапкыр Аллаһ хозурына барып, намазны әзәйтүне сорады һәм Аллаһ Тәгалә 50 вакыт намазны җиңеләйтеп, 5 вакытка гына калдырды. Муса ؑ тагын сора дигән, өммәтең 5 вакыт намазны үти алмас, дигән. Мөхәммәд ﷺ: «Юк, тагын Аллаһ каршына кайтырга оялам», – дия. Шул вакытта Аллаһ Тәгалә: «Бәндә 1 изгелек кылса, 10 изгелек кылган шикелле әҗер алыр», – дигән фәрман бирде. Ягъни 5 вакыт намаз вакытында үтәлсә – 50 вакыт укылган кебек әҗере булыр. Бу кичәдә Мөхәммәдкә ﷺ 3 бүләк булды:

1. Мөхәммәдкә ﷺ Кыямәт көнендә өммәтен яклау хокукы бирелде (шәфәгать);
2. «Бәкара» сүрәсенең ахырына 2 аять өстәлде (285, 286 аятьләр);
3. 5 вакыт намаз бурыч булып йөкләнелде.

Аллаһының хакын үтәмәгән 1 кеше 60 яшендә ничә көн яшәгәнен санап чыккан – 21 мең 500 көн яшәгән. 21 мең 500 не тапкырлаган 5 кә (5 намаз), ягъни 100 меңнән артык намазы калган. Уйлый-уйлый, шуның кадәр югалтуны мин каплый алмыйм, дип кайгырып, бу ихлас күңелдән тәүбә итә дә, мәет була. Аллаһ Тәгалә бәндәнең ихластан үзенең тормышына хисап кылганы өчен 60 еллык гөнаһысын кичерә. Безгә бу бик зур гыйбрәт. Без дә үткән тормышыбызны кайтара алмыйбыз, һәркөнне үзебезгә хисап кылыйк: бүген көнем намазда үттеме? Йоклар алдыннан үзебезгә хисап кылыйк: мин хәзер йоклыйм, кайда уянам? Ярый ястыгында уянсаң, әле бит башка урында уянуыбыз мөмкин! Кабердә уянсак, гөнаһыбызга тәүбә итмәгән, намаз үтәлмәгән, мәңгелеккә нинди гамәлләр белән барабыз? Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә Үзенең сөекле китабы Корьәни Кәримдә әйтте:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ حَقَّ تُقَاتِهِ وَلَا تَمُوتُنَّ إِلَّا وَأَنتُم مُّسْلِمُونَ ﴿١٠٢﴾

**«Әй мөэминнәр, Аллаһыдан каты куркыгыз, Аның хөкемнәрен бозудан бик нык сакланыгыз, чын мөселман хәлегездә генә үлегез».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:102

Әле вакыт бар, дип, хакыйкатьне пенсиягә кадәр этәреп түгел, гомеребез, сәламәтлегебез, акылыбыз бар икән, намазның дога-сүрәләрен өйрәнеп, 5 вакыт намаз укучылардан булып дөньядан үтик.

Чынбарлыкта гыйльми ачышлар хак булган кебек, Ислам дине дә хак, хаклык белән хаклык һичбер вакытта да каршы килми, киресенчә, берберсен баета гына, шуңа күрә бүгенге көндә космоска очулар, Коръәндәге фәнни ачышлар – һәммәсе дә хак булып, Коръәни-Кәрим китабының Аллаһыдан икәнен генә исбатлый. Космосны да, Аллаһ Тәгалә Мигъраҗ кыйссасында зикерләп, Үзенең аятеннән (билгесеннән) икәнен аңлатты («Фүссиләт» сүрәсе, 53 аять). Бу могҗиза түгелме? Галәмгә очу хакында Коръәндә 1400 ел элек язылган. Аллаһ Тәгалә моны үзе Мөхәммәд ﷺ мисалында могҗиза рәвешендә исбат итте. Расүлебезне космоска чыгарды – киләчәк буынга динебезнең дөрес гыйлем икәнен күреп иманнарын куәтләргә дәлил итеп калдырды. Аллаһ Тәгалә Үзенең Китабында әйтте:

قُلْ أَرَأَيْتُمْ إِن كَانَ مِنْ عِندِ اللَّهِ ثُمَّ كَفَرْتُم بِهِ مَنْ أَضَلُّ مِمَّنْ هُوَ فِي شِقَاقٍ بَعِيدٍ ﴿٥٢﴾

**«Беләсезме, Коръән Аллаһыдан иңдерелгән булып та, соңра сез Коръәнгә иман китермәсәгез, миңа хәбәр бирегез, сукыр вә аңардан ерак булган кешедән дә адашканрак вә азгынрак кеше бармы?»**

«Фүссиләт / Аңлатылды», 41:52

*Рөстәм хәзрәт Хәйбуллин,*

*Буа районы «Мәлик» мәчете имам-хатыйбы*

*28 нче апрель вәгазе,*

*Шәгъбан аеның 2 нче көне, һиҗри исәп буенча 1438 нче ел*

## Ни өчен күрәзәчеләр кайвакыт дөрес сөйли?

Бөтен галәмне юктан бар кылып, тәрбия кылучы Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгаләгә хәмде-сәнәләребез булса иде. Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә илләребезгә һәм көннәребезгә хәерле иминлек, тынычлык, авыруларга хәерле шифалар, тәүфыйксызлыкта, намазсызлыкта, динсезлектә йөрүчеләргә Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә тәүфыйк-һидият (туры юлга керүчеләргә хас сыйфатлар: күркәм әдәп-тәрбия, яхшы әхлак), истикамәтләр (турылык, намуслылык, дөрес юнәлеш) насыйп кылса иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафага ﷺ күңелләребезнең түреннән чыккан салават-шәрифләребез, догаларыбыз ирешсә иде.

Мөхтәрәм газиз кардәшләрем, җомга көннәребез мөбарәк булсын! Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә ике җомга арасында вафат булган мөселман кардәшләребезнең рухларына догаларыбызны ирештерсен иде. Ике җомга арасында никахлашкан яшьләребезнең Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә күңелләренә өлфәт-мәхәббәт салып, мәхәббәтләрен дәвамлы кылып, алардан туган балаларны да Ватаныбызга, динебезгә, милләтебезгә игелекле, файдалы балалар насыйп кылса иде.

Бүген киләчәген белергә теләп, алдагы көннәрендә нәрсә көтәчәге белән кызыксынып күрәзәчеләргә мөрәҗәгать итүчеләр еш очрый. Алар шул фаразлауларга ышанып, күрәзәче әйткән, булачак дигән вакыйганы, сәгатьне көтеп яши. Ләкин эш шунда: кемдер ул сәгатьне түземсезлек белән көтә, кемдер калтырап. Чөнки еш кына ул күрәзәчеләр кешегә үлем вакыты якынлашканын әйтеп, йөрәкләренә хафа салып, өйләренә кайтарып җибәрәләр. Җитмәсә, «сөенечле хәбәр» өчен каерып акча да алып калалар. Ә бер танышым кызык кына хәлгә очраган. Монда күрәзәче аны түгел, ә ул үзе күрәзәчене урынына утырткан. Барган да: «Озак яшисем

калдымы әле?» – дип сораган. Бөтен дөнья серләрен үзендә саклаган кеше кебек, тегесе: «Нәкъ утыз яшеңне тутыргач үлем көтә сине», – дигән. Ә танышым бер дә аптырап тормыйча: «Ялганламагыз, миңа инде 32», – дип җавап кайтарган. Менә шулай да була икән. Әмма һәр очрак та әлеге кебек шаярып искә алу белән генә төгәлләнсә иде. Кайбер хорафатларга ышанучылар күрәзәче әйткәннәргә ышанып, авыруга сабыша, борчылып, төн йокыларын калдыралар. Бу килгәнемдә юньлерәк хәбәр ишетмәмме икән, дия-дия актык акчаларын җыеп, янә күрәзәчеләренә ашыгалар. Әйе, күрәзәчеләргә йөрүнең иң зур минусы еш кына борчу-сагышка төшү булса, икенчесе – кесә ягына кырын сугуы. Чөнки аларга йөрүчеләр, гадәттә, уртача хезмәт хакын 2-3 сеанста бетереп чыгарга мөмкин. Кайберәүләр югалган якыннарын, кыйммәтле әйберләрен күрәзәчеләрдән «таптыра-таптыра», соңгы акчаларын да аларга илтеп тапшырырга мәҗбүр була.

Болар гади күзгә ташланган иң зур кимчелекләр. Ә менә Ислам динебез күрәзәчеләргә ничек карый соң? Алар хакында диндә нинди мәгълүматлар бар? Һәм күрәзәчелек итү диндә ничек аңлатыла? Нигә еш кына күрәзәчеләр дөресен сөйли?

Бу сорауларга җавап табар өчен без Аллаһ китабы Коръән һәм Пәйгамбәребезнең сөннәтенә мөрәҗәгать итик:

– Күрәзәчелек диндә катгый тәнкыйтьләнә. Кеше үзенең киләчәген берничек тә белә алмый. Аңа бары үткәне генә билгеле. Алдагы тормышында аңа нәрсәләр күрергә язганын да бары Аллаһ Үзе генә билгели. Бәлки ул кеше гомере буе бәхетле яшәр, әллә нинди авыр сынаулар узмас. Ә бәлки сынау арты сынау килеп, аның тормышын үзгәртер. Әмма ничек кенә булмасын, кеше үзендә көч табып, барлык сынауларны да җиңеп чыгарга тиеш. Ләкин, кызганычка, күпләр кызыксынудан гына да түгел, хәтта ярдәм өчен дә күрәзәчеләргә чаба. Ләкин ни хикмәт, кайвакыт алар да дөресен әйткән кебек тоела. Әмма бу күз буяу гына. Күрәзәчеләрнең

үз серләре бар. Һәм, бер яктан караганда, ул бик гади. Коръәни Кәримнең «Җен» сүрәсендә моның хакында әйтелә:

وَأَنَّا لَمَسْنَا السَّمَاءَ فَوَجَدْنَاهَا مُلِئَتْ حَرَسًا شَدِيدًا وَشُهُبًا ﴿٨﴾ وَأَنَّا كُنَّا نَقْعُدُ مِنْهَا مَقَاعِدَ لِلسَّمْعِ ۖ فَمَن يَسْتَمِعِ الْآنَ يَجِدْ لَهُ شِهَابًا رَّصَدًا ﴿٩﴾

**«...Без күккә менәргә тырыштык. Ләкин анда фәрештәләр гаскәренә юлыктык. Без бүгенге көнгә хәтле күктәгеләрнең хәбәрен ишетер өчен, шунда көтеп утырдык. Әмма хәзер тыңлап торырга теләүченең һәрберсенә атылучы йолдыз бәрелеп аны юк итәчәк...»**

«Җиннун / Җен», 72:8-9

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ җир йөзенә расүл итеп җибәрелгәнче, барлык җеннәр дә күккә менеп, фәрештәләрнең ни сөйләгәннәрен тыңлап торып, ишеткәннәрен күрәзәчеләргә җиткерәләр иде. Ә күрәзәчеләр исә, үз чиратларында, моны кешеләргә тапшырып «хак сөйләүчеләр», «барысын да аңлаучы хикмәт ияләре» булып калалар. Әмма бу ялгыш фикер. Кеше өчен киләчәкне алдан белү, язмышларны белеп сөйләү мөмкин хәл түгел. Моңа бик нык ярдәмчеләр, арадашчылар булышкан очракта гына ирешеп була. Алар – җеннәр. Ләкин Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ килү белән, җеннәр йолдызлар белән атып төшерелә торган булды. Безнеңчә «йолдыз атылу» да ул нәкъ менә фәрештәләрне тыңлау нияте белән күккә күтәрелгән җеннәрнең куылуы икән.

Ләкин серләрне чишүнең башка юллары да бар. Әйтик, күрәзәчегә килгән кеше үзенең берәр югалган әйберен табарга тели. Шунда җеннәр ярдәмгә килә дә. Алар бөтен мәгълүматны табып, туплап, хуҗаларына – күрәзәчеләргә – җиткерә. Күрәзәче исә барысын да үзе белгән кеше сыман, әлеге кешегә хәбәр итә. Ләкин бу, әлбәттә, хәрам юл. Дин күрәзәчеләргә, экстрасенсларга, сихерчеләргә баруны тыя. Чөнки үзенең киләчәген

белергә теләп килгән кешеләргә еш кына күрәзәчеләр бик тә күңелсез хәлләр дә җиткерергә мөмкин. Мәсәлән, бер айдан юл һәлакәтенә очрауны. Яисә берәр якынын югалтуны. Шуңа да Аллаһ безгә боларның барысын да сер итеп, без белә алмый торган әйберләр итеп куйган. Әгәр дә адәм баласы үзенең кайсы елда, кайсы көндә, ничек итеп үләсен белеп гомер итсә, ул яши дә алмас иде. Һәр үткән көн, узган минутлар аның газабын тагы да арттырыр иде. Бәлки ул үлем якынлашканын белгәнгә күрә генә, соңгы елларында гына дөньялыгын онытып, намазга басар, дингә кереп китәр иде. Ләкин Аллаһ алай булуын теләмәгән. Ул безгә Үзенең әмерләрен изге Коръәнебездә әйтеп, Пәйгамбәрбезнең ﷺ сөннәтләрендә билгеләп калдырган. Бу дөньяда безне нәрсә көткәне билгеле түгел. Кайчан үләсебезне дә, гомеребезнең ничек төгәлләнәчәген дә белмибез. Әмма Аллаһ безгә кушканча яшәсәк, ни булачагы һәм Аңа каршы барсак, безне ни көтәчәге ачык билгеле. Калганын Аллаһ Үзе генә белә. Бернинди күрәзәчеләр дә безгә нәрсә кылып бәхетле булачагыбызны һәм нәрсә аркасында бәлагә юлыгачагыбызны әйтә алмый.

إِنَّ اللَّهَ عِندَهُ عِلْمُ السَّاعَةِ وَيُنَزِّلُ الْغَيْثَ وَيَعْلَمُ مَا فِي الْأَرْحَامِ ۖ وَمَا تَدْرِي نَفْسٌ مَّاذَا تَكْسِبُ غَدًا ۖ وَمَا تَدْرِي نَفْسٌ بِأَيِّ أَرْضٍ تَمُوتُ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ ﴿٣٤﴾

**«Хакыйкатьтә, сәгать турындагы гыйлем – Аллаһта. Ул яңгыр яудыра һәм карыннарда булганнарны белә, һичбер җан иясе иртәгә нәрсә кәсеп кылачагын белмәс, һәм һичбер җан да нинди җирдә үләчәген белми. Хакыйкатьтә, Аллаһ – белүче, хәбәрдар!»**

«Локман», 31:34

Дөрес, кайвакытларда, кешедә күз тию, бозым эләктерү очраклары булганда, өшкерүче кешеләргә мөрәҗәгать итәләр. Алар кешенең кинәттән генә хәлсезләнеп китүенең һәм кайбер очракларда хәтта гаиләдә тыныч-

сызлык күзәтелүенең серләрен әйтергә, ягъни бик нык күз тидерүләрен яки бозымга очраган булуларын кисәтергә мөмкин. Алар әлеге кешеләргә ярдәм итә. Үзләренә ешрак килергә, үз-үзләрен саклар өчен тәһарәтле йөрергә, дөрес яши башлар өчен һәм башка бәлаләргә юлыкмас өчен Аллаһка якынаеп, намазга басарга өнди. Һәм ярдәм күрсәтүләре дә – Коръән аятьләре, Аллаһ сүзләре белән кешене дәвалау гына. Яисә суга Коръәннән аятьләр, сүрәләр укып, авырган кешегә шул суны эчерү. Төрле зәхмәтләрдән, күз тиюләрдән саклый торган «Аятел Көрси», «Ихлас», «Фәләкъ», «Нәс» сүрәләрен уку, һәм әлеге кеше терелсен өчен Аллаһтан ярдәм сорау. Аның гөнаһларын гафу итүне сорау. Чөнки кайвакытларда кеше үзенең гөнаһлары аркасында да әлеге хәлгә төшәргә мөмкин. Аллаһ сүзләре белән дәвалаучылар шәмнәр кабызып, әллә нинди ташлар кулланмый. Үзләренә килгән кешеләрдән фотосурәтләр, чәч-тырнаклар да сорамый. Өшкерүче кеше газета битләренә игъланнар биреп, телефон номерларын да таратып йөрми. Алар бары иң хәерле һәм нәтиҗәле булган, ә иң мөһиме – рухи сәламәтләнү биргән юллар белән генә дәвалый.

Аллаһы Тәгалә әйткән:

وَنُنَزِّلُ مِنَ الْقُرْآنِ مَا هُوَ شِفَاءٌ وَرَحْمَةٌ لِّلْمُؤْمِنِينَ ۙ وَلَا يَزِيدُ الظَّالِمِينَ إِلَّا خَسَارًا ﴿٨٢﴾

**«Без мөэминнәрнең күңелләренә шифалы аятьләрне вә Коръәннән рәхмәтле хөкемнәрне иңдерәбез».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:82

Аллаһы Тәгалә шушы сөйләгәннәребез белән гамәл кылырга язса иде!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*

*«Галиев» мәчете имам-хатыйбы*

*5 нче май вәгазе,*

*Шәгъбан аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1438 нче ел*

# Шәгъбан аеның фазыйләтләре

Без, кешеләрне, акыл нигъмәте белән баетып, барча мәхлуклардан өстен иткән Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләгә мактауларыбыз һәм шөкраналарыбыз булса иде. Безгә бу һәм киләсе дөньяда да бәхетле булырга, хакыйкатьне ялганнан аерырга өйрәткән, барчабызга күркәм үрнәк булган сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафага ﷺ, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Газиз дин кардәшләрем! Әссәләәмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәракәәтүһ! Изге шәгъбан аеның җомгасы барчаларыбызга мөбарәк һәм хәерле булсын!

Шәгъбан аеның фазыйләтләре турында сөйләгәнче, Ислам тарихында иң мөһим вакыйгаларның берсе булган «Тәһвилүл кыйбла», ягъни кыйбланың үзгәртелүе турында искә төшерәсем килә.

Бу вакыйга шәгъбан аеның 15 нче көнендә (быел 15 нче шәгъбан 10–11 майга туры килә) Мәдинәи Мөнәүвәрәнең «Бәни Сәләмә» мәчетендә булган. Расүлуллаһ ﷺ өйлә намазы фарызының беренче ике рәкәгатен укыганда вәхи иңгән, намазда торган хәлләрендә Кәгъбә тарафына борылганнар. Бу халәтне күргән сәхабәләр дә аңа ияреп намазны дәвам иткәннәр. Моңа кадәр намазны алар Кудс (Иерусалим) шәһәрендәге әл-Әкса мәчетенә карап укыганнар.

Бу турыда Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

قَدْ نَرَىٰ تَقَلُّبَ وَجْهِكَ فِي السَّمَاءِ ۖ فَلَنُوَلِّيَنَّكَ قِبْلَةً تَرْضَاهَا ۚ فَوَلِّ وَجْهَكَ

شَطْرَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ ۚ وَحَيْثُ مَا كُنتُمْ فَوَلُّوا وُجُوهَكُمْ شَطْرَهُ ۗ وَإِنَّ الَّذِينَ أُوتُوا الْكِتَابَ لَيَعْلَمُونَ أَنَّهُ الْحَقُّ مِن رَّبِّهِمْ ۗ وَمَا اللَّهُ بِغَافِلٍ عَمَّا يَعْمَلُونَ ﴿١٤٤﴾

**«(Ий, Мөхәммәд) чыннан да, Без синең күккә карап торганыңны (хәбәр көткәнеңне) күрәбез. Хәзер Без Кыйбланы син бик тә риза булган тарафка күчерәбез. Йөзеңне изге мәчет (Кәгъбәтуллаһ) тарафына юнәлдер. (Ий, мөселманнар) кайда гына булсагыз да, йөзләрегезне шул Кыйблага юнәлдерегез. Шик юк ки, китап әһелләре (яһүдләр һәм христианнар) бу гамәлләрнең Аллаһтан килгән чынбарлык икәнен бик яхшы беләләр. Аллаһ аларның ни кылганнарыннан хәбәрсез түгел».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:144

Хаҗ һәм гомрә кылучылар ул мәчеттә намаз укырга тырышалар. Ул мәчетнең икенче исеме – «Мәсҗидүл-кыйбләтәйн» (ике кыйбла мәчете). Бу мәчет Пәйгамбәребезнең мәчетеннән 5 чакрым ераклыкта урнашкан.

Мөхтәрәм мөселманнар! Шәгъбан аеның 15 нче көне вә кичәсе елның иң олуг көннәреннән санала. Шул көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте һәм мәгъфирәте җир йөзенә таралып торыр. Хәдис-шәрифтә болай дип әйтелгән: «Шәгъбан аеның унбишенче кичәсе керсә, аны гыйбадәт белән үткәрегез. Көндез исә ураза тотыгыз, чөнки Аллаһы Тәгалә ул кичне кояшның чыгуына кадәр дөнья галәменә рәхмәт күзе белән карар һәм боерыр: «Тәүбә һәм истигъфар итүче булса, аны гафу итәм. Ризык сораучы булса, аңа ризык бирәм. Авыруга дучар булса, аңа саулык-сәламәтлек бирәм. Бармы андый кешеләр, бармы?», – дип әйтер»[1].

Бу кичәне «Бәраәт кичәсе» дип атыйлар. Аның олуглыгы турында хәбәр-риваятьләр күп. Бәраәт кичәсендә бер ел эчендә булачак эшләр хакында хөкем кылына, әҗәл вә гомерләр билгеләнә.

1 Имам Ибн Мәҗә хәдисләр җыентыгыннан

Бу изге кичәдә Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен мөмкин кадәр изге гамәлләр, нәфел гыйбадәтләр кылырга тырышырга кирәк. Аллаһы Раббыбызның бөтен әмерләренә буйсыну, кешеләр белән күркәм мөгамәләдә булу мөселманлыкның мөһим сыйфатлары булып тора. Пәйгамбәребез ﷺ әйткән: «Аллаһы Тәгалә өч нәрсәне өч нәрсә эченә яшергән: Үз ризалыгын яхшы гамәлләрнең берсенә яшергән». Димәк, даими яхшы гамәлләр кылучы кеше, әлбәттә, Аллаһының ризалыгын таба. Изге гамәлләр исә күп төрле. Һәрнинди яхшы, файдалы гамәлне «бу кечкенә гамәл» дип әйтмичә, кылырга гына кирәк. Бу турыда Расүлүллаһ ﷺ болай дип әйткән: «Саваплы эшләрнең һичберен кечек дип санамагыз, кылып торыгыз! Хәтта агым судан алып башка бер кешенең комганына су салып бирү кебек кечкенә бер гамәлне дә, зур гамәл кебек хөрмәт белән кылыгыз», – дигән.

Яшергән нәрсәнең икенчесе – Үзенең газабын гөнаһ, начар эшләрнең берсенә яшергән. Димәк, гөнаһ гамәлләрдән сакланып йөргән кеше Аллаһның газабыннан, әлбәттә, имин булыр. Ләкин «Моның гөнаһы зур түгел», дип, кечкенә гөнаһлардан сакланмаган кеше, шиксез, бер Аллаһның газабына очрап калуы табигыйдыр.

Яшергән нәрсәләрнең өченчесе – вәли (изге) кешеләрне халык эченә яшергән. Бөтенесен хөрмәт кылган кеше, әлбәттә, Аллаһның вәлиен дә ихтирам иткән булачак. Әмма игътибарсызлыкка гадәтләнгән кеше бер ара Аллаһның иң яраткан бәндәсен дә рәнҗетеп куюы бик мөмкин.

Хак Тәгалә Кәләм шәрифтә әйтә:

وَقِيلَ لِلَّذِينَ اتَّقَوْا مَاذَا أَنزَلَ رَبُّكُمْ ۚ قَالُوا خَيْرًا ۗ لِّلَّذِينَ أَحْسَنُوا فِي هَٰذِهِ الدُّنْيَا
حَسَنَةٌ ۚ وَلَدَارُ الْآخِرَةِ خَيْرٌ ۚ وَلَنِعْمَ دَارُ الْمُتَّقِينَ ﴿٣٠﴾ جَنَّاتُ عَدْنٍ يَدْخُلُونَهَا
تَجْرِي مِن تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ ۖ لَهُمْ فِيهَا مَا يَشَاءُونَ ۚ كَذَٰلِكَ يَجْزِي اللَّهُ الْمُتَّقِينَ ﴿٣١﴾
الَّذِينَ تَتَوَفَّاهُمُ الْمَلَائِكَةُ طَيِّبِينَ ۙ يَقُولُونَ سَلَامٌ عَلَيْكُمُ ادْخُلُوا الْجَنَّةَ بِمَا كُنتُمْ

تَعْمَلُونَ ﴿٣٢﴾

**«Һәм тәкъваларга: «Раббыгыз нәрсә иңдерде?» – дип әйтелер. Алар: «Хәерлек!» – дип әйтерләр. Бу дөньяда яхшылык эшләгәннәргә – яхшылыктыр, ахирәт йорты исә, әлбәттә, хәерлерәк. Никадәр яхшы тәкъваларның йорты! Мәңгелек бакчалары, алар анда керерләр, аларның астында елгалар агып торалар, аларга анда – теләгән нәрсәләре. Тәкъваларга Аллаһ менә шулай җәза бирә, фәрештәләр тарафыннан пакь килеш вафат ителгәннәргә! Алар: «Сәлам сезгә! Кылганнарыгызга карата җәннәткә керегез!» – дип әйтер».**

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:30–32

Имам Шәгъби «Кифая» дип исемләнгән китабында язган: «Раҗәб аеның беренче өлеше (ун көнлеге), шәгъбан аеның икенче өлеше, Рамазан аеның исә ахыргы өлеше олы вә фазыйләтле көннәрдер. Шәгъбан аеның «Бәраәт кичәсе»ндә һәрбер мөэмин Аллаһы Тәгаләдән яхшы теләкләрне сорап, дога-тәкбирләрдә мәшгуль булуы тиешле».

Имам Газали «Мокашәфәтүл кулүб» дигән китабында язган: «Мөселманнарга җир йөзендә ике көн гает булганы кебек, фәрештәләр дә күктә ике кичәне гает кылып үткәрәләр икән. Алар исә – Кадер һәм Бәраәт кичәләре».

Имам Субуки үзенең тәфсирендә әйткән: «Ләйләтүл бәраәт» андагы сыйфатларга карап төрлечә исемләнә. Мәсәлән, бу кичәгә «ләйләтүл тәкфир», ягъни бәндәләрнең гөнаһлары кәффәрат кылына дигән, кичә диелә. Әгәр Аллаһы Тәгалә җомга көнне бер атна эчендә кылынган гөнаһларны кичерсә, «Бәраәт кичә»сендә бер еллык гөнаһларны гафу кыла. «Ләйләтүл кадер» кичәсендә исә Хак Тәгалә мөэмин бәндәләренең гомерләре буе кылган гөнаһларын кәффәрат кылып җибәрә».

Мөхтәрәм мөселманнар! Бәраәт кичәсенең кадерен белик. Шул кичәдә ихлас күңелдән догалар кылыйк, Аллаһы Раббыбызга тәүбә белән мөрәҗәгать итик.

Ислам галимнәре әйтүенчә, тәүбә кабул булсын өчен өч шарт үтәлергә тиеш. Беренче шарт үткән заманга карый, икенчесе – хәзерге заманга һәм өченчесе – киләчәк заманга:

1. кылган гөнаһ өчен чын күңелдән үкенү;
2. шушы гөнаһны кылмау;
3. киләчәктә бу гөнаһлы гамәлгә кередән кайтмаска ният кылу.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ үзенең бер хәдисендә бәни Исраилдән булган бер кеше турында риваять китерә: «Заманасында бер бәндә туксан тугыз кешене үтерә һәм аның күңеленә шик керә: әгәр тәүбә итсәм, Аллаһ мине гафу итәрме икән? Бу сорауга җавап табар өчен, ул гыйбадәтханәгә бара. Анда бер хөрмәтле кеше янына килә һәм аңа сорау бирә: «Мин туксан тугыз кешене үтердем. Әгәр тәүбә кылсам, Аллаһ мин гафу итәрме икән?» – ди. Теге кеше: «Кит, мөртәт, ничек инде син, туксан тугыз кешене үтереп, Аллаһның ярлыкавын өмет итәсең», – дип әйтә. Бу сүзләрне ишеткәч, җинаятьченең ачуы чыга һәм: «Ярар, син йөзенче булырсың», – дип әйтеп, теге кешене үтерә. Ләкин җинаятьченең күңеле тынычланмый, шик арта бара. Берникадәр вакыттан соң, бу кеше гыйлемгә, хикмәткә ия булган берәү янына килә һәм аңа шул ук сорауны бирә. Хикмәт иясе: «Әлбәттә, Аллаһ сине гафу итәчәк, чөнки Аллаһы Тәгаләнең тәүбә капкасы һәрвакыт ачык, ләкин белеп тор, син бу шәһәрдә җинаятьче булып танылдың, шуңа күрә башка шәһәргә кит. Шунда тәүбә кылырсың, сиңа анда беркем дә комачауламаячак», – дип әйтә. Бу кеше хикмәт иясенең сүзләрен үзенең күңеленә сала да, күрше шәһәргә юнәлә, ләкин ярты юлда вафат була. Бу кеше янына ике төркем фәрештә төшә. Бер төркеме: «Бу кеше җәннәткә керә», – дип әйтә. Икенчеләре: «Юк, ул җәһәннәм әһеле булачак», – диләр. Шулай итеп, фәрештәләр бер-берләре белән бәхәсләшә башлый. Аллаһы

Тәгалә Җәбраил фәрештәгә: «Алар янына бар, үлчәсеннәр, бу кеше кайсы якка якынрак, чыгып киткән шәһәргәме, әллә бара торган шәһәргәме?» – дип әмер бирә. Фәрештәләр үлчиләр һәм бу кеше тәүбә кылырга бара торган шәһәргә якынрак булуын ачыклыйлар. Аллаһы Тәгалә бу кешене җәннәт әһеле итеп язып куярга куша»[1].

Аллаһы сөбханәһү вә Тәгалә барчабызга шушы мөбарәк кичәдә тәгать-гыйбадәтләр, тәүбәләр кылып, күңелләребезне пакьләргә, нурландырырга, изге максатларыбызга ирешергә насыйп итсә иде.

*Нияз хәзрәт Сабиров,*
*ТҖ МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе,*
*«Апанай» мәчете имам-хатыйбы,*
*тарих фәннәре кандидаты*

1 Әбү Ләйс Сәмәрканди «Тәнбиһүл-гафилин»

*12 нче май вәгазе,*

*Шәгъбан аеның 16 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1438 нче ел*

# Сатып алынган авыру

Галәмнәрне юктан бар кылып, безгә меңләгән пәйгәмбәрләр җибәрүче Аллаһы Тәгаләгә иң зур дан-мактаулар булсын. Һәм галәмнәргә иң зур рәхмәт итеп җибәрелгән Пәйгәмбәр, калебләрнең нуры, йөрәкләр табибы булучы Мөхәммәд Пәйгамбәребезгә ﷺ күңел түрләреннән чыккан иң күп салават-шәрифләребез булса иде!

Бүген динебез таралып, күпләр дин юлына басканда, кайбер җитешсез якларыбыз һаман да кала бирә. Адәм баласы яңадан-яңа гөнаһ юлларын табып тора. Боларның берсе һәм иң күп таралганы булып тәмәке белән кальян тарту торадыр, җәмәгать. Әлбәттә, алар хәраммы әллә мәкрүһ тәһримме булуына карата зур ихтиләф бар. Вәгазьне язар алдыннан галимнәребез белән киңәшләштек һәм Җәлил хәзрәт Фазлыев биргән җавапны сайлап язарга булдык. «Тәмәке һәм кальян мәкрүһ тәһрим булса да, үзенең күп зарар китерүе белән хәрам хөкемендә була», – диде республикабызның баш казые. Яхшылап карасак: беренчедән, бу сәламәтлеккә, тирә-юньгә, кешенең финанс торышына тәэсир итә. Кешене гаиләсен ашатырга дип эшләгән акчасын шушы буш һәм зарарлы нәрсәләргә әрәм итәргә мәҗбүр итә. Табиблар әйтүенчә, тәмәкегә караганда кальянның зарары тагын да күбрәк һәм куркынычрак.

Ә дин ягыннан моңа нинди караш һәм нинди аять-хәдисләр белән бу нәрсәләрнең гөнаһлы гамәл икәнен дәлилләп була соң? Иң беренче – тәмәке кеше сәламәтлегенә зарар китерә, кешенең күп әгъзаларын эштән чыгара. Һәм нәтиҗәдә кешене үлемгә китерә, димәк, кеше үз-үзен үтерә, дигән сүз. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَلَا تَقْتُلُوٓا۟ أَنفُسَكُمْ ۚ إِنَّ ٱللَّهَ كَانَ بِكُمْ رَحِيمًا ﴿٢٩﴾

**«...Янә үз-үзегезне, яки дин кардәшегезне үтермәгез. Дөреслектә, Аллаһ сезнең өчен рәхимле булды».**

«Нисә / Хатыннар», 4:29

Исламда кешенең үз-үзен үтерүе – бу әле кеше үзенә генә китергән зарар. Ә бит тәмәке тартучы әле тирә-юнендәге кешеләргә дә күпме зарар китерә. Җәмәгать транспорты тукталышларында тәмәкесен кабызып тартып, төтенен битеңә диярлек өреп басып торганда, сулыйсың килмәсә дә суларга туры килә.

Икенчедән, хәдисләргә мөрәҗәгать итсәк, Пәйгәмбәребез ﷺ малны, сәламәтлекне һәм вакытны бушка әрәм итмәскә куша. Кыямәт көнендә бит адәм баласы Аллаһ каршында байлыгын һәм вакытын нәрсәгә кулланганын әйтергә мәҗбүр була, чөнки Аллаһ безгә боларның барсын да амәнәт итеп, вакытлыча куллануга биреп торды. Хәрамга яки гөнаһлы юлга киткән акчаны, вакытны һәм сәламәтлекне кайтарып булмый. Әле ул булганының да бәрәкәтен ала. Кеше шул акчасына йортына, гаиләсенә ризык алып кайтса, никадәр савапка ирешер иде. Хәдистә килгәнчә, кеше үз гаиләсенә алып кайткан һәр кисәк ризык өчен савап ала. Ә әгәр дә шул акчасын җыеп ятимнәр һәм мескенннәргә өләшсә, нинди әҗер булыр иде?

Әгәр без гыйлем алмасак, мәчеткә йөрмәсәк, мескеннәргә ярдәм итмәсәк, ә тәмәкегә вакыт та, акча да тапсак, Аллаһ каршысына нинди оят белән басарга кирәк?! Кайбер кешеләрдә, кызганыч, кальянны бит мөселман илләрендә тарталар, Исламда кальян рөхсәт ителгән дигән ялгыш фикер таралган. Кальянның Ислам культурасына бернинди дә катнашы юк. Бу гамәлләр мөселман илләренә 20 нче гасырда үтеп кергән чир. Бу гамәлләр берсе дә дин ягыннан хупланмый һәм рөхсәт тә ителми. Кызганыч ки, кайвакыт кулларына тәмәке тоткан гүзәл затларны да күрергә мөмкин, монысы инде бөтенләй дә кискен хәл. Бу гүзәл затларның әни буласылары, гаиләдә балаларына күркәм тәрбия бирәселәре бар. Әгәр бала

гаиләдә әти-әнисенең тәмәке тартканын һәм кунак җыеп хәмер эчеп, кальян тартканын күрсә, бу бала тулы җәмгыять өлеше була аламы? Һәм без, мөселманнар, кешеләргә бу эшләрнең бик начар икәнен чын-чынлап аңлатсак һәм үз гамәлләребез белән күрсәтсәк, Аллаһның рәхмәте белән бу чирләрдән арынырбыз.

Кызганыч, кайбер кардәшләрнең «мин дин юлында, мин шушындый сөннәт гамәлне кылам», дип сөйләп тә, тәмәке белән мавыкканнарын күрергә туры килә. Мондый сорау туа: синең бер сөннәтне үтәп, шул ук вакытта тәмәке тартуың бу сөннәт савабын яндырмыймы? Мөхтәрәм газиз дин кардәшләрем, үзебезне шундый куркыныч гадәтләрдән, шайтан гамәлләреннән сакласак иде. Инде шушы авыруга бирелгән кардәшләребезгә Аллаһы Тәгаләдән шифа сорасак иде.

*Алмаз Галимҗанов,*
*Саба районы имам-мөхтәсибенең*
*яшьләр эше буенча урынбасары*

*19 нчы май вәгазе,*

*Шәгъбан аеның 23 нче көне, һиҗри исәп буенча 1438 нче ел*

## Каберләрне зиярәт итү

Бөтен галәмнәрнең тәрбиячесе булган, безгә ике дөньяның бәхетенә ирешү өчен шәригатьне бүләк иткән Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгаләгә барча мактауларыбыз, шөкраналарыбыз булса иде. Безгә Аллаһның кануннары буенча яшәргә өйрәткән, безнең өчен тырышкан, кайгырган, күп догалар кылган сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафага ﷺ, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Газиз дин кардәшләрем, әссәләәмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәракәәтүһ. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә илебезгә, җаннарыбызга тынычлык, әгъзаларыбызга сәламәтлек, күңелләребезгә тәүфыйк-һидаять биреп, хәерле һәм бәрәкәтле тормышлар насыйп итсә иде. Бүгенге вәгазебез каберләрне зиярәт итү турында булачак.

Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ үзенең мәшһүр хәдисендә: «Мин сезгә каберләрне зиярәт итүне тыйган идем, хәзер исә рөхсәт бирәм, чөнки каберләрне зиярәт итү Кыямәт көнен искә төшерә», – дип әйткән[1].

Каберлек – ул шундый бер тыныч урын ки, анда кеше үз-үзе белән ялгыз калып, фикер йөртә, зирәгрәк була башлый, үз яшәеше һәм анда күмелгән кешеләрнең тормышлары турында уйлана, гыйбрәт ала. Каберләрне зиярәт итү һәрберебезгә киләчәк үлемебезне искә төшерә.

Кеше һәрвакыт ике чынбарлык: яшәү теләге һәм үлемнең котылгысызлыгы арасында яши. Әгәр яшәүнең һәм үлемнең хакыйкый мәгънәсен танымасак, яшәү мәгънәсен беркайчан да аңлый алмаячакбыз.

[1] Имамнар Тирмизи, Мөслим хәдис җыентыкларыннан

Иманлы кеше өчен үлем – Алллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән бүләк ул, бер халәттән икенче халәткә күчү, ә имансызлар һәм гөнаһлы кешеләр өчен үлем җәзага әйләнә.

Дөреслектә, кешенең ике төп киңәшчесе бар: аларның берсе сөйләүче булса, икенчесе – дәшмәүче. Сөйләп торган киңәшче Аллаһның бөек китабы Коръән булып тора, ә сөйләшмәүче – үлем. Кешеләр менә шушы сөйләшми торган киңәшчедән дәрес, гыйбрәт алсыннар өчен, бабаларыбыз каберлекләрне шәһәрләрнең үзәгендә урнаштырганнар.

Үлемнең теле юк, ләкин ул дәшми торса да, аңа тирән мәгънә салынган. Каберлекләр безнең әти-әниләребезнең, әби-бабаларыбызның, туган-кардәшләребезнең, яраткан дусларыбызның исемнәре белән тулыдыр.

Мөхтәрәм җәмәгать, шуны онытмасак иде! Аллаһның Расүле ﷺ әйткән: «Кабер – ул буш дөнья түгел. Иманлы бәндә өчен ул җәннәт бакчаларыннан бер бакча, имансыз кеше өчен җәһәннәм чокырларыннан бер чокыр булачак», – дигән[1].

Сөекле Пәйгамбәребез ﷺ үзе еш кына сәхабәләрнең каберләрен зиярәт иткән һәм алар өчен дога кылган: «Сезгә иминлек, тынычлык насыйп булсын! Әгәр Аллаһ теләсә, без дә сезгә тиздән кушылачакбыз. Мин үзебез һәм сезнең өчен Аллаһы Тәгаләдән бәхет сорыйм».[2]

Хөрмәтле мөселманнар! Каберләрне зиярәт итү безгә дәрес бирсә, ин шә Аллаһ, мәетләребезгә җиңеллек китерә. Ибн Габбас ؓ риваять итә: «Бервакыт Расүл Әкрам ﷺ ике кабер арасыннан үткәндә, болай дип әйткән: «Хәзерге вакытта шушы ике кабердә ятучылар зур булмаган гөнаһлары өчен зур җәза алалар. Кабердә ятучыларның берсе гайбәт сөйләп йөргән, ә икенчесе нәҗестән пакьләнмәгән». Шуннан соң Пәйгамбәребез ﷺ пальма ботагын сындырып, аны икегә бүлеп, шул каберләр өстенә кадап куй-

1 Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан

2 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

ган һәм әйткән: «Бу ботаклар корыганчыга кадәр ул кешеләрнең кабер газапларын җиңеләйтеп торыр»[1].

Танылган мөфәссир имам Куртуби бу хәдисне болай дип шәрехли: «Бу ботаклар корыганчыга кадәр» дигән сүзләр шуны аңлата: әгәр кабергә үсемлекләр утыртылса яки Коръән укылса, мәетләр җиңеллек сизә. Әгәр бер үсемлек мәетнең хәлен җиңеләйтсә, Коръән уку аңа тагын да күбрәк җиңеллек бирәчәк».

Әгәр мәетләребезгә Коръән укылса, бигрәк тә «Йәсин» сүрәсе укылса, аларга Аллаһның рәхмәте ирешәчәк. Мәетләргә «Йәсин» сүрәсен уку турында хәдис-шәрифтә болай дип әйтелгән: «Йәсин» сүрәсе Коръәннең калебе булып тора. Дөреслектә, Аллаһның ризалыгын һәм киләсе дөньяда Аллаһның рәхмәтен алу нияте белән «Йәсин» сүрәсен укыган кешенең гөнаһлары гафу ителер, шулай булгач, мәетләрегезгә «Йәсин» сүрәсен укыгыз», – дигән[2].

Аллаһның Расүле ﷺ әйткән: «Әгәр сезнең берегезгә үлем ирешсә, аны тиз арада күмәргә тырышыгыз. Мәетне күмгәннән соң, аның баш очында «Фатиха» сүрәсен, ә инде аяк очына басып, «Бәкара» сүрәсенең соңгы аятьләрен («Әмәнә расүл») укыгыз»[3].

Имам Нәвави «Риядус-салихин» («Изгеләр бакчасы») дип исемләнгән китабында имам Шәфигый сүзләрен китерә: «Кабер янында изге Коръәннән аятьләр һәм сүрәләр уку яхшы гамәл булып санала, әмма Коръәнне тулысынча уку – тагын да яхшырак».

Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә Үзе Коръәндә мәетләребез өчен дога кылырга өйрәтә:

رَبَّنَا اغْفِرْ لَنَا وَلِإِخْوَانِنَا الَّذِينَ سَبَقُونَا بِالْإِيمَانِ وَلَا تَجْعَلْ فِي قُلُوبِنَا غِلًّا لِّلَّذِينَ آمَنُوا رَبَّنَا إِنَّكَ رَءُوفٌ رَّحِيمٌ ﴿١٠﴾

---

1 Имамнар Бохари, Мөслим, Тирмизи хәдис җыентыкларыннан

2 Әхмәд ибн Хәнбәл, Мөснәд

3 Имамнар Табарани, Дәйләми, Хәйсәми хәдис җыентыкларыннан

**«Йә Раббыбыз, гөнаһларыбызны ярлыка һәм бездән элек иман китергән дин кардәшләребезне ярлыка! Һәм безнең күңелләребездә иман китергән кардәшләребезгә карата дошманлык кылма! Йә Раббыбыз, дөреслектә, Син шәфкатьле һәм рәхмәт кылучы!»**

«Хәшер / Сөреп Чыгару», 59:10

Мөхтәрәм мөселманнар! Монда начар гадәтләргә, ягъни бидгатьләргә игътибар итәргә һәм шулардан ерак булырга кирәк. Ислам галимнәре үзләренең китапларында каберләрне зиярәт итү кагыйдәләрен, әдәпләрен аңлаткан булсалар да, хәзерге көндә кайберәүләр шушы хаталарны кабатлыйлар. Берәүләр дини наданлыклары аркасында кабер өстендә шәм кабызалар, кәгазьләргә, чүпрәкләргә үзләренең теләкләрен язып, аларны чардуганга яисә кабер өстендәге агач ботакларына бәйләп куялар. Башкалар исә икенче чиккә тайпыла, каберләрне зиярәт иткән кешеләрне ширектә гаепли. Без гамәлләр кылганда чикләргә тайпылмыйча, урталыкны тотарга тиеш. Якын кардәшләребездә хаталарны күрсәк, аларны хурламыйча, рәнҗетмичә хикмәт белән дөреслекне аңлатырга кирәк.

Ибн Габбас ﷺ риваять кыла: Сәгъд бин Губәдә ﷺ дигән сәхабәнең әнисе үлгәч, ул Пәйгамбәребез ﷺ янына килеп: «Йә Расүлүллаһ, минем әнием вафат булды. Ул үлгән вакытта янында була алмадым. Әгәр әнием өчен үз җиләк-җимеш бакчамны сәдака итеп бирсәм, бу гамәлем аңа файда китерерме икән?» – дип сорады.

Аллаһның Расүле ﷺ : «Әйе», – диде.

Сәгъд ﷺ әйтте: «Әй Аллаһның Расүле! Шаһит булыгыз! Мин әнием өчен бакчамны сәдака итеп бирәм», – диде[1].

Безне хак юлга әйдәүче Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Кеше вафат булганнан соң барлык гамәлләреннән өзелә, ләкин аның өч төрле гамәле файда китерәчәк: 1) сәдакатүл-җәрия, ягъни кеше үлгәннән соң да файда китерә

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

торган сәдака; 2) башкаларга биреп калдырылган белем; 3) балаларның догалары.[1]

Мөхтәрәм җәмәгать! Хәдисләрдән күренә ки, мәетләребез өчен Коръән уку, сәдакалар бирү һәм башка изге гамәлләр кылу аларга җиңеллек һәм саваплар китерә. Бу фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчкән әти-әниләребезне, әби-бабаларыбызны, туган-тумачаларыбызны, якын дусларыбызны, кардәшләребезне онытмыйча, алар өчен догалар кылсак иде. Аларның каберләрен тәртиптә тотып, алар янында чүпләр калдырмасак иде.

*Нияз хәзрәт Сабиров,*
*ТҖ МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе,*
*«Апанай» мәчете имам-хатыйбы,*
*тарих фәннәре кандидаты*

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

*26 нчы май вәгазе,*

*Шәгъбан аеның 30 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1438 ел*

# Гыйбадәтләребез җәннәт белән сөендерер

Рамазан аенда ураза барыбыз өчен дә фарыз. Бу турыда аять тә бар:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

**«Әй иман китергән кешеләр, сездән алдагы кавемнәргә фарыз булган шикелле, сезгә дә ураза фарыз булды»,** – диелә.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Моны безгә Аллаһ Тәгалә әйтте, кушты. Кайбер кешеләр: без моны үти алмыйбыз бит, безнең көчебез җитми моңа, дип, мисаллар китереп, төрле акланулар табалар. Аллаһ Тәгалә безгә көчебез җитмәгәнне йөкләми. Көчебез җиткәнне генә йөкли. Ул: «әй кешеләр», – дисә, барлык кешегә фарыз булыр иде. Монда Ул: «әй иман китергән кешеләр», – ди. Иман китереп: «Ләәә иләәһә илләлааах Мүхәммәдүр Расүүлүллааах», – дип, Аллаһны танып, чын күңелдән Аңа инанган кешеләр өчен ураза фарыз булды, димәк. Әгәр кеше Аллаһны танымаса, иман китермәсә, әлбәттә, имансыз кеше ураза тота алмый, аның аңа көче җитми. Әмма иманлы кешегә ураза тоту – ул бер бәхет, бер сәгадәт, аңа Аллаһның бер бүләге. Ул аны сөенеп каршы ала, аның беткәненә кайгырып тора. Аңа ураза тоту да, кич белән мәчеткә килеп, егермешәр рәкәгать тәравих намазы уку да – бер бәйрәм, Аллаһның бер рәхмәте.

Ураза – иң җиңел гыйбадәтнең берсе. Намаз уку өчен әле кеше тәһарәт ала белергә, күпмедер сүрәләр өйрәнергә, намазның

хәрәкәтләрен истә тотарга тиеш. Ураза тотар өчен исә кеше билгеле арада ризыктан, яман сүздән, якынлык кылудан тыелып кына торырга тиеш. Монда сүрәләр, аятьләр ятлыйсы да, хәрәкәтләр, тәртипләр өйрәнәсе дә юк. Календарь булса, сәгать булса, шул җитте. Кеше кояш чыгарга ике сәгать кала сәхәр ашап бетерергә тиеш. Шуннан соң бер унбиш-егерме минут Коръән аятьләре укып, шушы йорттан ахирәткә киткәннәр рухына дога кылып утыргач, иртәнге намазын укый да, шуның белән көне башланып китә.

Монда ният әйтү – фарыз. Сәхәр ашап бетергәч, татарча, үз телебездә: «Иләһи ният кылдым, бер Ходаем, Үзеңнең ризалыгың өчен Рамазан уразасын тотмакка, таң беленгәннән алып кояш баеганга кадәр», – дип әйтсәк, ният була. Гарәпчә ошбу сүзләрне укып, тел илә ният кылу мөстәхәбтер:

نَوَيْتُ أَنْ أَصُومَ صَوْمَ شَهْرِ رَمَضَانَ مِنَ الْفَجْرِ إِلَى الْمَغْرِبِ خَالِصًا لِلَّهِ تَعَالَى

**«Нәүәйтүән әсуумә саумә шәһри рамәдаанә минәлфәҗри иләл-мәгрибн хаалисан лилләәһи тәгәәләә».**

Кичтән үк без ураза тотабыз, дип уйлап ятып, сәхәр әзерләвебез үзе дә ният инде. Кемдер ният әйтмәгән булса да, борчылырга тиеш түгел. Кайвакыт иртә белән кояш чыгарга ике сәгать кала ашап, каядыр барасың, көндез ашарга туры килми. Әмма бу ураза булып китми. Без монда сәхәр ашарга дип ниятләмәдек. Бу вакытта, әгәр уразадан китсен инде бу, дисәк, ниятләп куярга тиешбез. Рамазан уразасында исә ният бер шарт булып торса да, безнең кичтән үк сәхәргә әзерләнеп ятуыбыз үзе ният инде.

Сәхәр ашаганнан соң, авызларны чайкап, уразаны бер ниятләп куйгач, без көне буе судан, ризыктан һәм якынлык кылудан тыелып торырга тиешбез. Телебезне ялганнан, гайбәттән сакласак, бик саваплы булабыз. Уразабыз үзенең нигезенә, җиренә җитә. Ризыктан тыелу – уразаның кечкенә өлеше, җиңел өлеше, әмма гайбәттән, сүздән тыелып тору – уразаның авыр өлеше. Аллаһ Тәгалә безгә акыл биргән икән, без үзебез

дә акыл белән фикер йөртеп, уразаның авыр өлешен дә үтәп чыгарга тырышырга, гайбәткә кермәскә, ялган сөйләмәскә, бер-беребез белән ачуланышмаска тырышырга тиеш. Кемдер безнең каршыбызга килеп сүз сөйләп тора икән, ул кешегә: «Мин уразамын, мин уразамын, мин уразамын», – дип әйтергә кирәк. Үзеңнең уразада икәнеңне әйтү бу вакытта рия булмый. Бик ачуың чыкса да, кемгәдер ачуланма, мин уразамын, дип кенә белдер. Кич белән, кояш баегач, авыз ачарга кирәк була. Календарь кирәк тә, сәгать кирәк инде.

Календарьда кояшның кайчан баюы языла, кояш баегач, без авыз ачарга тиеш булабыз. Тоз белән, су белән, йә булмаса, татлы бер җимеш белән авыз ачу саваплы санала. Болар – Аллаһның беренчел яраткан җимешләре. Әйтик, шикәр – ул чөгендердән ясалган, икмәкне без нәрсәләрдер кушып үзебез әзерләдек. Тоз, су, җимешләр – Аллаһ Тәгалә беренчел бар иткән нигъмәтләр. Авыз ачканнан соң татарча: «Йә Раббым, Үзеңнең ризалыгың өчен генә ураза тоттым, тоткан уразаларымны кабул кыл, йә Раббым, үзеңнең биргән нигъмәтләрең белән авыз ачам, кылган гөнаһларымны гафу кыл», – дип әйтсәк, һәм белгән кеше дога кылып куйса, бу шулай ук гүзәл бер эш була. Ифтар кылганнан соң ошбу дога укыла:

اَللَّهُمَّ لَكَ صُمْتُ وَبِكَ أَمَنْتُ وَعَلَيْكَ تَوَكَّلْتُ وَعَلَى رِزْقِكَ أَفْطَرْتُ فَاغْفِرْ لِى يَا غَفَّارُ مَا قَدَّمْتُ وَمَا أَخَّرْتُ

**«Әллааһүммә ләкә сумтү үә бикә әәмәңтү үә гәләйкә тәүәккәлтү үә гәләә ризкыйкә әфтартү фәгъфирлии йәә гаффәәру мәә каддәмтү үә мәә әххартү».**

Сәхәрдә кеше ризыкны күпме ашаса да ярый. Пәйгамбәребезнең ﷺ шундый бер хәдисе бар: «Туйганчы ашау – әдәпсезлек, туйганнан артыгын ашау – хәрам». Менә туйганнан артыгын ашау, күбрәк итеп ашау сәхәрдә һәм кунак сыйлаганда рөхсәт ителә. Ике очракта. Авыз ачкач исә

кеше җиңелчәрәк кенә ашап калу белән канәгатьләнергә, нәфесен тагын бер кат җиңә торган көч табарга тиеш. Сәбабы тияр.

Һәм инде ахшамнан соң, сәгать ярымнан соң безнең ясигә вакыты керә. Шушы вакытта тәравих намазы уку шулай ук бик саваплы. Беренче – тәравих намазын укыган кешенең гөнаһлары ярлыканыр. Рамазан аеның икенче көнендә икенче тәравих намазын укыган кешенең әти-әнисенең гөнаһлары кичерелер, – ди. Сау-сәламәт килеш Рамазан аен каршылаганбыз икән, шушындый саваплы гамәлләрне дә күбрәк кылырга кирәк. Өйдә ялгыз гына уку ялыктыра, шуның өчен мәчеткә килеп, җәмәгать белән, балалар тәравих әйткәнне тыңлап, намазны мәчеттә укысак, саваплырак. Җәмәгать белән булгач, күңелле дә була, икенчедән, безнең өебездән чыгып китеп кайтып кергәнгә кадәр вакытыбыз гыйбадәттән санала. Бер савап Рамазан аенда, ким дигәндә, 700 савапка хисапланыр, ди. Бер сум сәдака бирсәң, 700 сумнан хисаплана. Ким дигәндә. Бер Аллаһ Тәгалә генә белә. Рамазан аенда фитыр сәдакасы бар. Ураза тотабыз, сәхәр ашыйбыз, авыз ачабыз, кайберәүләрнең, авыз ачкач, ашарга ризыклары булмаска мөмкин, кайберәүләрнең гает көнендә, бәйрәм итеп, табынга куярга ризыклары булмавы ихтимал. Шуның өчен иң беренче чиратта мескеннәргә, хәле авыр гаиләләргә без ураза фитыры бирергә тиеш булабыз. Алар да безнең белән бергә сөенсеннәр, шатлансыннар, шушы сәгадәт, бәхет, рәхмәт аен алар да аңласыннар. Ураза фитыры – байлыгы көмеш нисабына җиткән кешегә ваҗиб була. Димәк, бу кеше фитыр сәдакасын бирмәсә, гөнаһлы була. Байлыгы көмеш нисабына җитмәгән кеше фитыр бирсә, саваплы була, әмма бирмәсә, бу кешегә гөнаһ булмый. Ураза фитыры җан башыннан бирелә. Нисап малына алтын-көмеш, бәллүр савыт-сабалар, диварга эленгән келәмнәр, саклык акча, сатарга куйган мал керә. Менә шушының бөтенесенең кыйммәте 7 мең сумнан артып китсә, бу гаиләгә ураза фитыры ваҗиб була. Бирсә – савап, бирмәсә – гөнаһлы. Кайвакыт сәдаканың күләмен билгелиләр. «Ник билгелиләр аны?» – дип сорыйлар.

Нәфел сәдакасының күләмен билгеләргә беркемнең дә хакы юк. Әмма бар зәкәт, бар фитыр, бар гошер – боларның күләмнәре билгеләнгән.

Рамазан аенда һәр изге гамәлнең савабы зуррак, шуңа күрә зәкәтне дә Рамазан аенда биреп кую яхшы. Зәкәтне нисабы 83 грамм алтын хәтле малы булган кеше бирә. Алтынның граммы 12 доллар булса, нисаб мең доллар чамасы килеп чыга. Алтын-көмеш савыт-сабалар, дивардагы келәмнәр, сатарга дигән мал, кассадагы акча, бөтенесен җыйгач, мең доллардан артса, кеше шушы байлыгының кырыктан берен зәкәт итеп бирергә тиеш. 2,5 процент. Әйтик, 100 мең сумга җыела икән, бу кеше бөтенесе 2,5 мең күләмендә сәдака бирергә тиеш. Сәдака бурычлы кешегә, ятим кешегә, фәкыйрьгә, шәкертләргә бирелсә – яхшы. Моны да Рамазан аенда тапшыру саваплы. Бу сәдаканы мәдрәсәләргә, мәчетләргә дә бирә алабыз. Чөнки бүген мәдрәсәләргә дә, мәчетләргә дә дәүләттән бер тиен дә акча каралмаган. Шуның өчен мәчет-мәдрәсәләргә сәдака бирү дөрес санала.

Ә инде бер кеше, менә 2,5 мең сум акча, сиңа зәкәт китердем, кабул итеп ал әле, дип, үзенең дә зәкәт чыгарырлык малы булган кешегә бирсә, бу кешенең моны алырга хакы юк. Әйтергә тиеш: «Минем үземнең дә зәкәт чыгарасым бар, бу миңа тиеш түгел, син ярлырак кешегә бир», – дип. Бу ире үлгән тол хатыннарга кагылмый. Чөнки алар кимсетелгән булып саналалар, алар бүген балалар үстерәләр. Боларның алырга хаклары бар. Уттан бәла-каза күргән, эре малы үлеп китеп, бәла-казага тарган, кемнәндер бурычка акча алып, өй салып мәшәкатьләнгән кешеләргә зәкәтне бирү искиткеч саваплы була.

Кайчак шундый сораулар биргәлиләр: намаз укый белмәгән кешегә ураза тоту ярыймы? – диләр. Намаз үзенә күрә бер фарыз, ураза үзенә күрә бер фарыз. Намаз укый белмәсәң дә, Рамазан уразасын тотарга кирәк. Җилкәңнән бер фарызың төшеп тора. Хәтта кеше намаз укымаса да, Рамазан аен сау-сәламәт килеш каршылаган икән, ул тәненең зәкәтен

чыгарырга тиеш. Ураза ул – безнең тәнебезнең зәкәте, сәламәтлегебезнең зәкәте. Авыру кешегә ул мәҗбүри түгел. Аны терелгәч тота ала, терелмичә үлеп китә икән, аның өстендә бу фарызы калмый.

Ураза чакта, онытылып китеп, нәрсәдер капсак, нәрсәдер ашап куйсак, нәрсәдер эчеп куйсак, ураза бозылды, дип уйларга ярамый. Искә төшүгә тиз генә авызны чайкап, уразаны дәвам итәргә кирәк. Ураза кешегә шулай ук базарда сатып аласы әйбернең тәмен татып карау да рөхсәт ителә. Татып карамый гына алса, саваплырак була. Татып караса, уразасы ачылмый. Кемдер авыртып, авыруы көчәйгән шикелле булып, мәҗбүри дару эчәргә, укол кадатырга туры килсә, бу кешегә уразадан чыгарга, терелгәч, бу көннәр өчен яңадан шул көннәр санынча ураза тотарга кирәк.

Кеше үз ирке белән уразаны өзсә, бу кешенең өстендә 60 көнлек ураза каза булып тора. Бу кеше шушы бер көнне түләр өчен тоташ 60 көн ураза тотарга тиеш.

Шушы кагыйдәләрне белеп, уразаны ризыктан, судан гына тыелуга кайтарып калдырмыйча, телебезне дә гайбәтләрдән, яман сүзләрдән саклап, матур иттереп Рамазан айларыбызны үткәрергә Аллаһ Тәгалә насыйп итсә иде. Кайсыларыбызга Аллаһ Тәгалә байлык биргән икән, байлыгыбыз бар икән, шушы байлыгыбызның зәкәтен дә бирергә кирәк. Шулай ук ураза фитырларыбызны да тапшырыйк.

Бу айда Аллаһның кешеләргә тагын бер рәхмәте бар: кем дә кем ураза тоткан кешеләрне чакырып, авыз ачтырса, ифтар мәҗлесе оештырса, ураза тоткан кешеләрнең савабы ул кешегә дә язылыр, ди. Кемнең малы, вакыты бар икән, шулай ук Аллаһ Тәгалә каршысында иң күркәм, иң саваплы булган шушы табынны да әзерләргә кирәк. Өч кешене генә чакырып булса да авыз ачу табыны үткәрү зарури. Монда Коръән укыла. Аллаһның фарызын үтәүче кешеләр җыела. Аллаһ Тәгалә каршысында шушы табынның савабы белән никах табыны гына тиңләшә ала. Ә бүтән

вакытта Коръән укытып, без моның хәтле савапны ала алмыйбыз, чөнки 20–30–40 кеше җыярга мөмкинбез, шулар арасында бер-ике генә намаз укучы кеше булырга мөмкин. Бу төркем Коръән тыңлый, тамагын туйдыра, акчасын алыштыра да, кайтып китә. Рамазан аенда исә табынга ураза тоткан кешеләр чакырыла. Ураза тоткан кешенең үзенең савабы да кимеми, хуҗаның исә, ничә кешене чакырса, шулкадәр кешенең уразасының савабы гаиләә кешеләренә языла. Менә шушындый бәрәкәтле, бәхетле, сәгадәтле айга кердек без. Аллаһ Раббыбыз: «Санаулы гына көннәр ул», – диде. Санаулы көн тиз үтә. Һәр көнендә күбрәк изгелек эшләп калырга тырышырга кирәк. Шулай булганда без, мөселманнар, үзебезнең Аллаһ Тәгалә каршысындагы вазифаларыбызны үтәүчеләрдән булырбыз. Һәм Аллаһ Тәгалә үзенең вәгъдә кылган әҗер-савапларын да безгә насыйп итеп, үлгәннән соң шушы гыйбадәтләребез өчен җәннәт белән сөендерер.

*Җәлил хәзрәт Фазлыев,*
*Татарстанның баш казые,*
*Балтач районы имам-мөхтәсибе*

*2 нче июнь вәгазе,*

*Рамазан аеның 7 нче көне, һиҗри исәп буенча 1438 ел*

# Аллаһы Тәгаләгә ышануның баскычлары

Адәм балалары тышкы яктан төрле сурәттә, матди яктан төрле хәлдә булган кебек, аларның эчке дөньялары да төрле була. Ягъни бөтен яклап бертигез булган кешеләрне очрату мөмкин түгел дисәк, хата булмас, дип уйлым. Беренче карашка бер-берсенә охшаган кешеләрнең дә, җентекләп караганда, алай түгеллеге ачыклана. Әйтергә теләгән сүз шуннан гыйбарәт – кешеләрнең Аллаһы Тәгаләгә карата да мөнәсәбәтләре дә, Аның кодрәтенә таянулары да шулай ук төрле була.

Аллаһы Тәгалә бу хакта изге Китабында шулай дип әйткән:

﴿ بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ ﴾

إِذَا وَقَعَتِ الْوَاقِعَةُ ﴿١﴾ لَيْسَ لِوَقْعَتِهَا كَاذِبَةٌ ﴿٢﴾ خَافِضَةٌ رَّافِعَةٌ ﴿٣﴾ إِذَا
رُجَّتِ الْأَرْضُ رَجًّا ﴿٤﴾ وَبُسَّتِ الْجِبَالُ بَسًّا ﴿٥﴾ فَكَانَتْ هَبَاءً مُّنبَثًّا ﴿٦﴾
وَكُنتُمْ أَزْوَاجًا ثَلَاثَةً ﴿٧﴾ فَأَصْحَابُ الْمَيْمَنَةِ مَا أَصْحَابُ الْمَيْمَنَةِ ﴿٨﴾
وَأَصْحَابُ الْمَشْأَمَةِ مَا أَصْحَابُ الْمَشْأَمَةِ ﴿٩﴾ وَالسَّابِقُونَ السَّابِقُونَ ﴿١٠﴾
أُولَٰئِكَ الْمُقَرَّبُونَ ﴿١١﴾ فِي جَنَّاتِ النَّعِيمِ ﴿١٢﴾ ثُلَّةٌ مِّنَ الْأَوَّلِينَ ﴿١٣﴾
وَقَلِيلٌ مِّنَ الْآخِرِينَ ﴿١٤﴾

«Вакыйга» сүрәсенең беренче 14 аятендә Кыямәт көненең киләчәге һәм кешеләрнең өч төркемгә бүленәчәкләре турында сөйләнә. Бергәләшеп шушы аятьләрнең мәгънәләренә күз салыйк:

**«Һичшиксез, Кыямәт көне килеп җиткәч. Ә аның исә киләчәге һәм булачагы ялган түгел. Ул көнне (бер төркем) кешеләр (гөнаһлы**

**булганнары өчен) кимсетелер (икенчеләр кылган яхшылыклары һәм изгелекләре сәбәпле, хөрмәт белән) дәрәҗәле булыр. (Кыямәт сәгәтьләрендә) җир каты тетрәү белән тетрәр. Таулар җимерелеп төшәр һәм тузан бөртегенә әйләнер. (Ул дәһшәтле көннәрдә) сез (кешеләр) өч төркемгә бүленерсез. Берәүләре уң як төркеме булыр, сез аларның кем икәнлекләрен беләсезме икән?! Икенчеләр сул як төркеме булыр, сез аларның кемнәр икәнлеген чамалыйсызмы икән?! Өченчеләр исә күпкә алга китүчеләр (изгелек ярышында беренче булучылар). Нәкъ шушы төркем (Аллаһы Тәгаләгә) якын булучылар, (олы хөрмәткә лаек булган бәндәләр). Алар нигъмәтләр белән сугарылган җәннәт бакчаларында булырлар. Өченче төркемгә керүчеләр элеккеге заманаларда иманлы бәндәләрнең өчтән берен тәшкил иткән булсалар, хәзер исә, соңгы заманаларда, алар бик әзләр».**

«Вакыйга / Хәл», 56:1–14

Югарыда язылган аятьләргә таянып, Аллаһы Тәгалә каршында кешеләрнең дәрәҗәләре, рухи хәләтләре төрле дип аңлау кирәк, һәм дөнья тормышында бу хәл чыннан да шулай икәнлекне күзәтеп була. Кешеләрнең Аллаһы Тәгалә белән булган мөнәсәбәтләре берничә дәрәҗәгә бүленә. Башка төрле әйткәндә, дөньяда иманлы кешеләрне берничә төркемгә бүлеп була: беренче, икече һәм өченче баскычта булучылар дип бүлү урынлы булыр, дип саныйм.

1. Беренче баскыч. Авырлык килгәндә яки үзләренең көчләре белән генә берәр теләккә ирешә алмаганда, Аллаһы Тәгаләне искә төшерүче бәндәләр. Күпчелек кешеләр шулай яшиләр дә. Рәхәт булганда Аллаһы Тәгалә аларга кирәк түгел, ә инде авырлык килсә, алардан да диндаррак кешеләрне таба алмыйсың. Бу хакта изге Коръән китабында «Фүссиләт» сүрәсенең 51 нче аятендә шулай дип язылган:

وَإِذَا أَنْعَمْنَا عَلَى الْإِنسَانِ أَعْرَضَ وَنَأَىٰ بِجَانِبِهِ وَإِذَا مَسَّهُ الشَّرُّ فَذُو دُعَاءٍ عَرِيضٍ ﴿٥١﴾

**«(Ни гәҗәп) әгәр дә кешегә берәр төрле нигъмәт бирсәк, ул борылып китеп бара (Аллаһы Тәгаләне оныта). Ә инде аңарга берәр авырлык килеп кагылса, ул киң итеп дога кылучы (бик диндар кешегә әйләнә)».**

«Фүссиләт / Аңлатылды», 41:51

Диңгездә бер зур гына көймәдә унлап кеше өйләренә юл тоталар икән. Кинәт кенә бер көтмәгәндә каты җил-давыл чыга, һәм көймә бата башлый. Бөтенесе кулларын күкләргә күтәреп Аллаһы Тәгаләгә ялвара башлыйлар. Араларында Аллага ышанмаган бер кеше дә булла. Аның куллары бүтәннәргә караганда да югаррак сузыла. Ул: «Әй Раббым Аллаһы Тәгалә, коткар мине! Әгәр дә исән калсам, иң зур йортымны сатып, акчасын Синең юлыңда сарыф итәрмен», – дип Аллаһтан исән-имин калуын сорый.

Аны күргән бер иманлы бәндә: «Син бит Аллаһка ышанмыйсың, ничек әле Аңа ялварасың?» – дип сорый.

Теге исә кырыс кына: «Син мине башка кеше белән бутыйсыңдыр», – дип җавап кайтара. Сүзләренә өстәп: «Ә син нигә котылу хакында дога кылмыйсың?» – дип эндәшә.

Әлеге кеше исә: «Мин авырлыклар килгәнче, көймәгә утыргач ук дога кылдым. Ә хәзер исә Аллаһның тәкъдире ни белән бетәчәген күзәтәм. Ул ни язган булса, шул булыр», – дип җавап кайтара.

Бераз вакыт узгач, җил-давыллар басыла, һәм көймә исән-имин хәлдә яр буена килеп туктый. Һәм ни гаҗәп, әле бая гына имансызлыгыннан тәүбә кылган кеше, көймә яр буена килеп туктагач, мырылданамырылдана: «Ашыгыбрак йортымны сатып Аллаһы юлында сарыф итәм, дип әйтеп куйдым, ахрысы», – ди. Әлеге сүзләрен ишетеп алган дусты:

«Син әллә Аллаһы Тәгалә диңгездән тыш башка җирдә сине газаплый алмас, дип уйлысыңмы?!» – дип әйтеп куя.

Әйе, җәмәгать, әлеге риваятьтә сөйләнгән имансыз байга охшаган кешеләрне очрату сирәк күренеш түгел. Авырлык килгәндә генә Аллаһы Тәгаләне искә төшерү асылда дөрес хәл булмаса да, андый кешеләрне без тәнкыйть итәргә тиеш түгел. Һәрберебез үзе өчен үзе җавап бирер. Ә минем иманым ни дәрәҗәдә икән, дигән сорауны үзебезгә бирик. Аллаһы Тәгаләне искә төшерүнең икенче баскычында басып торган кеше беренче баскычта булган бәндәләргә кимсетеп карамасын. Һәм икенче баскыч соңгы баскыч түгел икәнлекне онытмасын иде.

2. Икенче баскыч. Рәхәт булганда да, авырлыклар килгәндә дә, Аллаһы Тәгаләне истән чыгармаучылар. Пәйгамбәребез ﷺ бу хакта шулай дип боера: «Чын иманлы бәндәнең хәленә гаҗәпләнәм. Чөнки аның белән була торган бөтен нәрсәдә аның өчен хәерле ягы бар. Һәм бу хәл иманлы бәндәгә генә хас булган нәрсә. Әгәр дә аңа Аллаһыдан бер шатлык килсә, ул шөкер итә, һәм ул аның өчен хәерле була. Әгәр дә киресенчә, аңа авырлык килсә, ул сабыр итә, һәм ахыргы чиктә бу аңа хәерле булып чыга».

Димәк, Пәйгамбәребезнең ﷺ югарыда язылган сүзләреннән аңлашыла: әлеге баскычта, башка төрле әйткәндә халәттә, булган кешеләр Аллаһы Тәгаләнең аларга карата тәкъдире нинди генә булса да, аны кайдадыр шөкерана, кайдадыр сабырлык белән каршы алалар. Әлеге хәлгә ия булган кешеләрне очрату сирәк күренеш булса да, бары бер дә юк, дип әйтмәс идем. Аллаһның рәхмәте белән барыбыз да шушы баскычка күтәрелергә һәм әлеге халәткә ия булырга тырышырга тиешбез.

3. Өченче баскыч. Аллаһны күргән кебек Аңа ышанучылар. Аллаһның ризалыгыннан башка бүтән бернәрсәгә дә омтылмаучылар. Без ничек итеп балаларыбызны, әти-әниләребезне, сөйгән ярларыбызны сөйгән булсак, алар исә Аллаһы Тәгаләне шулай яраталар. Бу халәт пәйгамбәрләргә һәм изге кешеләргә хас. Аллаһы Тәгалә изге Коръәнендә бу хакта шулай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا مَن يَرْتَدَّ مِنكُمْ عَن دِينِهِ فَسَوْفَ يَأْتِي اللَّهُ بِقَوْمٍ يُحِبُّهُمْ وَيُحِبُّونَهُ ﴿٥٤﴾

**«Әй иман китерүчеләр, сездән берегез диннән тайпылса, Аллаһы Тәгалә Үзе аларны яраткан, алар да Аны яраткан бер теркем кешеләрне (тайпылучылар урынына) китерер».**

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:54

Югарыда язылган «Вакыйга» сүрәсендә «изгелек ярышында беренче булучылар» дип нәкъ шушы кешеләр хакында әйтелгән. Өченче баскычка ирешкән кешеләр юк дәрәҗәдә, бик аз.

Ибраһим Әдһәм исемле бер изге кеше төш күрә. Төшендә бер фәрештә изгеләр исемлеген укып тора икән. Әдһәм хәзрәтләре әлеге фәрештәдән: «Ул дәфтәрдә минем исемем юкмы?» – дип сорый. «Синең исемең ничек? – дип сорап дәфтәргә баккач, – Синең исемеңне тапмадым. Ә син кем буласың?» – дип сорый фәрештә. «Мин изгеләрне сөюче», – ди Ибраһим Әдһәм. Шуннан соң фәрештә дәфтәрнең беренче битендә беренчеләрдән буларак «Ибраһим Әдһәм» дип язылган язуны күрә. Әйе, изгеләрдән булмасак та, изгеләрне сөяргә тырышыйк.

Хөрмәтле дустым, язылган сүзләргә нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: иманыбыз һәм эчке халәтебез өстендә эшлик. Хәзергә нинди баскычта булуыбызны аңлап, басып торган җирдән югарырак баскычка омтылыйк. Асылда Аллаһы Тәгалә безне шуның өчен якты дөньяда кеше итеп яратты. Хайваннарның бер урында тапталып торулары һәм рухи яктан үсә алмаулары гадәти хәл булса да, адәм баласы өчен исә килешә торган эш түгел. Аллаһы Тәгалә безне рухи яктан үстерә торган юлларга юлыктырсын. Әмиин.

*Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдин,*

*«Шамил» мәчете имам-хатыйбы*

*9 нчы июнь вәгазе,*

*Рамазан аеның 14 нче көне, һиҗри исәп буенча 1438 нче ел*

## Хакыйкый тәкъва

Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгаләгә хәмед-сәнәләребез, мактауларыбыз, Мөхәммәд Пәйгамбәргә ﷺ салават-шәрифләребез, сәламнәребез булса иде.

Аллаһы Тәгалә безгә: «Аллаһы каршында тәкъвалы булыгыз», – ди. Мөбарәк булган шушы җомга көнне Аллаһы Тәгаләне олылап, Аның нидасын, ягъни Коръән-Кәримдәге аятендә билгеләнгән: «Әй иман китергән бәндәләр! Җомга азанын ишетү белән, бөтен дөнья эшләрегезне ташлап, Аллаһы Тәгаләне зикер кылырга, Аллаһы Тәгаләне искә алырга дип, гыйбадәткә ашыгыгыз», – дигән чакыруын ишетеп, бирегә җыелган мөэмин-мөселман кардәшләребез. Һәрберебезгә дә Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгаләнең сәламе, ике дөнья рәхмәте һәм бәрәкәтләре булсын. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!

Аллаһы Тәгалә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ حَقَّ تُقَاتِهِ وَلَا تَمُوتُنَّ إِلَّا وَأَنتُم مُّسْلِمُونَ ﴿١٠٢﴾

**«Әй иман китергән бәндәләр, Аллаһы Тәгаләдән хакыйкый курку белән куркып, хакыйкый тәкъвалыкта булып, ахыр сулышыгызга кадәр мөэмин мөселман булып калыгыз»,** – дигән.

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:102

Нәрсә соң ул хакыйкый курку, хакыйкый тәкъвалык? Хакыйкый тәкъва дигәндә, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләрен, Аллаһы Тәгаләнең хәрамнарын, хәлалләрен аера белү; рәхмәтләрен һәм газапларын аера белү; Аллаһ Тәгаләдән безгә җибәрелгән рәхмәтен кабул итә белү күз

уңында тотыла. Ничек тә булса Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын эстәү, шуны табарга тырышу, шуңа омтылу, шуның белән яшәргә тырышу да ул.

Коръәндә әйтелгән:

﴿رَّضِيَ اللَّهُ عَنْهُمْ وَرَضُوا عَنْهُ ﴿١١٩﴾﴾

**«Аллаһы Тәгалә алардан риза булыр, һәм алар да Аллаһы Тәгаләдән риза булырлар».**

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:119

Бирედә «алардан» дип килә. Ягъни бу кешеләр Аллаһы Тәгалә биргән бөтен хөкемнәрне һич карусыз, һич шиксез, бер авырсынмыйча, бер дә ялкауланмыйча башкарып, шуны кабул итеп, Аллаһы Тәгалә риза булса иде дип йөрүчеләр, шуның белән яшәүчеләр. Менә шушы була тәкъвалык. Ни өчен Аллаһы Тәгалә бу дөньяда хәрамнарны булдырды? Адәм баласы үзен-үзе хәлакәткә салмасын өчен, үзен-үзе хәсрәткә салмасын өчен, хәрамнарны билгеләде һәм шулардан тыйды. Әгәр безгә хәрамны аңлатып, шулардан тыймаган булса, без адашып-саташып, бик күп ялгышлыклар кылган булыр идек, бик күп начарлыклар эшләгән булыр идек. Үзебезне үзебез юк иткән булыр идек. Хәтта инде Аллаһы Тәгалә бик газаплый торган, ачуы төшкән, газабы төшкән бер коллары булыр идек. Аллаһы Тәгалә безне ни өчен хәләлләр белән шушылай шатландырды? Менә бу сезгә ярдәм итәчәк, хәләл белән яшәсәгез, хәләлләрен дә исраф кылмасагыз, Аллаһы Тәгалә ризалыгын табарсыз, ди.

Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләрдән эчегез, ашагыз, әмма исраф кылмагыз. Аллаһы Тәгалә исраф кылучыларны яратмый. Кем дә кем Аллаһы Тәгалә каршында тәкъва булды, Аллаһы Тәгалә хәрамыннан сакланып, хәләленә омтылды, исраф кылмады исә, Аллаһы Тәгалә кушкан гыйбадәтләрдән ялкауланмады, иренмәде исә, Аллаһы Тәгалә аларны сөя, алар да Аллаһы Тәгаләгә мәхәббәт тота.

Кемнәр алар? Алар шушы туры юлда булганнар, тәкъва булган кешеләр. Хәтта Аллаһы Тәгалә андый кешеләрне ярата, андый кешеләргә мәхәббәтен төшерә, ди. Аларны һәрвакыт бәхеттә-сәгадәттә яшәтә, дөнья тормышларын да хәерле кыла, ахирәттә дә Үзенең хөрмәтен, рәхим-шәфкатен күрсәтәчәк, ди. Шуңа күрә, әгәр дә хәләл белән яшәсәләр, исраф кылмасалар, аларны Аллаһы Тәгалә ярата.

Хәтта тәкъвалык мәсьәләсенә килгәндә, Аллаһы Тәгаләдән «Әй иман китергән бәндәләр, Аллаһы Тәгаләдән хакыйкый курку белән куркыгыз...» аяте иңдерелгәч, сәхабәләр сорыйлар: «Ничек соң без ул хакыйкый тәкъва белән тәкъва булыйк? Хакыйкый курку ничек була соң?» Пәйгамбәребез ﷺ Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп: «Йә Раббым, кавемемә, өммәтемә бик авыр. Хакыйкый курку ничек була соң?» – дигәндә, Аллаһы Тәгаләдән башка бер аять иңде:

فَاتَّقُوا اللَّهَ مَا اسْتَطَعْتُمْ وَاسْمَعُوا وَأَطِيعُوا وَأَنفِقُوا خَيْرًا لِّأَنفُسِكُمْ ﴿١٦﴾

**«Аллаһыдан куркыгыз, Аңа гөнаһлы булудан сакланыгыз көчегез җиткән чаклы, ягъни Аллаһ тыйган гөнаһлы эшләрдән тыелырга көчегез җитә торып, тыелмыйча, һәм кушкан савaплы эшләрне көчегез җитә торып, эшләмичә, гөнаһлы булмагыз. Аллаһының сүзен ишетегез һәм итагать итегез, һәм малларыгыздан сәдакалар бирегез – бу эшләр үзегез өчен файдалыдыр».**

«Тәгабүн / Алдану», 64:16

Ягъни булдыра алганча куркыгыз. Һәркем үзенең күңелендә булганча, булдыра алганча курка Аллаһы Тәгаләдән.

Кемдер инде Аллаһы Тәгаләнең сүзен ишетеп, һушын югалтып, аңын җуеп егыла торган дәрәҗәгә җиткәндер, чөнки Аллаһы Тәгаләдән шулкадәр курка. Мәсәлән, Әбү Хәнифә берсендә гыйбадәттә мәшгуль булып утырган вакытта, бер наданрак кеше килә дә: «Йә Әбү Хәнифә, иттакулЛаһ!» – ди. Ягъни «Ий Әбү Хәнифә, Аллаһы Тәгаләдән курык!» –

ди. Шул вакыт Әбү Хәнифә «аһ» ди дә, куркуыннан аңын җуеп егыла. Куркуы шундый була. Тагы бер мисал: Фузаил ибн Иязнең улы Коръән укыган вакытта «Аллаһы Тәгаләнең газабы бик тә куркыныч» дигән аятькә килеп җиткәч, укый алмый, аңын җуеп егыла торган була. Шундый дәрәҗәдә курка Аллаһы Тәгаләдән. Фузаил ибн Ияз малаен берсенә Коръән өйрәтергә бирә. «Малаемны Коръән укырга өйрәт, ләкин бер аятькә, шушы газап турындагы аятькә җиткәч, саграк бул, Аллаһ сакласын, бер-бер хәл булмасын, Аллаһы Тәгаләдән бик каты курка, шуның кадәр бу аятьне күңеленә якын кабул итә», – ди укытучыга. Коръәнне өйрәткәндә, укып утырган вакытта, укытучысы моны онытып җибәрә, шушы аятькә, бу сүзләргә килеп җиткәч, малай «Аллаһ» дип кычкыра да, аңын җуеп егыла һәм шул рәвешле җан тәслим кыла.

Кемнәрдер «Аллаһыдан куркыгыз, Аңа гөнаһлы булудан сакланыгыз көчегез җиткән чаклы» сүзләрен ишеткәндә, хәтта үлер дәрәҗәдә куркалар. Кемдер, әлбәттә, Аллаһы Тәгаләдән куркып, хәрамнардан кача, алардан шулкадәр качып, нинди генә бер начарлык, явызлык эшләргә дә курка. Шулкадәр куркып, тирләп-пешеп, калтырый-калтырый утыра. Әмма инде кемдер хәтта аны «Аллаһы Тәгаләдән курык», дип кыйнап торсаң да, ул аны аңламый торган була. Андыйлар да була. Аллаһы Тәгаләнең шушындый сүзләреннән курыкмаучылар бар. Кайберләре үләр дәрәҗәдә куркырлар, кайберләре тирләп-пешеп, калтырап куркыр, кайберләре кыйнап торсаң да, Аллаһы Тәгаләнең газапларын күреп торса да, Аллаһы Тәгаләнең хәрамнарыннан качмый, хәләлләренә омтылмый, һәм булдыра алганча куркам, дигән булып, тел белән генә «мин куркам» дип әйтеп йөри, әмма курыкмый. Андыйлар да була.

«ИттакуЛлаһ» – Аллаһы Тәгаләнең шушы булган хөкемнәреннән куркырга, хөкемнәрен тота алмаудан куркырга кирәк. Иң беренче мөэмин мөселманга шуны аңларга кирәк – бу дөньядагы тормыш үтәчәк, ул фани. Мәңгелек ахирәт бар, киләчәк тормышыбыз бар. Бу дөньяда 90 ел яшәсәң

дә, 100 ел яшәсәң дә, үтә ул. Нух ﷺ 950 ел яшәде, ләкин: «Бу дөньяны ничек таптың соң, йә Нух?» – дип сорагач, «Бүлмәнең бер ишгеннән кердем дә, икенче ишектән чыгып киттем кебек», – ди. 950 ел яшәсә дә, бернәрсә күрә алмадым бу дөньяда, ди. Күпме генә яшәсәң дә, бу дөнья үтә торган, алдый торган, адәм баласын үзендә тотып калырга теләүче. Ни өчен үзенә игътибар иттертә? Аллаһы Тәгалә безне шушы дөнья белән сыныймы? Ахирәткә кергәндә, Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә әйтә бит, ихласлары гына, Аллаһы Тәгаләдән курыкканнары гына җәннәткә керер, ди. Армиядә хезмәт иткәндә дә учения – укулар, спорт белән шөгыльләнсәк тә, тренировкаларыбыз бар. Ни өчен? Ахырда куркып, югалып калмаска, ярышка чыкканда беренче булып килер өчен, җиңелмәс өчен, төшеп калмас өчен. Аллаһы Тәгалә дә безне шулай сыный. Ахирәттә Аның рәхмәтенә ирешер өчен. Әгәр без бу дөньяда, Аллаһы кушканча, үзенә күрә бер сынауларны үтә алмасак, үлгән вакытта шайтан каршыбызга килеп басыр да, бозлы салкын су күтәреп торыр. Моны Пәйгамбәребез ﷺ әйтеп калдыра. Үлеп барганда кешенең сусавы бик арта, бөтен тәне корый, авызлары кибә, бер йотым гына булса да су эчәр идем, дип интегә. Аның каршына сап-салкын су тотып, шайтан килеп баса. Шайтан: «Әгәр Аллаһы Тәгаләдән баш тартсаң, Мөхәммәдне ﷺ ялганчы дип әйтсәң, шушы суны бирәм», – дип әйтә. Менә шушы шайтанга бирешмәс өчен, без бу дөньяда тәкъвалык белән йөрибез, Аллаһы Тәгаләдән куркабыз, гөнаһлар кылсак, Ул безне җәзалар, бу дөньяда ук газаплар, дип уйлыйбыз. Күп очракта бу дөньяда гөнаһ кылучылар, көферлекләр кылучыларга берни булмаган кебек, ләкин аларның ахыр нәтиҗәләре бик куркыныч, ди. Аллаһы Тәгалә моны үлгән вакытта күренер, ди. Мондыйлар үлгән вакытта көферлектә китәрләр. Бер яктан, Аллаһы Тәгалә безне дөнья белән сыный, шушы дөньяга шайтанны җибәреп, бу дөньяга безне бәйли торган бер җебен – нәфес дигән нәрсәне, дөнья җебе белән нәфес җебен бәйли торган шайтанны булдырган. Ул безне бәйләп куя да, шушы дөньяда син

яшә, Аллаһы Тәгаләне күрмисең бит, ди. Әмма Пәйгамбәребез ﷺ: «Минем өммәтем нинди бәхетле өммәт. Ул Аллаһы Тәгаләне күрми инанган, иман китергән», – ди.

Хәтта Муса ﷺ Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать иткәндә, сөйләшкәндә Анының Мөхәммәд ﷺ өммәтен югары дәрәҗәгә күтәргәнен, мактавын белә. «Кемнәр соң алар, йә Раббым?» – ди. «Ишетәсеңме бер тавыш?» – дип сорый Аллаһ. «Бу нинди матур тавыш? Дөньяда мин мондый тавыш ишеткәнем юк», – ди Муса ﷺ. «Бу – Аллаһыны зикер итүчеләр. Мөхәммәд ﷺ өммәтенең зикер итүчеләренең тавышы бу», – ди Аллаһ. «Каян килә соң ул?» – дип сорый Муса. «Әлегә алар сезнең билләрегездә. Чөнки Адәм баласының нәселе әтиләренең билләреннән чыккан су белән дәвам итә. Югарыга кара, йә Муса», – ди Аллаһ. Югарыга башын күтәреп караса, Аллаһы Тәгалә күк капусын ача, җәннәтләрне күрсәтә. Шунда йолдызлар, ай кебек бик нурланып, ялтырап тора торган бихисап күп сарайлар күрә. «Бу нәрсәләр соң?» – ди. «Бу – Мөхәммәд ﷺ өммәтенең урыннары», – ди Аллаһ. «Йә Раббым, алар бөтенесе дә җәннәткә керәчәкләрме соң?» – дип сорый Муса. «Бөтенесе дә керәчәкләр. Хәтта җәһәннәмгә кергәннәм соң да, иң соңгысы булып, гомерендә «лә иләәһә илләЛлаһ Мөхәммәдер-расүлүллаһ» дип ихлас күңелдән бер генә тапкыр әйткән булса да, Миннән аны да аларның пәйгамбәрләре, расүле, Минем хәбибем Мөхәммәд шәфәгать кылып, җәһәннәмнең төбеннән чыгарып, җәннәткә кертергә сораячак», – ди Аллаһ. «Йә Раббым, мине дә шушы өммәттән кылсаң иде», – ди Муса ﷺ. «Синең үзеңнең өммәтең бар, Муса. Син өммәтеңне җитәкләп бар. Әмма Мөхәммәднең ﷺ өммәте кереп беткәч, син иң соңгысы булып керерсең», – ди. Ибраһим ﷺ дә, Муса ﷺ дә Аллаһы Тәгаләдән Мөхәммәд ﷺ өммәтеннән булсак иде, дип сораганнарына: «Булырсыз, аларның өммәтеннән булып, алар белән бергә керерсез», – ди. Бу риваятьләр аять-хәдисләр белән Әнвәр Гашыйкый китапларында да күрсәтелә. Ягъни Аллаһ Тәгалә шулкадәр олылады, шулкадәр зур-

лады безнең өммәтебезне. Шуңа да иман китерүче бәндәләргә Аллаһы Тәгаләдән куркыгыз, ди. Һәм дөньяда да, ахирәттә дә шулкадәр җиңүче булырсыз, ягъни Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешерсез, ахирәтегез дә, дөньягыз да ялтырап торыр, бәхетле булыр, ди.

Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә һәрберебезгә дә туры юлда булуыбызны насыйп итсә иде.

*Илдус хәзрәт Фәиз,*

*«Болгар» мәчете имам-хатыйбы*

*16 нчы июнь вәгазе,*

*Рамазан аеның 21 нче көне, һиҗри исәп буенча 1438 нче ел*

# Кадер кичәсе

Рамазан аен ел буе сагынып көтсәң дә, изге көннәр сизелми дә үтә. Көн арты көн Раббысына тугры бәндә кадерле вакытларны изге гамәл, Коръән укуга багышлый. Тоткан руза калебләрне йомшарта, торган кыямнар сабыр, әхлаклы итә, укыган аятьләр гафиллектән уята. Тән итагать кыла, тел зикер итә, җан уйлана, гыйбрәт ала.

Кунакның китәр вакытлары җиткәч, кадере арта. Шулай ук Рамазанның ахыргы 10 көне дә безнең өчен аеруча гыйззәтле. Ул көннәрдә иман әһеленең изгелекләре өстәлә, «Рәхмәтенә ирешермен, гөнаһымнан пакьләнермен, уттан котылырмын», – дигән өметләр арта. Гаишә ﵂ әйтте: «Аллаһ Илчесе Рамазанның ахыргы ун көнендә башка көннәргә караганда ныграк иҗтиһад, тырышлык күрсәтте»[1].

Пәйгамбәребез ﷺ ул көннәр турында болай дигән: «Рамазаның ахыргы 10 көне – ул Җәһәннәм газабыннан котылу көннәре»[2].

Рамазан ае бәгыренең иң күркәм почмагында Коръән иңдерелгән Кадер кичәсен яшереп тота. Бер орлыктан үсеп чыккан агачта меңләгән җимешләр җитешкән кебек, Кадер кичәсенә дә мең ай йөкләнгән.

Бу кичәдә әҗер-саваплар бергә – мең бәрабәрендә языла. Бу кичәнең тулы кадерен һәм кыйммәтен бары ачлыктан нечкәрә-нечкәрә сизгерләнгән күңелләр генә аңлый һәм тоя ала. Аллаһы Тәгалә әйткән:

إِنَّا أَنزَلْنَاهُ فِي لَيْلَةِ الْقَدْرِ ﴿١﴾ وَمَا أَدْرَاكَ مَا لَيْلَةُ الْقَدْرِ ﴿٢﴾ لَيْلَةُ الْقَدْرِ خَيْرٌ مِّنْ أَلْفِ شَهْرٍ ﴿٣﴾ تَنَزَّلُ الْمَلَائِكَةُ وَالرُّوحُ فِيهَا بِإِذْنِ رَبِّهِم مِّن كُلِّ أَمْرٍ ﴿٤﴾

---

1 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

2 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

سَلَامٌ هِيَ حَتَّىٰ مَطْلَعِ الْفَجْرِ ﴿٥﴾

**«Хактыр ки, Без Коръәнне (Ләүхел-мәхфүздән дөнья күгенә) Кадер кичендә төшердек. Сиңа Кадер киче дигәне нәрсәне белдерә? Кадер киче – мең айдан да хәерлерәктер. Ул кичтә һәртөрле эш өчен, Раббыларының рөхсәте белән фәрештәләр һәм Җәбраил ﷺ иңәр. Ул төннең таңына кадәр иминлек, сәламәтлек булыр».**

«Кадер / Кадер Киче», 97:1-5

Ни өчен соң ул төн «Кадер киче» дип аталды?

Кадер – «кодрәт» ул, бу төн Аллаһ каршында иң кодрәтле һәм иң хөрмәтле төндер. Аның икенче мәгънәсе – «тәкъдир», бу төндә ел әйләнәсенең язмышы тәкъдир кылына. Аллаһ Тәгалә әйтте:

فِيهَا يُفْرَقُ كُلُّ أَمْرٍ حَكِيمٍ ﴿٤﴾

**«Ул төндә һәрбер хикмәтле эш бүленә».**

«Духан / Төтен», 44:4

Бу кичәдә фәрештәләр адәм баласының берьеллык тәкъдирен алып киләләр. Соңра Кадер төнен Коръән иңү белән үзенчәлекле иткән Аллаһ ул төннең тагын бер өстенлеген бәян итеп: «Кадер төне мең айдан хәерлерәк», – дия. Ул төнне догада, гыйбадәттә, зикердә, намазда үткәргән бәндә мең ай гыйбадәт кылудан да зуррак әҗер алачактыр. Мең ай ул 83 ел һәм 4 ай була.

Ул төндә җир йөзенә Аллаһ кешеләргә тәкъдир кылган һәрбер яхшы вә яман эш белән Җәбраил ﷺ һәм башка фәрештәләр төшәләр. «Ул таң беленгәнче иминлектер». Ягъни Кадер төнендә җир өстенә төшкән фәрештәләр бәрәкәт, тынычлык һәм хәерлелек белән төшәләр. Бигрәк тә ул фәрештәләр Коръән укучылар, Аллаһны зикер итүчеләр һәм гыйлем

эстәүчеләр белән бергә булалар. Шайтан да ул төнне үзенең мәкерлекләрен кыла алмый.

Кадер төне кайчан була?

Мөселманнар өчен айлар арасында Рамазан ае, көннәр арасында җомга көне, кичләр арасында Кадер кичәсе иң мөбарәк санала. Кадер кичәсе Рамазан шәриф аенда булган бер кичәдер. Шул ук вакытта Рамазанның кайсы кичәсендә булганы төгәл һәм анык рәвештә билгеләнмәгән. Бу мәсьәләдә галимнәр төрле фикердә.

Пәйгамбәребез әйткән: «Кадер төне – Рамазанның ахыргы ун төнендә. Кем аларны уяу үткәрә, Аллаһ аның кылган һәм кылачак гөнаһларын кичерә. Бу да так санлы төндә. Тугызынчы, жиденче, бишенче яки өченчесендә».

Күбесе егерме жидесендә дигән фикердә, чөнки Пәйгамбәребез ﷺ мөбарәк төнне соңгы ун төннән эзләде. Расүлүллаһ ﷺ әйткән: «Кадер кичәсен эзләүче кеше аны егерме җиденче төнендә эзләсен»[1].

Әбү Зәрр ﷺ: «Без Рамазан аенда Расүлүллаһ ﷺ белән бергә ураза тотканда, уразаның соңгы җиде көне калган иде. Һәм егерме өченче төнгә каршы ул безнең янга төн уртасында намаз укырга чыкты. Егерме дүртенче төнгә каршы ул безнең янга чыкмады, ә егерме бишенчесенә каршы төн уртасында чыкты. Аннары мин аңа: «Расүлүллаһ! Бәлки сиңа төнге намазны үткәрергәдер?» – дидем. Расүлүллаһ ﷺ: «Әгәр бу төнне берәр кеше имамга ияреп намаз укыса, бу – төне буе укыган намазга тиң була», – дип җавап бирде. Расүлүллаһ ﷺ егерме алтынчы төнгә каршы безнең янга чыкмады. Төннәрнең егерме җиденчесенә каршы ул үзенең хатыннарын, гаилә әгъзаларын һәм башка кешеләрне җыйды, һәм намазны шундый озак итеп укыды ки, хәтта без сәхәр ашауны калдырудан курыктык. Калган төннәрдә ул безнең янга чыкмады», – дип риваять кылган[2].

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

2 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

Кадер төненең үз галәмәтләре бар.

Галимнәр билгеләп үткәнчә, Кадер кичәсен кайбер галәмәтләрдән, шул кичкә хас булган аерым билгеләрдән, тәгаенләргә мөмкин: бу кичә нурлы, тыныч һәм матур булыр; бик салкын да булмас, бик эссе дә булмас; ул кичтә болытлар йөрмәс һәм җил исмәс, һавадан йолдызлар атылмас, яңгыр яумас, барча җиһанда тылсымлы тынлык урнашыр. Шул төн арты кояш нурсыз пакь тулы ай кебек чыгар.

Кадер кичәсе гыйбадәте.

Бу кичә Аллаһның рәхмәте бик мул булган бер кичәдер. Көндез ихтыяҗы булганнарга мөмкин кадәр ярдәм итәргә, авыз ачканда фәкыйрьләрне ашатып-эчерергә, кичен Коръән укып, гыйбадәт кылып үткәрергә кирәк. Гыйбадәттә каза намазын кылу, Коръән-Кәримнән сүрәләр, догалар уку, тәүбә итү, сәдака бирү, мөселманнарны сөендерү һәм башка саваплар казану – болар барысы да бу кичәгә хөрмәт күрсәтүнең ишарәседер. Хөрмәт күрсәтү гөнаһлы эшләрне эшләмәү белән дә хасил булыр.

Расүлүллаһ ﷺ әйткән: «Әгәр берәү, Аллаһы Тәгаләгә инанып һәм савабына өметләнеп, Кадер кичәсен гыйбадәт кылып уздырса, элек кылган гөнаһлары гафу ителәчәк»[1].

Шулай ук кайбер риваятьләрдә Кадер кичәсендә иң азы – ике рәкәгать, уртача – йөз рәкәгать, ә иң күбе – бер мең рәкәгатьле намаз укылуы хәбәр ителә[2].

Бу намаз бары ике рәкәгатьтән торса, «Әл-Фәтиха» сүрәсеннән соң һәр рәкәгатьтә ике йөзешәр аять уку кирәк. Бу намаз йөз рәкәгатьтән укылса, «Әл-Фәтиха» сүрәсеннән соң һәр рәкәгатьтә бер тапкыр «Әл-Кадер» һәм өч тапкыр «Әл-Ихлас» укылырга тиеш. Һәр рәкәгатьтән соң Пәйгамбәребез ﷺ Гайшәгә رضي الله عنها өйрәтеп калдырган әлеге доганы укырга кирәк:

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

2 Исмәгыйл Хаккы, Рухүл-бәян, 10/372

اللَّهُمَّ اِنَّكَ عَفُوٌّ تُحِبُّ الْعَفْوَ فَاعْفُ عَنِّي

**Әллаһуммә иннәкә гәфүввун түхиббуль гәфвә фәәгфугәнни**

«Йә Аллаһ! Син – Гафу итүче һәм (гөнаһлы бәндәләреңне) гафу итәргә яратасың. Гафу итче мине!»[1]

Бу намазны нәкъ шушы рәвешле уку мәҗбүри түгел, әмма аны шушылай уку мәслихәт булуын хәбәр итүче риваятьләр бар. Төп максат булып исә мөселманнарның бу төнне гыйбадәт һәм зикердә үткәрүе тора.

Пәйгамбәрбез ﷺ, дүрт хәлифә ﷺ һәм соңыннан бөтен Ислам дәүләтләре бу кичәгә олуг хөрмәт күрсәткәннәр, гыйбадәттә үткәргәннәр.

Болгар бабаларыбыз заманында бу кичәдә мәмләкәтнең һәр җирендәге бөтен күңел ачу урыннары ябылган. Казан ханнары «Кол Шәриф» мәчетенә һәм башка мәчетләрдә сәхәргә кадәр гыйбадәт итеп, гафу ителүләре өчен Җәнабе Хакка догада булганнар.

Кадер кичәсендә Аллаһ адәмнәренең югары рухи хисләренә торышлы күренешләр насыйп итәр. Бу кичәдә күңел күзләренә иләһи нурдан сөрмә тарткан саф мөэминнәр хакыйкать офыкларының йолдызлары кебектер.

Безне Рамазаныбызда саулык-сәламәтлектә кавыштырган Аллаһыбызга мактау, зурлауларыбыз вә шөкерләребез булсын! Тагын да күп еллар дәвамында Рамазаннар морадына ирешергә насыйп әйләсен. Әмин!

*«Хозур» редакциясе*

---

[1] Ибн Мәҗә, Дога: 5, №3850, 2/1265

*23 нче июнь вәгазе,*

*Рамазан аеның 28 нче көне, һиҗри исәп буенча 1438 нче ел*

## Дөнья һәм ахирәт өчен тырышу

Бөтен шөкер-рәхмәтләребез, чиксез мактау-сәнәләребез, олуглауларыбыз галәмнәрнең Хуҗасына, көдрәт Иясенә, безне юктан бар итеп, шушы дөньяның хәлифәсе итүчегә, тәрбия кылучыга – Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгаләгә генә булсын иде.

Аның илчесенә, пәйгамбәрләрнең дә иң нурлысына, шушы дөньяларга, дөнья мәктәбенә, мәдрәсәсенә соңгы пәйгамбәр булып җибәрелгән, бөтен кешелек дөньясының, битенә, төсенә, малына карамыйча, дәрәҗәсенә игътибар итмичә, һидәяткә, хаклыкка чакырган; көннәрен һәм төннәрен гыйбадәттә үткәреп, өммәте өчен күп күз яшьләрен түгеп кайгыручыга, җәннәт юлына өндәүче пәйгамбәр Мөхәммәдкә ﷺ күңел түреннән ихлас салават-шәрифәләребезне дә Раббыбыз ирештерсен иде.

Әлбәттә, газиз дин кардәшләрем, дөнья ул яктылык, тереклек галәме, маңгай күзе белән күзәтелгән табигать тормышы, ул да булса Раббыбыз тарафыннан вакытлыча гына бирелгән зур нигъмәтләрнең берсе. Һәм дә Раббыбызның нигъмәтләре чиксездер, шуларның берсе – без кешеләрне дөньяда һәм ахирәттә бәхетле булуыбызга сәбәп булган олуг нигъмәт, гыйлем нигъмәте. Һәм дә Коръәни-Кәримнең иң беренче, иң алдан иңгән аятьләре, шушы нигъмәтнең әһәмиятен ачыклый торган аятьләр:

**اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ ﴿١﴾ خَلَقَ الْإِنسَانَ مِنْ عَلَقٍ ﴿٢﴾ اقْرَأْ وَرَبُّكَ الْأَكْرَمُ ﴿٣﴾ الَّذِي عَلَّمَ بِالْقَلَمِ ﴿٤﴾ عَلَّمَ الْإِنسَانَ مَا لَمْ يَعْلَمْ ﴿٥﴾**

**«(Ий Мөхәммәд), (Коръәнне) укы һәрнәрсәне халык кылучы Раббың исеме илә! Ул халык кылды кешене оешкан каннан. Укы,**

**синең Раббың – Аллаһ – бик хөрмәтле вә юмарттыр. Ул – Аллаһ – каләм белән язуны өйрәтте. Кешегә белмәгән нәрсәләрен өйрәтте».**

«Галәк», 96:1–5

«Укы!» – Җәбраил ﷵ шушы әмерне Пәйгамбәр ﷺ янына килеп җиткерде. Менә Раббыбыз бәндәләренә, шушы дөньяда Үзе белән таныштырыр өчен, гыйлем бирә. Аллаһ Раббыбызның исемнәре, сыйфатлары, көдрәте аркылы, Аның Галәмдәге нигъмәтләрен өйрәнеп-танып, танышабыз Аның белән. Аллаһ Тәгалә безне Үзенең расүлләре, пәйгамбәрләре белән таныштыра. Үзебезнең күзләребез гаҗиз калган, күрә алмаган фәрештәләр, җеннәр дөньясы белән таныштыра. Һәм Аллаһ Раббыбыз хак гыйлем аша шуларны үзебезнең күзләребез белән барып, күреп кайткан кебек итеп җәннәт һәм җәһәннәме белән таныштыра. Җәннәткә омтылырга һәм җәһәннәмнән качарга өйрәтә. Кешеләргә дөрес яшәргә, үзара дөрес мөгамәлә корырга дип, шәригать кагыйдәләре билгеләнгән. Аллаһ Тәгалә безне Үзенең Китабы Коръәни-Кәримдә әйләнә-тирә, ягъни күкләр, йолдызлар, җирдә яшәгән хайваннар, кошлар, үсемлекләр дөньясы һәм башка затлар белән дә таныштыра.

Раббыбыз адәм балаларын нинди максат белән бар иткән соң, дигән сорауны да искә төшерик. Бу сорауга без төрле җаваплар ишетә алабыз: дөньядагы тормыш – гаилә кору максатына ирешү, дигән кешеләр дә күп; хәерле кеше була белү, балалар тәрбияләү, һәм башка фикерләр дә әйтелә. Алары да хата түгел, әммә хакыйкатьтә Аллаһы Тәгалә безне бер асыл максат белән халык итте, яратты димәк. Ул да булса:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

**«Кеше илә җеннәрне Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен генә халык кылдым»,** – ди Аллаһы Тәгалә.

«Зарият / Таратучы», 51:56

Менә бу һәрбер кешенең максатларының асылы булып торырга тиеш. Чөнки бездән Кыямәт көнендә Раббыбыз каршысында сорала торган нәрсә – ул да безнең гыйбадәтебез, намазыбыз. Гыйбадәт ул бик тирән мәгънәне ачыклый. Һәрбер гыйбадәт җирдә Җәбраил фәрештә аша иңдерелгән булса, намазыбыз ул инде җиде күк өстендә әмер ителде.

Мисал өчен, безләргә гыйбрәт булган, чын мәгънәсендә ахирәткә омтылырга өйрәтүче пәйгамбәр Мөхәммәдтән ﷺ 200–300 елдан соң яшәгән олуг шәхесләребез тормышыннан өзекләрне искә төшерәсем килә. Әүлияләрнең берсе, димәк Аллаһка якын булган бәндәләренең берсе, Ибраһим Әл-Әдһәмнең тормышыннан. Фәлән кеше күп вакытлар төрле-төрле имамнар, хәзрәтләр янында булганнан соң, Ибраһим Әл-Әдһәм янына да килеп җитә һәм шундый сораулар бирә: «Хөрмәтле хәзрәтем, мин бик гөнаһлы кеше, күз алдына нинди гөнаһ килә, шуларны эшләгән кеше, һәм аларны дәвам итүчеләрдән мин», – ди. «Мин күп хәзрәтләр янында булдым, әмма барысы да бер үк җавап кайтардылар, мин хәзер синең яныңа килдем. Әй хөрмәтле хәзрәтем, миңа шушы гөнаһларны дәвам итәргә рөхсәт бир әле», – дип дәвам итә. Ибраһим Әл-Әдһәм елмая да, алты төрле шарт әйтә. Әгәр дә шуларның берсен үтәсәң, нинди бозык эшкә күңелең тартса, шуны кыл, ди. Шартлары мондый була:

1. Аллаһ Тәгалә сине күрмәс бер урын тап.

2. Аллаһныкы булмаган бер җир тап.

3. Тап шундый ризык, ул Аллаһның ризыгы булмасын.

4. Газраил фәрештәдән عليه السلام качып кара, мөгамәлә кор аның белән, минем әлегә яшисем килә, дип әйт.

5. Кабергә кергәч, анда якыннарың сине бер ялгызыңны калдырып китkәч, җавап алырга килгән Мөнкир белән Нәкир фәрештәләрнең сорауларына җавап кайтарма, борыл да кирегә ят үз урыныңа.

6. Кыямәт көнендә сине түбәнчелек белән җәһәннәмгә таба алып барганда, син тукта да, минем анда барасым килми, дип әйт аларга, һәм борыл да, җәннәткә таба кит.

Шушы сүзләрдән, шартлардан соң теге кеше бик тирән уйларга бата һәм бу шартларның берсен дә үти алмаганын аңлап, кылган хаталарына тәүбә итүен аңлый. Ибраһим Әл-Әдһәмгә тәүбәгә килүен әйткәннән соң, бу кеше киләчәктә шулай ук дини гыйлем алырга омтыла, зур галимнәр санынан булып кала.

Икенче мисал итеп моннан йөз еллар элек, революциягә кадәр яшәгән күренекле галимнәребезнең берсе – Зәйнулла ишан Расулевны искә төшерәсем килә. Ул Троицк шәһәрендә яшәп, дингә хезмәт иткән мәшһүр шәхесләребезнең берсе булып тора. Көннәрнең бер көнендә аның янына шулай ук бер кеше килә, һәм шундый сорау бирә: «Әй Зәйнулла ишан, хәзерге вакытта мәчетләр, мәдрәсәләр күп, әмма кешеләрнең үзгәрүе һаман сизелми». Зәйнулла ишан елмаеп куя да, болай дип әйтә: «Сине сабыннар, шампуньнар чыгара торган заводның хуҗасы дип беләм. Бу эш белән башта әтиеңнең әтисе, аннары әтиең, хәзер инде син шөгыльләнәсең. Менә кара инде, дустым, ерактa гына бер сабый бала уйнын-уйный пычранган ди, ә син сабыннар чыгарсаң да, аның хәзер өсте пычрак. Моңа ни әйтәсең инде?» «Әлбәттә, ул бит миңа килми. Миннән сабыннар сатып алмый, шуңа күрә ул шулай пычранган», – дип җавап кайтара теге кеше. «Кардәшем, мәчетләр һәм мәдрәсәләр Аллаһка гыйбадәт кылып, Аның динен өйрәнә торган биналар. Һәм без, шуңа да карамастан, шушы биналарга килмәсәк, йөрмәсәк, бездә дә үзгәреш булмас», – ди ишан. Шуннан теге кеше Зәйнулла ишанга мөрәҗәгать итеп әйтә: «Хәзер бит бөтенесе дә акчага. Акча булган кешедә генә тынычлык, аны гына хөрмәт итәләр. Акча булмаганда хөрмәт тә юк. Минем гыйбадәткә вакытым да юк, көн-төн шуның турында гына уйлыйм», – ди. Шуннан соң да Зәйнулла ишан Расулев елмая да, бик хикмәтле сүзләр

әйтә: «Аннары син үзең үзеңә җавабын табарсың. Кардәшем, акчага син бик эшчән, сиңа хезмәт итәчәк кешеләр яллый аласың, әмма чын дуслыкны сатып алалмыйсың. Акчага син зур сарай сатып ала аласың, әмма аның эчендәге тынычлыкны син сатып ала алмыйсың. Син үзеңә рәхәтлек китерер өчен зур карават, мендәрләр сатып ала аласың, әмма йокыны син сатып алалмыйсың. Үзеңә теләгән тәмле ризыклар сатып ала аласың, әммә аппетит сатып алып булмый. Акчага син бик кыйммәтле дару сатып ала алырсың, әмма шифаны сатып алалмассың. Хәзер инде уйла, барысы да акчага икәнме?»

Шулай, дин кардәшләрем, без дә гөнаһ кылудан, хәрамнан, дөнья тормышыбызны гына кайгыртудан сакланып, Аллаһ Тәгаләбез безне нинди максат белән яратканын онытмый, гыйбадәтләребезне арттырып, дини һәм дөньяви гыйлем алырга омтылып, ахирәт тормышыбыз турында беркайчан онытмый, һәрдаим фирдәвес җәннәтләренә бер адым ясап торып, мөэмин-мөселманнардан булсак иде. Бу вакытлы гына дөньябызда Аллаһ Раббыбыз безгә күпсанлы аятьләр, ягъни билгеләр, күрсәтә. Шуларны күреп, фикер йөртеп, Пәйгамбәребез ﷺ, күренекле галимнәребез һәм әүлияләребез холкын үзебезгә үрнәккә куеп, шушы мисалларга омтылсак иде!

*Азат Галимов,*

*Казан Ислам университетының*

*Шәригать бүлеге шәкерте*

# Ураза гаете хөтбәсенең гарәпчә укылышы

خطبة عيد رمضان

بِسْــمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

اَللهُ أَكْبَرُ اَللهُ أَكْبَرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَاللهُ أَكْبَرُ اَللهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ سُبْحَانَ مَنْ نَوَّرَ قُلُوبَ الْعَارِفِينَ بِنُورِ الْمَعْرِفَةِ وَالْإِيمَانِ وَشَرَحَ صُدُورَ الصَّادِقِينَ بِشَرْحِ الْهِدَايَةِ وَالْعِرْفَانِ وَأَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِصِيَامِ شَهْرِ رَمَضَانَ ۞ اَللهُ أَكْبَرُ اَللهُ أَكْبَرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَاللهُ أَكْبَرُ اَللهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ سُبْحَانَ مَنْ فَتَحَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ الرَّحْمَةِ وَالْغُفْرَانِ وَغَلَّقَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ النِّيرَانِ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ۞ وَعَدَ لِلصَّائِمِينَ دُخُولَ بَابٍ مِنْ أَبْوَابِ الْجِنَانِ كَمَا أَخْبَرَنَا نَبِيُّنَا نَبِيُّ آخِرِ الزَّمَانِ: إِنَّ لِلْجَنَّةِ بَابًا يُقَالُ لَهُ الرَّيَّانُ لاَ يَدْخُلُهُ إِلاَّ الصَّائِمُونَ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ، شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنْزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ۞ اَللهُ أَكْبَرُ اَللهُ أَكْبَرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ اَللهُ أَكْبَرُ اَللهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ وَأَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ ذُوالْعَفْوِ وَالْغُفْرَانِ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى آلِهِ وَأَصْحَابِهِ صَلاَةً مُوصِلَةً إِلَى دَارِ الْجِنَانِ ۞ أَيُّهَا النَّاسُ، أُوصِيكُمْ عِبَادَ اللهِ وَنَفْسِي أَوَّلاً بِتَقْوَى اللهِ ۞ أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ ۞ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوا وَّالَّذِينَ هُم مُّحْسِنُونَ ۞ بَارَكَ اللهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرْآنِ الْعَظِيمِ وَنَفَعَنَا وَإِيَّاكُمْ بِالْآيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَّادُ الْكَرِيمُ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ السَّمِيعُ الدُّعَاءِ

خطبة ثانية

إِنَّ الْحَمْدَ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذُ بِاللهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ ۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَى جَمِيعِ الْأَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلاَئِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى عِبَادِكَ الصَّالِحِينَ وَعَلَى أَهْلِ طَاعَتِكَ أَجْمَعِينَ مِنْ أَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرَضِينَ ۞ اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ وَارْحَمْنَا مَعَهُمْ وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

## Ураза гаете хөтбәсенең кириллицага транслитерациясе

### Беренче хөтбә

**Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим**

**Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһү үәллааһү әкбәр, Аллаһу әкбәр, үә лилләәһил-хәмде. Сүбхәәнә мән нәүүәра кулүүбәл-гәәрифиинә би нуурил-мәгърифәти үәл-иимәән, үә шәрахә судүүрас-саадикыынә би шәрхил-һидәәйәти үәл-гирфәән, үә әкрамә гибәәдәһүл-мү’миниинә би сыйәәми шәһри рамәдаан. Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһү үәллааһү әкбәр, Аллаһу әкбәр, үә лилләәһил-хәмд. Сүбхәәнә мән фәтәхә гәләс-саа’имиинә әбүәәбәр-рахмәти үәл-гуфраан, үә галләка гәләс-саа’имиинә әбүәәбән-ниираани фи шәһри рамәдаан. Үәгадә лис-саа’имиинә дүхуулә бәәбин мин әбүәәбил-җинәәни кәмәә әхъбәранәә нәбиййүнәә нәбиййү әәхириз-зәмәән: иннә лил-җәннәти**

**бәәбән йүкаалү ләһүр-раййәән. Ләә йәдхулүүһү илләс-саа'имүүнә фии шәһри рамәдаан. Шәһрү рамәдаанәлләҙии үнзилә фииһил-куръәәнү һүдәл-линнәәси үә бәййинәәтин минәл һүдәә үәл-фүркаан, Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһү үәллааһү әкбәр, Аллаһу әкбәр, үә лилләәһил-хәмд. Үә әшһәдү әлләә иләәһә илләллаһү үәхдәһүү ләә шәриикә ләһүү ҙүл-гәфьүи үәл-гуфраан, үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһүү үә расүүлүһүү. Салләллааһү Тәгаалә галәйһи үә гәләә әәлиһи үә әсхәәбиһи саләәтән-мүүсыйләтән иләә дәәрил-җинәән.**

**Әййүһәннәәс, үүсыыкүм гибәәдәллааһи үә нәфсии әүүәлән-битәкъүәллааһ. Әгууҙу билләәһи минә шәйтаанир-раҗиим, бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим. Иннәллааһә мәгәлләҙиинәт-тәкау үәлләҙиинә һүм мүхсинүүн. Бәәракәллааһү ләнәә үә ләкүм фил-куръәәнил-газыйим, үә нәфәганәә үә иййәәкүм бил-әәйәәти үәҙҙикрил-хәкиим, иннәһүү һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүл-галиййүл-газыйиму сәмиигуд-дүгаа'.**

## Икенче хөтбә

**Иннәл-хәмдә лилләәһи нәхмәдүһүү үә нәстәгыйнүһү үә нәстәгъфируһү үә нуъ'минү биһи үә нәтәүәккәлү галәйһи үә нәгууҙү билләәһи мин шүруури әнфүсинәә үә мин сәййиәәти әгъмәәлинәә мән йәһдииһилләәһү фәләә мүдыллә ләһү үә мән йүдълилһү фәләә һәәдиә ләһ. Үә әшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһү үәхдәһүү ләә шәриикә ләһ, үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһүү үә расүүлүһ. Аллаһүммә салли үә сәллим гәләә җәмигыль-әнбийәә'и үәл-мүрсәлиин, үә гәләә мәләә'икәтикәл-мүкаррабиин. Үә гәләә гыйбәәдикәс-саалихын, үә гәләә әһли таагатикә әҗмәгыын, мин әһлис-сәмәүәәти үәл-арадыын. Аллаһүммә-гъфир лилмү'миниинә үәл-мү'минәәт, үәл-мүслимиинә, үәл-мүслимәәт, әл-әхъйәәи минһүм үәл-әмъүәәт, үәрхәмнәә мәгәһүм. Үәхшүрнәә мәгәһүм бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин.**

# Ураза гаете хөтбәсенең татарчага тәрҗемәсе

## Беренче хөтбә

Мәрхәмәтле, шәфкатьле Аллаһы исеме белән.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыга гына мактау. Аллаһыга якынаючыларның (гарифләрнең) күңелләрен (калебләрен) мәгърифәт (ярлыкау) һәм иман нуры белән нурландырган, тугърыларның (садыйкларның) күңелләрен һидәят һәм белем белән ачкан, мөэмин колларына Рамазан ае уразасын бүләк иткән зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Рамазан аенда ураза тотучыларга рәхмәт һәм мәгъфирәт (гөнаһларны гафу итү) ишекләрен ачкан һәм ут ишекләрен бикләгән зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Ул (Аллаһы) ураза тотучыларга җәннәт ишекләренең берсе аша керүне вәгъдә иткәндер. Бу турыда безгә пәйгамбәребез, ахырзаман пәйгамбәре хәбәр иткән: «Чынбарлыкта, җәннәтнең бер ишеге бардыр, аңа «Раян» диелә. Ул ишектән Рамазан аенда ураза тотучылардан башка беркем дә кермәс». Аллаһы Коръәндә әйтә: «Рамазан ае кешеләргә тугры юл күрсәтүче, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр». Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк, Ул гафу итүче һәм мәгъфирәт иясе (гөнаһларны каплаучы) икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд – Аның колы һәм расүле икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аңа, аның гаиләсенә, сахабәләренә Аллаһы Тәгаләдән булган җәннәт йортларына илтә торган салават ирешсен. Әй кешеләр! Аллаһының коллары, сезгә һәм үземә дә тәкъвалы булырга васыять итәм. Таш белән атылган шайтаннан Аллаһыга сыгынам. Рәхимле, шәфкатьле Аллаһы исеме белән. Аллаһы Коръәндә

әйтә: «Чынбарлыкта, Аллаһы тәквалылар һәм игелек кылучылар белән бергә». Аллаһы безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Чынбарлыкта Ул (Аллаһы) гафу итүче, рәхимле, юмартлык иясе, олуглык иясе, бөек зат һәм догаларны ишетүче, кабул итүче.

## Икенче хөтбә

Чынбарлыкта, барча мактау Аллаһыга, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аннан гөнаһларыбызны гафу итүен сорыйбыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Аллаһыга үзебезнең начарлыкларыбыздан, гамәлләребезнең бозыклыкларыннан сыгынабыз. Кемгә Аллаһы Тәгалә һидәят бирсә – аны адаштыручы булмас, ә кемне адаштырса – аны туры юлга күндерүче булмас. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд – Аның колы һәм хак илчесе икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аллаһым, бөтен пәйгамбәрләргә, илчеләргә, Үзеңә якынайтылган фәрештәләреңә, Үзеңнең изгелек кылучы колларыңа һәм Сиңа итагать итүче әһелләрнең һәммәсенә – булсыннар алар күк әһелләреннән һәм булсыннар алар җир әһелләреннән – барчасына салават һәм сәлам ирештер. Аллаһым, мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, алар арасыннан исән вә вафат булганнарын мәгъфирәтең белән гафу ит. Алар белән берлектә безгә рәхимле бул һәм безне Үз рәхмәтең илә алар белән бергә булырга насыйп ит. Йә рәхимлеләрнең иң рәхимлесе.

*25 нче июнь вәгазе,*

*Шәүвәл аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1438 нче ел*

# Ураза гаете вәгазе

الْحَمْدُ للهِ رَبِّ الْعَلَمِينَ وَ الصَّلَاةُ وَ السَّلَمُ عَلَى مُحَمَّدٍ
وَ عَلَى آلِهِ وَ اَصْحَابِهِ اَجْمَعِينَ

Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәракәтүһ!

Рамазан аенда безгә сансыз нигъмәтләрен насыйп иткән, җәйге озын вә эссе көннәрдә безгә ураза, намаз, изге гамәлләр гыйбадәтләрен бүләк иткән Аллаһы Тәгаләгә сансыз мактауларыбыз булсын! Бер ай дәвамында җир шарының бар мөселманнары, Коръәни-Кәримдә китерелгән «Без ишеттек вә буйсындык»[1] сүзләренә нигезләнеп, ураза тотты, гөнаһлардан тыелып торып, көннәрен һәм төннәрен гыйбадәттә үткәрде. Әлхәмдүлилләһ, Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән без фарыз булган уразаны тоттык. Аның турында Коръәндә болай диелгән:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

**«Ий мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә руза тоту фарыз ителгән кебек, сезгә дә һәр елны бер ай руза тоту фарыз ителде. Шаять, рузаны калдырудан яки рузага кимчелек китерүдән сакланырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

[1] «Әл-Бәкара / Сыер», 2:285

Без изге Рамазан аен озатабыз. Мөэминнәрнең йөрәкләрен төрле хисләр биләп ала. Бер яктан, без хәзер көндезге вакытта ашап-эчү мөмкинлеге булганга сөенәбез. Һәм шул ук вакытта без моңсуланабыз, чөнки Рамазан аенда гына бирелә торган бүләктән – яхшы гамәлләребез өчен күп мәртәбә арттырылган савап алу мөмкинлегеннән – мәхрүм калабыз.

Мәшһүр мөселман галиме ибн Хәҗәр Әл-Гаскаләни «Фәтх әл-Бәри» дип аталган билгеле хезмәтендә болай дигән: «Рамазан тәмамлануын теләү – зур гөнаһлардан».

Әбү Һөрайра ﵁ риваять итә: «Расүлүллаһ ﷺ: «Минем өммәтемә башка өммәтләргә насыйп булмаган биш үзенчәлекле әйбер бирелгән:

1. Ураза тотучының авызыннан килгән ис Аллаһка миск исеннән дә ныграк ошый.

2. Ифтарга кадәр алар өчен судагы балыклар истигъфар кыла.

3. Алар өчен көн саен җәннәт бизәлә һәм Аллаһ: «Тиздән, бу дөньяның авырлыкларыннан арынып, сиңа минем иманлы бәндәләрем килер», – дип әйтә.

4. Рамазан аенда бар шайтаннарга богаулар кидерелә, һәм алар башка айлардагы кебек начар гамәлләрен кыла алмый.

5. Һәм соңгы төндә ураза тотучыларга гафу ителәчәк», – диде.

Сәхабәләр: «Бу Кадер кичәсеме?» – дип сорадылар. Пәйгамбәребез ﷺ: «Юк, әмма эшчеләргә эшне башкарып чыкканнан соң түләнә», – дип җавап бирә».

Ураза – Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгаләнең иң яраткан гыйбадәтләреннән. Изге гамәлләр өчен саваплар фәрештәләр аша тапшырыла, ә ураза савабын Аллаһы Тәгалә Үзе бирә, чөнки ураза фәкать Аның өчен генә. Ә Аллаһ Раббыбыз ризалыгы һәм Аның савапларыннан да кыйммәтлерәк бүләк булуы мөмкинме соң?!

Рамазан ае тәмамланганнан соң гына без Пәйгамбәребезнең ﷺ: «Әгәр Аллаһ коллары Рамазан аеның асыл кыйммәтен белсә, өммәтем

аның ел буе дәвам итүен теләр иде», – дигән сүзләренең хикмәтен һәм тирәнлеген тулысынча аңлый башлыйбыз.

Шулай ук Пәйгамбәребез ﷺ ураза тотучылар арасында тоткан уразаларыннан ачыгудан кала берни алмаганнар, һәм төннәрен гыйбадәттә үткәрүчеләр арасында гыйбадәтләреннән йокысыз төннәр генә алучылар күп, дип кисәткән.

Мөселман галимнәре бу хәдискә берничә аңлатма бирә:

– беренчедән, күз уңында көн дәвамында ураза тотып, ифтарын хәрам акчаларга үткәрүче кеше тотыла. Әлбәттә, мондый кеше көне буена ачыгу хисеннән кала берни алмый.

– Икенчедән, күз уңында ураза тотып та, гайбәт сөйләүче кеше тотыла.

– Өченче фикер – бу ураза вакытында үзен гөнаһлардан сакламаучы кеше.

Узган гасырның күренекле татар рухание Муса Җәруллаһ Бигиев ураза тотуның зур әһәмиятен билгели. Ул мондый фикер җиткерә: кеше үз ихтыяры белән тәмле тәгамьнәрдән баш тартып, ач торырга мөмкин. Һәм үз ихтыяры белән сусауга түзәргә – бер-ике көн дәвамында эчми торырга мөмкин. Әмма мондый халәт 30 көнгә сузылса, кеше ихтыяр көче белән үз нәфесен һәм теләкләрен тыярга өйрәнә. Мондый очракта адәм баласы үз теләкләренең хуҗасына әйләнә. Ачлык халәтен кичергән кеше үз ихтыяр көче белән ризыктан баш тартырга өйрәнгән, ә сусау кичергән – эчүдән тыелырга өйрәнгән, бу кеше, шиксез, беркайчан тыелган гамәлләр, хыянәт вә мәкер эшләмәс. Мондый кешенең теләкләре һәм нәфесе беркайчан пакьлек вә хакыйкать чикләреннән чыкмас, ул һәрвакыт шәригать рөхсәт иткән чикләрдә калыр. Башка төрле әйткәндә, бар илаһият диннәре кануннары күз уңында тоткан сәгадәткә ураза аша ирешү мөмкин, дип фикер йөрткән галим.

Әлхәмдүлилләһ, Ураза вә Корбан гаетләре вакытында Татарстаныбызның бар мәчетләре тулы. Бу форсаттан файдаланып, шуны

да искәртәсе килә: көн саен фарыз булган биш вакыт намаз яки атна саен укыла торган җомга намазы икесе бергә алынган Ураза һәм Корбан гаете намазларыннан да кыйммәтлерәк.

Моңа нисбәтле күренекле хәнәфи галиме, факыйһ Әбү Ләйс Сәмәркәнди үзенең «Тәнбиһүл гафилин» («Гафилләрнең уянуы») китабының «Җомга намазының дәрәҗәсе турында» бүлегендә мондый хәдис китерә: Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ әйткән: «Җомга – башка көннәрнең хуҗасы. Аллаһы Тәгалә каршында бу иң бөек көн. Аллаһ каршында бу көн Гыйд әл-фитр һәм Гыйд әл-әдхәгә караганда да бөегрәк». Шушы ук хәдистә Пәйгамбәребезнең ﷺ: «Җомга көнендә биш үзенчәлек бар: бу көнне Аллаһы Тәгалә Адәмне ؑ яраткан һәм җиргә төшергән. Шулай ук бу көнне Адәм ؑ вафат булган. Җомга көнне кешенең бар догалары, әгәр ул хәрамны сорамаган булса, кабул була торган вакыт бар. Кыямәт көне дә җомга көнне булачак. Бу көнне Аллаһка якын күктәге вә җирдәге фәрештәләр җомга шәфәгатен теләп тора», – дигән сүзләре китерелә.

Башка төрле әйткәндә, газиз дин кардәшләрем, биш вакыт һәм җомга намазының хөкемнәре – фарыз, ә Ураза вә Корбан гаете намазларыныкы – вәҗиб. Имам Әгъзам Әбү Хәнифә әйткән: «Мин фарызның вәҗибтән җир белән күк кебек аерылганын беләм». Шул сәбәпле, мин бар мөселманнарны да биш вакыт һәм җомга намазларын мәчетләребездә җәмәгать белән башкарырга чакырам.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Шулай ук исегезгә төшерәм, Рамазан аенда фитыр сәдакасын бирү тиешле. Аның хөкеме – вәҗиб, аны бәйрәм намазы тәмамланганчы бирергә кирәк. Киләчәктә бу җыелган сәдакалар зәкәт кебек бүленәчәк. Фитыр сәдакасы һәм зәкәт түләнә торган мал исәбе «нисаб» дип атала. Зәкәттән аермалы буларак, фитыр сәдакасын бирү өчен нисабның артып торуы мәҗбүри түгел, димәк, малның еллык үсеш нәтиҗәсен көтү кирәк түгел.

Инде берничә ел рәттән ураза иң эссе көннәргә туры килә. Без көн дә егерме сәгатькә якын сусыз һәм ризыксыз тордык. Шушы сынауны үтәргә көч биргән Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз, рәхмәтләребез барып ирешсен! Хәдисләрдә фәрештәләрнең ураза дәвамында Аллаһы Тәгаләдән ураза тотучыны ярлыкавын сораулары әйтелә. Әлхәмдүлилләһ, безнең җирлектә яшәүчеләр нинди бәхетле! Бу нигъмәтне гарәпләр, төрекләр һәм башка көньяк мөселман халыклары аңласа, мөгаен, гөнаһлардан күбрәк арыныр өчен, алар монда, төньякка, килеп торырлар иде.

Рамазан – Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу вакыты, әмма, газиз дин кардәшләрем, гыйбадәтләребезне бу ай үткәч тә туктатмыйк. Бар яхшы гадәтләребезне, изге гамәлләребезне саклап калыйк, гыйлемнәребезне арттырыйк, уйларыбыз, калебләребез вә хисләребезне камилләштерик, пакьләндерик! Рамазан – гөнаһ һәм начар гадәтләрдән арыну өчен искиткеч мөмкинчелек булды. Аңлы булыйк, калдырган гөнаһларыбыз, начарлыкларыбызны калдырыйк, кабатламыйк. Бу Рамазан ае безне гөнаһларыбыздан аерып торучы чик булсын, барчабызга күңел тынычлыгы, иман байлыгы бүләк итсен!

«Рамазан аенда ихлас тәкъвалык, Аллаһ шәфкатенә вә истигъфарына өмет белән ураза тотучының кылган гөнаһлары гафу ителер», – дигән Мөхәммәд пәйгамбәребез ﷺ. Аллаһ Раббүл-гыйззә уразаларыбыз вә гыйбадәтләребезне кабул итсә иде. Әмин.

Вәгазьне мондый кызыклы диалог белән тәмамлыйсы килә. Малай әтисеннән: «Әтием, мин Рамазанны сагынам. Ничек уйлыйсың, ул да безне сагынамы икән?» – дип сораган. Әтисе: «Әлбәттә, кадерлем. Нәкъ шул сәбәпле ул ел саен 10 көнгә иртәрәк килә», – дип җавап биргән.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөселманнарының*

*Диния нәзарәте рәисе, мөфти*

*30 нчы июнь вәгазе,*

*Шәүвәл аеның 6 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1438 нче ел*

## Вакыф

Хәйриячелек Ислам динендә язылган. Гамәлдә мөселманнар дөньясында иҗтимагый (социаль) эшчәнлек «вакыф» (гарәп теленнән «тукталыш», «тотып калу») дип атала торган махсус институтлар аша башкарыла.

Вакыф – дини яисә хәйрия эшчәнлеге өчен шәхси затлар һәм дәүләт тарафыннан тапшырылган милек. Вакыфка күчә торган милек беләнберрәттән күчми торганы да керә, ул бары тик файда китерә торган (керем) һәм тотылмый торган (акча) булырга тиеш. Вакыфка үз милкен тапшырган кеше аның гамәлгә куючысы дип исәпләнә.

Вакыф шәригать белән хупланылган һәм аның тарафыннан киң соралган гамәл. Әлеге төр милекнең төп нигезе Коръән һәм сөннәттә салынган. Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

لَن تَنَالُوا الْبِرَّ حَتَّىٰ تُنفِقُوا مِمَّا تُحِبُّونَ ۚ وَمَا تُنفِقُوا مِن شَيْءٍ فَإِنَّ اللَّهَ بِهِ عَلِيمٌ ﴿٩٢﴾

> **«Ий мөселманнар, үзегезгә сөекле нәрсәләрдән мохтаҗ мөселманнарга бирмичә торып, Аллаһыдан биреләчәк нигъмәтләргә ирешә алмассыз. Бит Аллаһ сезнең нинди нәрсәләрдән сәдака биргәнегезне беләдер».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:92

Пәйгамбәребез ﷺ сәхабәсе Әбү Талхә ﵁ әлеге аятьне ишеткәч, үз милкен Аллаһ ризалыгы өчен тотарга уйлый.

«Сахих Әл-Бохари» хәдисләр җыентыгында бу вакыйга башкача китерелә: Әбү Талхә ﵁ әлеге аятьне ишеткәч, Мөхәммәд Пәйгамбәр ﷺ

янына ашыга. Пәйгамбәргә аятьне укыгач, ул болай ди: «Минем иң кадерле милкем – Бәйраха бакчасы. Мин аны Аллаһ һәм Мөхәммәд Пәйгамбәр ﷺ юлына тапшырам. Әлеге бакча белән Аллаһ кушканча эш ит». Шул чак Пәйгамбәр ﷺ җавап бирә: «Афәрин, Әбү Талхә, бу керем китерүче милекне без синнән кабул иттек һәм кире кайтарабыз: якыннарың һәм туганнарың кулланышына тапшыр». Һәм Әбү Талхә бу бакчаны туганнарына бирә.

Әбү Һөрәйра ﷺ мондый риваять тапшыра: Пәйгамбәребез ﷺ : «Кеше вафат булганнан соң, аның өч төрле гамәленнән кала, бар гамәлләре туктала. Бу өч әйбер: туктаусыз хәйриячелек, башкаларга тапшырып калдырган файдалы гыйлем, үз ата-аналары өчен ялварып гыйбадәт кыла торган иманлы бала», – дигән[1].

Галимнәр хәдистә китерелгән «туктаусыз хәйриячелек» сүзтезмәсен вакыф дип аңлатканнар.

Пәйгамбәребез ﷺ сәхабәсе Ибн Гомәр мондый хәдис тапшыра. Аның әтисе Гомәр Хайбәрны (Мәдинә янындагы җир) алган вакытта, өлеш буларак җир мәйданын ала. Әлеге җирне алгач, Гомәр Пәйгамбәр ﷺ янына киңәшләшергә китә: җир белән нишләргә? Гомәр Пәйгамбәргә ﷺ мөрәҗәгать итә: «Ий Аллаһ Илчесе ﷺ ! Миңа Хайбәрдан җир эләкте. Моңа кадәр әлеге җир кисәгеннән дә кыйммәтлерәк нәрсәм юк иде. Аның белән нишләргә киңәш итәсең?» Пәйгамбәр ﷺ әйтә: «Теләсәң, вакыфка тапшыра аласың». Гомәр әлеге җир өлешен вакыфка бер шарт белән тапшыра: аны сатарга, бүләк итәргә, васыять буенча күчерергә ярамаган. Аның белән мохтаҗлар, туганнар, юлчылар һәм кунаклар куллана алган, шулай ук әсирлектән колларны азат итү өчен кулланырга ярый, дигән шарт булган. Әлеге җир белән шөгыльләнүчегә, җирдә үстергән азык-төлекне чама белән кулланучыга бернинди гөнаһы да булмаган. Нәкъ Гомәр биргән вакыф Ислам тарихында беренче вакыф милке булып санала. Вакыф гамәле мөселманнар арасында тиз һәм киң таралган. Пәйгамбәребез ﷺ сәхабәсе Җәбир мөмкинлеге булып, вакыф ясамаган бер генә сәхабә дә булма-

[1] Мөслим, 1631

ган, дип әйткән. Имам Әш-Шәфигый әйткән: «Миңа 80 әнсар (Мәдинәдә яшәүчеләр) вакыф булдырганы билгеле».

Вакыфның хикмәте:

1. Аллаһка якынаю, зур савап алу. Мөселман өчен Аллаһка якынайтучы яраткан гамәлдән дә артык нәрсә юк.

2. Үз милкеңне вакыфка әйләндергән гамәл – ачыктан-ачык Аллаһы Тәгаләнең колы икәнен күрсәтүче, Аңа карата яратуыңны белдерүче дәлил. Ә Аллаһка ярату – ул кушканнарны үтәүдә чагыла.

3. Алда китерелгән хәдистәге кебек, кеше үлгәч тә савабы булырдай үзеңнән соң чиксез сәдака калдыру.

4. Мөселман җәмгыятенә мәчетләр булдыру, мәдрәсә-мәктәпләр салу, белем тарату кебек игелекле гамәлләр кылу.

5. Мохтаҗларга, мескеннәргә, ярлыларга, ятимнәргә һәм юлчыларга ярдәм кулын сузу.

Вакыфның әркәннәре.

Вакыфның 4 өлеше бар: 1) гамәлгә куючы; 2) хәйрия максатына васыять ителгән милек (вакыф буларак); 3) вакыф васыять ителгән кеше; 4) төзелеше.

Үз чиратында, вакыфны гамәлгә куючының үз шартлары бар:

1. Гамәлгә куючының сүзләре юридик яктан дөрес булырга тиеш. Ул ирекле, балигъ булган яшьтә һәм тулы үз зиһенендә булырга тиеш. Балигъ булмаган бала вакыф булдыра алмый.

2. Гамәлгә куючының хәйрия белән шөгыльләнергә хокукы булырга тиеш. Банкротлык яисә тыелган эшчәнлек аркасында милкенә арест салынган кеше вакыф булдыра алмый.

3. Үз теләге белән эш итү.

Күчемсез милек вакыфы.

Ислам хокукы буенча вакыфны күчемсез милек белән булдыру да рөхсәт ителә, мәсәлән, җир, өй, кибет, кое (милектән файдасы булган ва-

кытка кадәр рөхсәт ителә). Күчемсез милекнең канун буенча дөрес булуын Коръән һәм сөннәт, сәхабәләрнең гамәлләре күрсәтә. Без алдарак Җәбирнең сүзләрен китергән идек: «Мөмкинлеге булып, вакыф ясамаган бер генә сәхабә дә булмаган», – дип әйткән. Билгеле булганча, еш кына алар вакыфны җир, өй һәм кое рәвешендә булдырганнар.

Күчә торган милек вакыфы.

Күчемсез милек вакыфы булган кебек үк, күчми торган милек вакыфы да бар. Алар рәтенә, мисал өчен, хайваннар, кием-салым, машиналар, өй кирәк-яраклары, файдалы әдәбият керә. Әлеге төр вакыфның урынлы һәм канунлы рәвештә дөрес булуын Аллаһ Илчесе ﷺ хәдисләре дәлилли. Шуларның берсендә болай дип әйтелә: «Кем дә кем үз атын Аллаһка ышанып һәм яратып вакыфка тапшыра икән, аның туклылыгы Ахирәт көнендә бизмәнгә салыначак»[1].

Ислам тарихы хәйриячелеге тарихына тиң. Белгәнегезчә, зәкәт – Исламның төп 5 төшенчәсе рәтендә тора. Зәкәт – мохтаҗлар хакына түләнә торган еллык мәҗбүри салым булып санала. Коръәндә зәкәт, намаз сыман ук, 27 тапкыр әйтеп үтелә. Исламда шулай ук сәдака кебек төшенчә барлыгын да онытмаска кирәк.

Исламда хәйриячелек һәм иҗтимагый эшчәнлекнең урыны булуы диндәге якын кешеңә ярату хисе белән дә аңлатыла. Социаль проблемаларны чишкәндә акча һәм финанс хәлнең нык булуы гына аз, күңел киңлеге, кешелек сыйфатлары да беренче урынга чыгарга тиеш. Элек-электән мөселман җәмгыятьләренә бердәмлек, ярдәм итү һәм бер-береңә терәк була белү хас. Бу барлык мөселманнар өчен дә бердәм канун.

Аллаһы Тәгалә Аның юлында вакыф булдыру мөмкинлеге бирсен иде, беренче чиратта, һәммәбездә вакыф булдыру теләген уятсын иде!

*Рөстәм хәзрәт Хәбибуллин,*

*«Вакыф» фонды мөдире*

[1] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

*7 нче июль вәгазе,*

*Шәүвәл аеның 13 нче көне, һиҗри исәп буенча 1438 нче ел*

## Зикер вә шөкер кылуның әһәмияте

Бисмилләһир рахмәнир рахиим

Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә бер аятьтә болай ди:

وَإِذْ تَأَذَّنَ رَبُّكُمْ لَئِن شَكَرْتُمْ لَأَزِيدَنَّكُمْ وَلَئِن كَفَرْتُمْ إِنَّ عَذَابِي لَشَدِيدٌ

**«Әгәр миңа шөкер кылсагыз, нигъмәтләремне арттырырмын, ә инде көферлек кылсагыз, шөкерсезлек белдерсәгез, белегез, дөреслектә, Минем газабым бик каты».**

«Ибраһим», 14:7

Бервакыт Муса ﵇ Аллаһы Тәгаләдән сорады: «Йә Раббым, ничек итеп мин Сине зикер кылыйм?» Аллаһы Тәгалә җавап итеп: «Синең зикер кылуың Миңа шөкер итүең», – диде. Моннан шуны аңларга була, шөкер белән зикер бер-берсе белән нык бәйләнгән, зикер кылмаган бәндә шөкерсездер, ә шөкерсез бәндә зикерсездер. Чөнки зикер ул Аллаһ Тәгаләне искә төшерү булса, шөкер – Аллаһның нигъмәтләрен искә төшереп, Аңа рәхмәт әйтү.

Расүлебез ﷺ үзенең бер хәдисендә зикернең әһәмиятлелеген аңлатып үтте. Әбү Әд-Дардә риваять итә: «Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Сезне иң хәерле гамәлгә өндимме? Раббыгыз каршында иң зәки (чиста, пакь) булган, дәрәҗәләрегезне күтәрә торган, Аллаһ юлында мал сарыф итүдән, алтын вә көмеш инфак итүдән, Аллаһ юлында җиһад кылудан да хәерлерәк гамәлгә өндимме?» Шул вакытта сәхабәләр: «Әлбәттә әйт, ий Аллаһ Илчесе!» – дип әйтте. Пәйгамбәребез ﷺ : «Аллаһны зикер кылу», – диде[1]».

---

[1] Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан

Мөхтәрәм җәмәгать, чыннан да, безгә зур дәрәҗәләргә ирешер өчен әллә ни кирәкми, фәкать күп итеп Аллаһны зикер кылу кирәк. Зикер – ул гыйбадәт. Пәйгамбәребез ﷺ: «Дөнья ләгънәт кылынган һәм дөньяда булган һәр нәрсә ләгънәт кылынган, өч нәрсәдән кала: зикер кылу, гыйлем алу һәм гыйлем бирү», – дип әйтте. Шуңа күрә без зикергә, гыйлем алуга һәм гыйлем бирүгә игътибарыбызны юнәлтмибез икән, шул вакытта дөнья белән бәйләнгән һәр эшебез ләгънәт астында булырга мөмкин. Шуңа, җәмәгать, шәригать гыйлемен алу бик кирәк, зикер белән шушы гыйлемебезне калебтә ныгытуда тырышырга кирәк.Әгәр кеше шушы өч гыйбадәтне үтәсә, дөнья белән бәйләнгән калган хәерле-изге эше ләгънәттә булмас, бәлки мәрхәмәттә булыр.

Пәйгамбәребез ﷺ сәхабәләренә бер кыйсса сөйләгән: «Бәни Исраил кавемендә өч кеше яшәгән, алар авыру булган. Берсе тән авыртуы белән (проказа) интегә, икенчесе сукыр була, ә өченчесенең башында чәче үсми. Көннәрдән бер көнне алар бер-берсенә сүз каттылар. Тән чире белән авырган кеше әйтә: «Кайчан бетәр тән авыруым, тәнем бигрәк ямьсез», – дип. Чәче булмаган кеше: «Кайчан чәчем үсәр? Кеше миннән көлә, мәсхәрә итә. Моңа түзеп булмый», – ди. Ә сукыры дәшми кала. Һәм болар аптырашып сукырдан: «Син күзеңнең күрүен теләмисеңме әллә?» – дип сорыйлар. Сукыр болай дип җавап бирә: «Иң мөһиме маңгай күзе түгел, ә Аллаһы Тәгалә минем күңел күзен алмавын телим, монысы иң хәерлесе, ә инде Аллаһ теләсә, маңгай күзе дә кайтыр». Бераз вакыт узгач, Аллаһ Тәгалә өчесенә дә кеше сурәтендә фәрештә җибәрә. Фәрештә иң әүвәл тән авыртуы белән интеккән кеше янына килә дә: «Әссәләмү галәйкүм!» – дип әйтә. Теге сәламгә җавап кайтармыйча: «Сиңа нәрсә кирәк?» – ди. Фәрештә моңа: «Башта сәламгә җавап бир!» – дигәч, бу кеше: «Әйе, вә галәйкүм әссәләм! Нәрсә кирәк?» – дип тупас кына җавап бирә. Фәрештә әйтә: «Мин сиңа ярдәм итәргә килдем, авырганыңны белдем». Авыру кеше: «Әйе шул, мин тән авыруы белән авырыйм, әгәр дә минем авыруым

төзәлеп тәнем матурайса, сәламәтләнеп китсәм, яхшы булыр иде», – ди. Фәрештә кулы белән тәнен сыпыргач, бу кеше сәламәтләнә, тәнематурая. «Тагын нәрсә телисең? Бәлки малдан берәр нәрсә телисеңдер?» – дип сорый фәрештә. «Әйе, миңа бер дөя бирсәң, шушы дөядән күп-күп дөяләр туар, миндә дөя көтүе булыр һәм баеп китәрмен», – ди кеше. Шуннан фәрештә Аллаһның әмере белән моңа дөя дә бирә һәм аннан китә. Аннан соң фәрештә чәче коелып пеләш калган кеше янына килә һәм: «Әссәләмү галәйкүм!» – дип әйтә. Бу кеше дә тегесе кебек үк сәламгә җавап кайтармыйча: «Сиңа нәрсә кирәк?» – ди. Фәрештә моңа: «Башта сәламгә җавап бир!» – дигәч, кеше: «Әйе, вә галәйкүм әссәләм! Нәрсә кирәк?» – ди. Фәрештә: «Мин синең хәлеңне белергә килдем, сиңа ярдәм итәргә килдем, авырганыңны белдем», – дип әйтә. Кеше: «Әйе шул, мин чәч коелу авыруы белән авырыйм, әгәр дә минем авыруым төзәлеп, чәчем үссә, чәчем матурайса, сәламәтләнеп китсәм, яхшы булыр иде», – диде. Фәрештә кулы белән башын сыпыргач, тегесе сәламәтләнә, чәче үсеп китеп, матураеп китә. «Тагын нәрсә телисең? Бәлки малдан берәр нәрсә телисеңдер, сарыклар, тәкәләр?» – дип сорый фәрештә. Кеше: «Юк-юк, сарыклар-тәкәләр уңыш китерми, миңа бер сыер бирсәң, шушы сыердан күп-күп сыерлар, үгезләр туар, миндә сыер көтүе булыр һәм баеп китәрмен», – ди. Шуннан фәрештә Аллаһның әмере белән моңа сыер да бирә һәм аннан китә. Аннан соң фәрештә сукыр кеше янына килә. «Әссәләмү галәйкүм!» – дип әйтә. Сукыр исә үзенең күркәм әхлагы һәм нык иманлы булу сәбәпле: «Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтүллаһи вә бәракәтүһү!» – дип матур итеп җавап бирә. Фәрештә: «Мин синең хәлеңне белергә килдем, сиңа ярдәм итәргә килдем, авырганыңны белдем», – дип әйтә. Сукыр: «Әйе шул, мин сукыр, әгәр дә минем күзләрем төзәлеп, яңадан күрү сәләтем кайтса, сәламәтләнеп китсәм, мин Аның махлукатләренә карап, Аллаһны мактар идем, Раббымнан күптән моны сорыйм», – диде. Фәрештә кулы белән күзләрен сыпыргач, сукыр сәламәтләнә, күзләре яңадан күрә башлый.

«Тагын нәрсә телисең? Бәлки малдан берәр нәрсә телисеңдер, сарыклар тәкәләр?..» – дип сорый фәрештә. Кеше: «Сөбхан Аллаһ, миңа күрү сәләте кайтты, моннан да зур нигъмәт, байлык бармы соң?! Инде шуннан соң Аллаһтан мин нәрсәдер сорарга оялам, әмма кешеләрдән мохтаҗ булырга теләмим, чөнки Пәйгамбәребез ﷺ әйтә: «Сәдаканы бирүче алучыга караганда хәерлерәк», – ди. Шуңа күрә миңа тәкә булса да ярый», – диде. Шуннан фәрештә Аллаһның әмере белән моңа тәкә бирә һәм аннан китә.

Фәрештә күпмедер вакытка югалып тора. Тән авыруы (проказа) белән авырган кеше баеп китә, дөя көтүе артканнан арта, зур-зур йортлар төзи, хәтта аның хезмәтчеләре була. Ул мактанып: «Менә мин бай, мин, мин, мин», – дип тәккәберләнеп, хәтта бу байлыкларны хакыйкатьтә кем биргәнен оныта. Аллаһ һәр нәрсәнең хуҗасы, Аллаһ әхвәлләрне үзгәртүче икәнен бөтенләй оныта.

Чәчсез булган кеше исә сыерлары артып, зур сәүдәгәргә әйләнеп баеп китә. Чәче матур, озын булып үсә. «Минем чәчләрем матур, кеше хәзер миннән көлми, мәсхәрә итми, киресенчә, мин хәзер чәчсез кешеләр өстенннән көләм, мәсхәрә итәм», – дип куана ул. Әмма бу нигъмәтләрнең хакыкый хуҗасын, Аллаһны, оныта.

Сукыр булган кешегә килгәндә, ул һаман догада, зикердә һәм шөкердә була. Эшен дә эшли, баеп китә, әмма һаман Аллаһның нигъмәтләренә шөкер итеп, Аңа хәмед-сәнәләр әйтүдән туктакмый.

Берникадәр вакыттан соң фәрештә кире әйләнеп кайта. Тән авыруы белән авырткан кешегә шул ук сырхау белән интеккән кеше кыяфәтендә килә. Һәм әйтә: «Мин мескен, мин мосафир, мин тән авыруы белән интегәм, миңа ярдәм ит», – ди. Җавап итеп: «Сезнең кебек мескеннәргә ярдәм итеп, малымны исраф итәсем килми минем. Болай да бик күп бурычларым бар, мине борчыма, кит моннан», – ди. Фәрештә әйтә: «Тукта, мин сине беләм ахрысы, син күптән түгел тән авыруы белән интеккән кеше түгелме? Мескен хәлдә елап йөргәнсең түгелме?» Теге кеше: «Юк,

минем белән берни булмаган иде, бу мал вә мөлкәт ата-бабалардан калган мирас», – дип җавап кайтара. Фәрештә исә кулын күтәреп: «Йә Раббым, әгәр дә ул ялганласа, аны элеккеге халәтенә кире кайтар», – дип дога кыла. Аллаһ Тәгалә бу фәрештәне сынау өчен җибәрә.

Шуннан соң фәрештә чәчсез булган кеше янына, шул ук чәчсез кеше кыяфәтендә килә. Һәм әйтә: «Мин мескен, мин мосафир, мин авыру белән интегәм, миңа ярдәм ит», – ди. Чәчсез булган кеше җавап итеп: «Синең башың ник сахра шикелле шундый буш? Башыңны берәр нәрсә белән каплап куй инде», – дип мәсхәрә итә. «Сезнең кебек мескеннәргә ярдәм итеп, малымны исраф итәсем килми, минем болай да бурычларым бик күп, миндә бернинди акча юк. Бар, мине борчыма, кит моннан», – ди. Фәрештә әйтә: «Тукта, мин сине беләм ахрысы, син бит күптән түгел үзең чәчсез идең? Мескен хәлдә елап йөри идең түгелме?» Теге кеше: «Юк, минем белән берни булмаган иде, бу мал вә мөлкәт ата-бабалардан калган мирас», – дип җавап кайтара. Фәрештә исә кулын күтәреп: «Йә Раббым, әгәр дә ул ялганласа, аны элеккеге халәтенә кире кайтар», – дип дога кыла.

Соңыннан сукыр булган кеше янына сукыр кыяфәтендә килә. Теге кеше сукырны күргәч: «Әссәләмү галәйкүм, керегез, рәхим итегез, нинди хаҗәтегез бар?» – дип каршы ала. Һәм: «Мин дә кайчандыр сукыр булдым, мохтаҗ хәлендә идем, һәм ничек миңа Аллаһ биргән нигъмәтне синең белән бүлешмим?» – ди. Фәрештә исә: «Аллаһ сиңа һәм синең малыңа бәрәкәт бирсен һәм Аллаһ синнән разый булсын», – диде.

Аннан сукыр булган кешегә фәрештә әйтә: «Мин фәрештә, мин өчегезгә дә сынау буларак килдем, икесе Аллаһны оныттылар, шөкер итмәделәр, шуңа Аллаһ аларны икесен дә кире шушы авыру мескен халәтенә кайтарды. Ә син шөкер итүчеләрдән булдың, Аллаһның зикереннән ваз кичмәдең, Аллаһ сиңа малыңны тагын да арттырыр, бәрәкәт бирер, синнән разый булыр», – дип фәрештә китеп тә бара.

Ахырда шушы ике кеше бик нык үкенә һәм: «Әй Аллам, без шөкерсез идек, тәкәбберләндек, әгәр дә без шөкер итеп синең нигъмәтләреңне таныган булсак, мондый хәлгә төшмәс идек», – дип зар елыйлар.

Шуңа күрә, хөрмәтле кардәшләр, белегез, бер гөнаһ та җәзасыз калмый, кайчан булса да без кылган гамәлләребез өчен җавап бирәчәкбез.

Шуңа да Аллаһ Тәгалә Коръән-Кәримендә болай ди:

فَاذْكُرُونِي أَذْكُرْكُمْ وَاشْكُرُوا لِي وَلَا تَكْفُرُونِ ﴿١٥٢﴾

**«Ислам дине сезгә биргән нигъмәтләремнең иң зурысы, шөкер йөзеннән Мине зикер итегез! Коръән белән вәгазьләнегез, әмерләрен үтәгез, тыйганнарыннан тыелыгыз, шуны башкаларга да ирештерегез! Мине зикердән куймагыз, нигъмәтләремне онытмагыз, шулай булсагыз, Мин дә сезне дөнья һәм ахирәт рәхмәтемә алырмын. Нигъмәтләремә шөкер итүдән баш тартып, көферлек кылмагыз! Мине зикер итегез, ягъни искә төшерегез, Мин дә сезне зикер итәрмен, Миңа шөкер итегез, көфер булмагыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:152

Шушы ике шөкерсез кеше халәтенә әвереләсегез килмәсә, тузан бөртеге хәтле нигъмәт өчен дә шөкер итегез. Аллаһыга көферлек китермәгез! Кылган гамәлләрегезгә хисап кылыгыз! Кайда гына булсагыз да, Аллаһыдан куркыгыз, дөреслектә, Ул барысын да күреп вә ишетеп тора.

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*

*«Галиев» мәчете имам-хатыйбы*

# Редакция хаты

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ

Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәракәтүһ!

Хөрмәтле имамнар, укучыларыбыз! Журналыбыз редакциясе сезне хезмәттәшлек итәргә чакыра.

Пәйгамбәребез ﷺ хәдисләрендә мөселманнарга булган гыйлемнәре белән уртаклашуның зарурлыгын әйтеп калдыра. Шулай ук имам Әхмәд: «Белем байлыкка охшаган: байлык күбрәк булган саен, аннан күбрәк зәкәт түләнә», – дип әйткән. Имам Гали رضي الله عنه әйткән: «Белүче үз гыйлемнәре белән бүлешә барган саен, аңа яңа гыйлем чыганаклары ачыла бара, алар үсә, ныгый һәм ачыклана. Башкаларны укытканда ул элек алган белемен ныгыта һәм яңасын ала».

«Шура» журналында вәгазьләрегез, мәкаләләрегез, әдәби әсәрләрегезне урнаштырырга теләсәгез, «Сорау-җавап» рубрикасында кызыксындырган сорауларыгызга җавап аласыгыз килсә, «Әңгәмә» сәхифәсе өчен интервью бирергә, редакция хезмәткәрләренә киңәшләрегезне җиткерергә теләгегез булса, **shura@mail.huzur.ru** электрон почтасына яки 420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы 6/27 («Шура» журналына» дип) адресына хатлар юллый, +7 (843) 202-07-74 номерына шалтырата аласыз.

Редакциягә килгән язмалар үзгәртелә ала, бастырылмаска мөмкин һәм кире кайтарылмый.

# Сорау–җавап

## Мордар китү гөнаһы

**Башка төбәктә яшәүче туганыбызның үз-үзенә кул салуын белдек. Бик аяныч хәл. Диндә мондый очраклар турында нәрсә диелә икән?**

Бу дөньяда яшәү мөмкинлеге ул – Аллаһның кешегә бүләк иткән олуг нигъмәте. Беркем дә бу дөньяга үзе теләп килми: һәр кеше Аллаһның әмере һәм рәхмәте белән туа. Димәк, бу дөньядан китү дә кеше теләгенә түгел, ә фәкать Аллаһ теләгенә бәйле булырга тиеш. Әмма, кызганыч, бүген кешеләрнең үз-үзенә кул салу, ягъни мордар китү очраклары турында еш ишетергә туры килә.

Барлык диннәр буенча да үз-үзеңә кул салу бик зур гөнаһ булып санала. Ислам тәгълиматы да көчләүнең барлык төрләрен, шул исәптән үз тәнеңә зыян салуны да катгый рәвештә тыя. «Ниса» сүрәсенең 29 нчы аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә: **«Үз-үзегезне үтермәгез! Дөрестән дә, Аллаһ сезгә (моны тыеп) мәрхәмәтле булуын белдерә».** Шунысы да мөһим: үзеңне үтерү Ислам дине буенча башка кешене үтерү белән тиң булган бик зур гөнаһ булып санала һәм үзенә кул салып мәңгелеккә күчкән кеше ахирәттә, Кыямәт көнендә башка кеше үтерүчеләр белән беррәттән, Аллаһ каршында җавап тотачак.

Бу дөньядан үз теләге белән китүнең сәбәпләрен ачыклаганда, гадәттә, шуларны атыйлар: гаилә тормышындагы проблемалар, эш урыны белән бәйле булган авырлыклар, әҗәт яки башка финанс проблемалары, җавапсыз мәхәббәт, физик көчләүгә дучар ителү, тормыш мәгънәсен югалту... Әмма шушы сәбәпләрнең барысын да бер сүз эченә берләштереп, билгеләп узарга була: ул – белемсезлек. Үз диненең нигезләрен белгән кеше нинди генә авыр хәлгә тарыса да, беркайчан да үз-үзен үтерергә җөрьәт итмәс, чөнки бу гамәлне кылу аңа көтелгән җиңеллекне алып килмәячәген аңлый ул. Алай гына да түгел: шушы гамәле нәтиҗәсендә

ул тагын да зуррак, ә иң мөһиме – мәңгелек газапка дучар ителәчәген дә яхшы белә. Хәдисләрдән мәгълүм булганча, үзенә кул салып үлгән кеше җәһәннәмдә бертуктаусыз шул гамәлен кабатлап интегер. Әйтик, Әл-Бохари һәм Мөслим җыентыкларында шундый хәдис китерелә: «Кем үзен тимер корал белән үтерсә, җәһәннәм утында берөзлексез шул корал белән үз эченә кадап торыр. Кем биеклектән сикереп үзен үтерсә, җәһәннәмнең тирән төбенә даими егылып төшеп җәфаланыр».

Шулай итеп, хәлемне җиңеләйтәм дип, бу дөньядан үзе теләп киткән кеше чынбарлыкта үзен бик тә, бик тә авыр хәлгә төшерә: аның җанын газап фәрештәләре каршы ала һәм ахирәт тормышына күчү белән, шул кеше үзен нинди газапларга дучар иткәнен аңлап бик үкенә, әмма хатасын төзәтү мөмкинлеге инде булмый.

Ни өчен үз-үзеңә кул салу Ислам динендә зур гөнаһ булып санала дигәндә, без иң элек: «Аллаһы Тәгалә моны катгый рәвештә тыйганга күрә», – дип җавап бирә алабыз. Инде билгеләп үтелгәнчә, бу тыю Коръән аятьләре белән дә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ хәдисләре белән дә расллана. Әмма кемдер шундый сорау да бирергә мөмкин: әгәр тормыш авырлыклары чыдап булмый торган йөккә әверелеп, яшәүнең бернинди дә мәгънәсе калмаса, нишләргә? Әйдәгез, бу хакта да уйлап-фикерләп алыйк.

Кеше – Аллаһы Тәгалә бар кылган иң гаҗәеп мәхлукларның берсе. Аны бар итүнең максатын аңлатып, Раббыбыз Аллаһы Тәгалә Үзенең изге китабы Коръән-Кәримдә болай ди: **«Җеннәрне һәм кешене Мин фәкать Үземә гыйбадәт кылсыннар өчен генә яраттым»** («Зарият / Таратучы», 56 аять). Яшәү максатыбызның тагын бер өлешен аңлатып, Аллаһы Тәгалә әйтә: **«Мөбарәк булсын шул Зат, Кем үлем һәм яшәүне сезне сынап карар өчен һәм кемнең гамәлләре яхшырак булуын карар өчен бар кылды...»** («Мүлек / Патшалык», 1–2 аятьләр). Димәк, Адәм балалары бу дөнья тормышына сынау узу өчен җибәрелә. Шулай булгач,

кешенең тормышы фәкать шатлыклы хәлләрдән генә гыйбарәт була алмаганы аңлашыла: барысы да үзгәреп тора, сөенеч көенеч белән, тынычлык тынгысызлык, ә бәхет-сәгадәт кайгы-хәсрәт белән алышынуы да бик ихтимал. Моның шулай булуының мәгънәсе – сыналу, ягъни шатлыклы хәлдә шөкер итәрме, авырлык килсә – сабыр булырмы дип, Аллаһы Тәгалә һәр кешене сыный. Моның асылында – Үз Раббыңа тугрылыклы булып калу һәм Аның хозурына, мәңгелек тормышка Ул риза булырлык хәлдә кайту. Бу – һәр кешенең Аллаһ каршындагы төп бурычы. Ә инде тормышы дәвамында кем ничек сыналачак – моны Аллаһы Тәгалә Үзенең олуг хикмәте белән алдан тәкъдирләп куя. Мөселман галимнәре билгеләп үткәнчә, мордар китүнең җинаятьчелеге үз тәкъдиреңә риза булмыйча Аллаһка каршы чыгудан да гыйбарәт.

Адәм баласы нинди генә авырлык кичерсә дә, Раббысын искә алып, ихлас күңел белән Аннан ярдәм сорап дога кылырга тиеш. Авыр хәлгә төшүчеләрне тынычландырып, Аллаһы Тәгалә Коръәндә кат-кат кабатлап әйтә: **«Дөрестән дә, кыенлыктан соң җиңеллек килә! Кыенлыктан соң (һичшиксез) җиңеллек килә!»** («Инширах / Ачмак», 5–6 аятьләр). Иң мөһиме – шайтан котыртуларына игътибар итмичә, сабыр булып калырга һәм «үтерүче» исеменнән баш тартып, мордар булып китү уен баштан чыгарырга кирәк. Бу гамәлнең аяныч нәтиҗәләре турында югарырак инде әйтелде. Коръәндә шундый аять тә бар: **«Аллаһның җәзасыннан курыккан кешегә Аллаһ һәрбер кыенлыктан чыгу юлын күрсәтер һәм аңа көтелмәгән, уйламаган җирдән ризык бирер. Аллаһка ышанган кешегә бер Аллаһ җитәр»** («Талак», 2–3 аятьләр). Мөхәммәд Пәйгамбәр ﷺ дә күңел төшенкелегенә бирүчеләрне юатып, болай дип әйтә торган булган: «Гыйбадәт мәсьәләсендә үзегездән югарырак булганнарга карагыз, дөнья эшләренә килгәндә исә – үзегездән түбәнрәк, үзегездән начаррак хәлдә булганнарга карагыз».

Элекке заманда бер патша вәзир-киңәшчеләрен җыеп, аларга болай дигән: «Шатлык килсә, мин артык сөенәм, борчу-мәшәкать килсә – бик көенәм. Сөенечле хәлдә һаваланмаска, кайгылы вакытта артык борчылмаска ярдәм итә торган бер гыйбарә уйлап табып, иртәгә миңа аны җиткерегез». Патша боерыгын ишеткән вәзир-киңәшчеләр тирән уйга баталар. Ә икенче көнне хикмәт ияләре патшага матур итеп бизәлгән кечкенә генә бер тартма бирә. Шуның эчендә ул затлы итеп эшләнгән балдак таба. Шул балдакта исә мондый язу була: «Бу хәл дә узып китәчәк…».

Әйе, бу дөньядагы һәрбер хәл узып китүчән. Ни генә булса да – һәр нәрсәне тыныч кабул итәргә тырышыйк. Шатлыкта Аллаһка шөкер итик, авырлыкта Аңа тәвәккәлләп дога кылыйк, «Аллаһы Тәгалә ташламый ул», дип уйлыйк. Күренекле ислам галимнәре бу тормышны зур сәяхәт, ә кешене – үз өенә әйләнеп кайтуны максат итеп куйган, төрле киртәләр һәм кыенлыклар аша узучы сәяхәтче белән чагыштырды. Шушы тормыш сәяхәтендә җитәкчебез Аллаһ булсын, иман белән яктыртылган туры юлдан адашмыйча, ялгышмыйча барып, Аллаһ хозурына ирешергә насыйп кылсын.

*Ришат хәзрәт Курамшин,*

*Кукмара мәдрәсәсе мөдире*

# Үрнәк затлар

# Әбү Гобәйдә Әмир ибн Габдуллаһ

«إن لكل أمّة أميناً، وإن أميننا أيتها الأمة: أبو عبيدة بن الجراح»

**«Һәр халыкның ышанычлысы (саклаучысы) бар. Бу халыкның ышанычлысы (саклаучысы) – Әбү Гобәйдә бин Әл-Җәррах»[1] .**

*Мөхәммәд Пәйгамбәр* ﷺ

Ул матур озынча битле, төз гәүдәле, озын буйлы, бик сөйкемле, ягымлы, бик тыйнак һәм оялчан кеше булган. Әмма авыр һәм куркыныч янаган очракларда ул усал арысланга охшаган. Мөхәммәд халкының яклаучысы, Мөхәммәд Пәйгамбәрнең ﷺ иң якын сәхабәләренең берсе, мәшһүр гаскәр башлыгы һәм сәясәтче Әбү Гобәйдә Әмир ибн Габдуллаһ ﵁ нәкъ шушындый булган. Аның турында Габдуллаһ ибн Гомәр: «Корәешлеләрнең өчесе иң данлыклы, әхлаклы һәм намуслы кешеләрдән булды. Әгәр алар синең белән сөйләшсә, беркайчан ялганламаслар, ә син алар белән сөйләшсәң, сине беркайчан ялганчы димәсләр. Бу – турылыклы Әбү Бәкер, Госман ибн Гаффан һәм Әбү Гобәйдә ибн Җәррах».

Тулы исеме: Әбү Гобәйдә Әмир ибн Габдуллаһ ибн Әл-Җәррах ибн Һиләл ибн Үһәйб ибн Дәббә ибн Әл-Харис ибн Фиһр ибн Мәлик ибн Ән-Нәдр Әл-Корәши Әл-Фиһрий. Әбү Гобәйдәнең Мөхәммәд Пәйгамбәр ﷺ белән уртак борынгы бабасы – Фиһр.

Әбү Гобәйдә 583 елда Мәккәдә туа. Ул югары дәрәҗәле, бик зирәк кеше була, шул сәбәпле халык аны, Әбү Бәкер белән беррәттән, «Корәеш кабиләсе башлыгы» дип атаган.

Әбү Гобәйдә беренче мөселманнардан. Ул Исламны Әбү Бәкер хак динне кабул иткәннең икенче көнендә кабул итә. Аның белән бергә Госман

---

[1] Әнәс ибн Мәлик тапшыра

ибн Мәзгун, Гобәдә ибн Харис, Габдеррахман ибн Гауф һәм Әбү Мөслимә ибн Габделәсәд тә Ислам кабул итә. Бу вакыйга болай риваять ителә: аларны Пәйгамбәр ﷺ янына Әбү Бәкер алып килә, Расүлүллаһ аларга Ислам турында сөйли, алар шундук аның сүзләренә инана һәм Ислам кабул итә. Әбү Гобәйдәдән Мәүлә Гомәр, Габдеррахман ибн Ганәм һәм башкалар Ислам кабул итә.

Ул һәрвакыт Пәйгамбәрне ﷺ яклаган, аның белән булган. Ибн Исхактан Әбү Гобәйдәнең Хәбәшстанга (Эфиопия) һиҗрәт кылучы мөселманнардан булуы хәбәр ителә.

Һичшиксез, башка беренче мөселманнарга кебек үк, Әбү Гобәйдәгә бик авыр сынаулар үтәргә насыйп була, ул кәферләр эзәрлекләүләре вә җәберләүләренә түзә. Әмма Бәдер сугышы вакытында Әмир ибн Габдуллаһка күз алдына китерергә дә авыр булган кайгы кичерергә туры килә. Бәдер көнендә Әбү Гобәйдә гадәттәгечә бик кыю рәвештә беренче рәтләрдә кәферләргә каршы сугыша. Аның ярсулы һөҗүмнәренә очраган саен, корәешләрнең атлы гаскәре як-якка таралган. Әмма дошманнар арасыннан берәү һәрвакыт аның каршысына килеп чыга торган булган. Әбү Гобәйдә бу кәфер белән бәрелешмәскә, кара-каршы чыкмаска бик тырышкан. Аны ничек кенә урап узарга тырышса да, бу кеше аның юлын кистереп, аңа комачаулап, Әбү Гобәйдә һәм кәферләр гаскәре арасына баскан. Түземлелеге бетеп, Әбү Гобәйдә кылычы белән бу кешенең башын чабып төшерә. Дошман аның каршында ава... Бу кәфер Әбү Гобәйдәнең әтисе була. «Әл-Мүҗадәлә» сүрәсенең 22 нче аяте шушы очракка һәм башка сәхабәләргә нисбәтле иңдерелгән:

**«Аллаһыга вә Кыямәт көненә иман китергән хак мөэминнәрне, Аллаһыга вә Аның Расүленә хилафлык кылучыга дус тапмассың, ягъни хак мөэминнәр Коръән белән гамәл кылырлар, әмма Коръән белән гамәл кылмаучы кешеләргә һич тә дус булмаслар, аларга иярмәсләр һәм алардан курыкмаслар, гәрчә ул Коръән белән гамәл кылмаучы-**

**лар үзләренең аталары булсалар да, яки балалары булсалар да, яки кардәш ыруглары булсалар да, Коръән белән гамәл кылмаганнары өчен алардан киселерләр, бергә яшәмәсләр. Коръән белән гамәл кылып та, Коръән белән гамәл кылмаучы кешеләрдән киселгән хак мөэминнәрнең күңеленә Аллаһ иманны ныклап беркетте, вә аларны Үзеннән булган рухи куәт белән куәтләде, дәхи аларны кертер асларыннан татлы елгалар агучы бакчаларга, алар анда мәңге калучылардыр, Аллаһ алардан разыйдыр вә алар да Аллаһыдан разыйлардыр, биргән нигъмәтләренә шөкер итүчеләрдер, алар Аллаһ гаскәрләредер. Әгяһ булыгыз, тәхкыйк, Аллаһ гаскәрләре газаптан котылып өстенлек табучылардыр»[1].**

Өхед сугышы вакытында Әбү Гобәйдә дошманның төп максаты җиңү түгел, ә Пәйгамбәрне ﷺ үтерү булуын аңлый. Шул сәбәпле һәрвакыт Пәйгамбәр янәшәсендә булырга омтыла.

Сугыш кызган вакытта берничә кәфер Әбү Гобәйдәне урап ала, шул вакытта Пәйгамбәргә ук килеп кадала. Моны күреп, Әбү Гобәйдә шундук дошманнарын тар-мар итә һәм чолганышны ерып, Пәйгамбәр ﷺ янына чыга. Пәйгамбәрнең ﷺ битенә көбәнең ике боҗрасы чәнчелүен күрә. Әбү Гобәйдә аларны бер-бер артлы тешләре белән тартып ала, шул сәбәпле өске һәм аскы ике тешен югалта. Әбү Бәкер Әс-Сыддык ؓ моны үз күзләре белән күреп тора һәм бу вакыйганы шул рәвешле тасвирлый:

«Өхед сугышының иң авыр мизгелендә Пәйгамбәребез җәрәһәтләнә, һәм көбәсенең ике боҗрасы аның битенә кадала. Моны күрү белән мин аның янына ашыктым. Шул ук юнәлештә: «Аллаһ, гамәлләребезне безнең буйсынуыбыз дип кабул итче!» – дип кычкырып башка берәү дә йөгерде. Без икебез дә Пәйгамбәр янына йөгереп килдек, әмма Әбү Гобәйдә беренче иде. Ул: «Аллаһ исеме белән сорыйм, ий Әбү Бәкер, Пәйгамбәребез битеннән боҗраларны миңа алырга рөхсәт ит», – дип сорады. Мин аңа

---

[1] Ногмани тәфсире

рөхсәт иттем. Әбү Гобәйдә тешләре белән бер боҗраны эләктереп алды һәм өске алгы теше белән бергә тартып чыгарды. Шул ук рәвешле ул икенче боҗраны эләктерде һәм аны тартып алып аскы алгы тешен югалтты».

Аның намуслы булуы турында Хөзәйфә ибн Әл-Ямәннән ибн Әбү Шәйбә мондый риваять тапшыра: «Бервакыт Мөхәммәд Пәйгамбәр янына Нәҗраһтән ике кеше килә һәм үзләре белән Коръән һәм сөннәткә өйрәтергә дип, бер намуслы кеше җибәрүен сорыйлар. Пәйгамбәр ﷺ аларга чыннан да намуслы, ышанычлы кеше бирәчәген әйтә. Моны ишеткәч, күп кенә сәхабәләр бу сүзләр алар турында дип уйлаган.

Гомәр ибн Әл-Хаттаб ؓ әлеге вакыйга турында: «Пәйгамбәребез шушы югары дәрәҗәне күрсәтәчәк кеше булачагыма өметләнгән көннән кала, мин беркайчан да җитәкчелек итү теләге белән янмадым. Шул сәбәпле кабаланып мәчеткә ашыктым. Өйлә намазын тәмамлаганнан соң, Пәйгамбәр безне күздән кичерде. Мин аның игътибарын җәлеп итәр өчен аяк очларына бастым, әмма ул күз йөртүен дәвам итте. Әбү Гобәйдәне күргәч: «Алар белән бар һәм бәхәсләренең гадел хакиме бул», – диде. Тиздән Әбү Гобәйдә алар белән китте», – дип сөйләгән».

Бу очрак Пәйгамбәребез ﷺ бары Әбү Гобәйдәгә генә ышанган һәм аны гына ихтирам иткән дигән сүз түгел, ә аның Пәйгамбәрнең ышанычлы сәхабәләреннән булуын күрсәтә.

Пәйгамбәребез ﷺ вафатыннан соң да Әбү Гобәйдә өммәтнең ышанычлысы булып, үз вазифаларын башкаруын дәвам итә. Булачак хәлифне сайлар алдыннан Әбү Бәкер ؓ Әбү Гобәйдә һәм Гомәргә күрсәтеп: «Аларның берсе хәлиф булса, мин моны шатланып кабул итәр идем», – ди.

Әбү Гобәйдә бик тыйнак кеше булган. Гомәр ибн Әл-Хаттаб хәлиф булган вакытта, хәлиткеч сугышларның берсендә мөселман гаскәренең башлыгы итеп билгеләнгән Хәлид ибн Әл-Вәлид урынына Әбү Гобәйдәне билгеләргә була. Гомәрдән бу хәбәрне алгач, Әбү Гобәйдә аны Хәлидкә җиткерми торырга була. Бары Хәлид ибн Әл-Вәлид җиңүгә ирешкәч кенә,

бу яңалык аңа да ирешә. Хәлиднең: «Ий Әбү Гобәйдә, Аллаһ сине ярлыкасын, ни өчен бу хәбәрне миңа вакытында җиткермәдең?» – дип соравына Әбү Гобәйдә: «Аны алуга син каушап калырсың, һәм бу гаскәребезнең рухи халәтендә чагылыр, дип уйладым. Без дөньявины кайгыртып, югары дәрәҗәләргә омтылмыйбыз. Без Аллаһ каршында кардәшләр», – дип җавап биргән.

Сүрия сугышында Әбү Гобәйдә гаскәр башлыгы итеп билгеләнә. Аның гаскәре башка мөселман гаскәрләре белән чагыштырганда көчлерәк һәм бик яхшы коралланган була. Ә Әбү Гобәйдәне гади гаскәриләрдән аеру мөмкин булмый.

Сүриядә Әбү Гобәйдә әмир итеп билгеләнгәч, халык бик тә шатлана. Моны ишетеп, Әбү Гобәйдә халык каршында чыгыш ясый һәм: «Кардәшләрем, мин Корәеш кабиләсеннән, мөселманмын. Мин үземнән тәкъвалырак, гаделрәк булган һәркем артыннан, аның тән төсе нинди булуына карамастан, күләгә кебек иярәчәкмен», – дип әйтә. Ягъни аның өчен бары дине, туган ыруы гына әһәмиятле, кешеләрне бәяләү өчен диндарлык кына нигез булып тора. Биш ел дәвамында ул бу дәүләт территориясендә тәртип саклап тора. Әбү Гобәйдә беренче чиратта гади халык тормышын кайгырта һәм дәүләтне алга җибәрергә тырыша. Элеккеге хакимне кайтару мөмкинлеге бирелгәч тә, сүрияләләр үз ырудашыннан баш тартып, Әбү Гобәйдәне өстенрәк күрә. Мәдинәдә корылык аркасында ачлык куркынычы тугач, Сүриядән анда дүрт мең капчык бодай җибәрелә. Бар бу икмәкне Әбү Гобәйдә үзе җыеп, үзе җибәрә. Әмир булуына карамастан, ул бик тыйнак яшәгән, иң гади киемнәрдән йөргән.

«Әз-Зүһд» китабында ибн Әл-Мөбәрак түбәндәгеләрне риваять итә. Гомәр ибн Әл-Хаттаб Шамга килгәч, кардәшенең кайда яшәвен белешә. Әбү Гобәйдәнең өендә ул бары кылыч, калкан һәм берничә сәфәр кирәк-ярагы гына күрә. Гомәр аңа бар кирәк әйберне алырга куша. «Ул вакытта кешеләр кайдан акча алдың, дип сорарлар, ә мин ни дип җавап кайта-

рырмын?» – дип әйтә Әбү Гобәйдә. Ә бит дәүләтнең бар байлыгы, бар салымнар, бар бүләкләр шушы йорт аша үтә. Гомәр моңа: «Синнән кала без барыбыз да үзгәргәнбез, ий Әбү Гобәйдә», – дип җавап кайтарган.

Шамда чума эпидемиясе башлангач, Гомәр Әбү Гобәйдәгә хат җибәрә. Хатында ул аңа ашыгыч эш йөкләячәген әйтеп, тиз арада килеп җитәргә куша. Әбү Гобәйдә хәлифнең ниятен аңлап ала. Җавап хатында ул Гомәрнең аны кизүдән саклап калырга теләвен аңлавын һәм гаскәре белән калып, гади солдатларының язмышын уртаклашырга теләвен яза. 638 елда Әбү Гобәйдә чума белән авырый һәм 58 яшендә вафат була. Ул Фәләстыйнның Әл-Кудс шәһәреннән ерак түгел Бисән җирлегендә җирләнгән. Әбү Гобәйдәнең үлеме бар мөселман өммәте өчен зур югалту була, хәтта Гомәр ибн Әл-Хаттаб та күз яшьләрен тыя алмый.

«Әл-Хәлийә» китабында Хафиз Әбү Нүгаймәдән мондый риваять китерелә. Бервакыт Гомәр янәшәдәгеләрдән: «Син нәрсә телисең?» – дип сораган. Берәү: «Өем тулы алтын булсын иде. Мин барын да мөселманнарга өләшер идем», – ди. Башка берәү: «Өем тулы энҗе, зөбәрҗәт һәм кыйммәтле ташлар булсын иде. Мин барын да мөселманнарга сәдака итеп бирер идем», – ди. Ә Гомәр: «Бер теләгем бар. Өем Әбү Гобәйдә ибн Әл-Җәррах кебек кешеләр белән тулы булсын иде», – дип әйткән.

*«Хозур» редакциясе*

## Гали ишан Әт-Түнтәри

Мөселман өммәтенең мәшһүр бер вәкиле, Түнтәр авылы имамы, билгеле суфи шәехе Гали ишан Әт-Түнтәрине идеаль татар муллаларының берсе дип атарга мөмкиндер. Руханиның тулы исеме – Гали бин Сәйфулла бин Габдрәшит бин Үтәгән бин Ярмөхәммәд бин Котлымөхәммәд бин Мөхсин Әт-Түнтәри.

Имам 1794 елда Казан губернасының Малмыж өязе (хәзерге ТР Балтач районы) Түнтәр авылында мулла гаиләсендә туа. Башлангыч дини белемне туган авылы мәдрәсәсендә ахун Мөхәммәдрәхим, мулла Габдуллаһ бин Яхъяләрдән ала. Соңрак Сасна авылында мулла Таҗетдин бин Габдеррәшит Әл-Иштирәкидә укый. Берничә ел Бохарада Гатаулла бин Йосыф бин Һади бин Әмин Әл-Бохари кебек билгеле муллаларда белем эсти. Шунда ук мөридләр тәрбияләргә иҗазәт ала. Соңрак, Сахибзад Миянфазыл Габделкадыйр ярдәмчесе булганда, берничә тапкыр Кандагар, Пешавар, Кабул, Лахор, Дәһли шәһәрләрендә була.

35 яшендә, ягъни 1829 елда, Гали ишан туган җиренә әйләнеп кайта һәм Түнтәр авылында имам-хатыйб һәм мөдәррис итеп билгеләнә, 45 ел дәвамында Түнтәр мәдрәсәсен җитәкли, күп шәкерт һәм мөридләр тәрбияли. Ишан һәм мәдрәсә даны бар илгә тарала. Гали ишан белән танышырга күп дин эшлекләре ашкына. Ш. Мәрҗани аның турында: «Илебездә бар ишаннар арасында ул үзенең укымышлылыгы, мәшһүрлеге, тәкъвалыгы һәм шәхси үрнәге белән билгеле иде», – дип яза. Гали ишан шулай ук авыруларны дәвалый белгән. Дәваланырга дип аңа төрле төбәкләрдән килә торган булганнар.

Халыкта ишан турында күп кенә риваятьләр саклана. Мисал өчен, берзаман Түнтәр авылына көчләп чукындыру максаты белән миссионерлар һәм кораллы солдатлар килә. Аларга каршы Гали ишан чыга. Ишанны күрү белән, алар баскан җирләрендә катып кала, солдатларның кулларыннан кораллары төшеп китә. Тагы бер мисал: Гали ишанга кайдандыр кучер белән кайтып килгәндә елга аша үтәргә кирәк була. Ә күперне су агызып киткән икән. Ишан кучерга: «Күзләреңне йом», – дип әйтә. Кучер күзләрен ачканда алар инде елганың аръягында була. Мондый могҗизалар аз булмаган.

Гали ишан 1874 елда 80 яшендә вафат була. Үз юлын дәвам иттерүче итеп ул киявен Шәмсетдин бин Рәхмәтулла Әт-Түнтәрине калдыра.

Замандашларының берсе ишан турында болай дип искә ала: «Гали хәзрәт Габдессәлам мөфти вакытында имтихан тота, аның указында аның җәмигъ мәчете имам-хатыйбы булуы һәм баш мөхтәсиб вазифасы йөкләнелүе билгеләнгән иде… Имам булгач, ул мәдрәсә тәртипләрен үзгәртә, мантыйк һәм кәләм кебек схоластик фәннәрне укытмый, әмма тәфсир, хәдис, гарәп әдәбиятын укыта. Имам беркайчан мәхәлләдән сәдака алмаган, үзенең матди ягын игенчелек, төрле кәсепләр белән шөгыльләнеп кайгырткан. Ишанлыгы белән бик күпләргә файда китергән, башка ишаннардан аермалы буларак, мал-мөлкәт җыймаган, ә бар керемен мохтаҗларга өләшкән. Гали ишан йортларының берсендә көн саен 20 фәкыйрьне ашатканнар. Васыять итеп калдырган 1000 сумының 600 сумын ул хаҗга, ә калганын сәдакага тотарга куша.

Имам бик тә атлар яраткан һәм яхшы атлар тоткан. Аның үзе генә йөргән чабышкылары булган. Атта ул бик оста йөргән, чаптырып барган көйгә җирдән нәрсәдер тотып ала алган, дип ишеткән идем.

Ул кешеләрне милләте ягыннан аермыйча, һәр гамәлен кешеләр файдасына башкарырга омтылган. Кулыннан килгәннең барын да эшләгән. Һәрвакыт авыр хәлгә калучыларның үтенечләрен үтәгән. Моның турында күп ишетергә туры килде. Ул: «Диннең нигезе икәү: Аллаһ кушканнарны үтәү һәм Аның мәхлукларына карата шәфкатьле булу», – сүзләрен кабатларга яраткан. Нинди генә түбән дәрәҗәле кеше булмасын, ишан һәркемне бик ихтирам иткән, балалар үтенечләрен дә үзе башкарган. Шул ук вакытта аны хөрмәт йөзеннән басып каршы алуларын яратмаган, баса башлаучыларны кире утырткан, беркемгә дә кулын үбәргә бирмәгән. Ул югары әхлаклы, кыю, зирәк, тирән гыйлемле булган, урта буйлы, төз гәүдәле, сирәк сакаллы, үткен күзле, ачык һәм тапкыр кеше булган…

Аның үз шәкертләре бик күп булган, шуның белән беррәттән, күпләр аннан тәфсир һәм хәдис буенча гыйлем алырга махсус килгән. Дәресләрен ул китап буенча түгел, ә хәтердән биргән. Сүзләре аңлаешлы

булган, сүзләре, әйтерсең, бер рәткә тезелеп, шундук күңелләрдә урнашкан, шул сәбәпле, ул сөйләгәннәрнең язмаларын дәреслек итеп кулланырга мөмкин булган. Ул укыту һәм тәрбия мәсьәләләренә бик игътибарлы була, шуңа күрә аның шәкертләре, башкалар белән чагыштырганда, күпкә әхлаклырак булганнар».

Һичшиксез, Гали ишан Әт-Түнтәри үз вакытының иң абруйлы шәхесләренең берсе булган һәм Ислам вә гыйлемлелекне үстерүгә бик зур өлеш керткән.

*Рәшид хәзрәт Маликов,*
*тарих фәннәре кандидаты,*
*Буа мәдрәсәсе мөдире*

Мәкалә Р. Ш. Зариповның «Гали ишан, Ишми ишан һәм Түнтәр мәдрәсәсе», «Түнтәр мәдрсәсәсенең кыскача тарихы» китапларына нигезләнеп язылды.

*Рәмзилә Шафикова тәрҗемәсе*

# Хикмәтле остаз – Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин

*Белемле кеше үлде, исеме үлмәде,*

*Белемсезнең, исән чакта да, исеме үле.*

Әхмәд Югнәки

XVIII гасырлардан алып 1917 нче елга кадәр күп кенә татар мәдрәсәләре Нәкышбәндия тарикатенең үзәкләре булып тора. Шундыйларның берсе – Кизләү мәдрәсәсе. Бу мәдрәсәдә халкыбызның күренекле дин әһелләре, гыйлем ияләре, әдипләр, шагыйрьләр белем һәм тәрбия ала. Алар арасында Казан шәһәрендәге «Мәрҗани» мәчетенең мәшһүр имамы, хикмәтле остаз – Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин. Ул Татарстан җөмһүриятенең Норлат районы Колбай-Мораса авылында дөньяга килә. Аның әти-әнисе, гаиләсе хакында мәгълүмат аз сакланган, хәтта туган елы да төгәл мәгълүм түгел. Документларда туган елы 1898 дип язылса да, җиде ел бер гаилә булып яшәгән килене әйтүе буенча, ул 1896 елның 28 мартында туа. Әтисе Сафиулла вафат булгач, 7 балалы гаилә ятим кала. Атасыз калган гаилә бөлгенлеккә төшә, авылда хәерчеләр рәтендә кала. Матди яктан хәлләре мөшкел булса да, мескенләнмиләр: әниләре улы Әхмәдзәкине укытырга ниятли. Аны күрше Кизләү авылы мәдрәсәсенә укырга бирә.

Мәдрәсәләр, мәчетләр ул заманда да халык хисабына көн күргән. Дәүләт йә битараф булган, йә булмаса дошманлык күрсәтеп җимергән. Хәллерәк гаиләләр, үз өлешләрен кертеп, балаларын укытса, Әхмәдзәки мич ягып, су ташып үз хезмәте белән өлешен керткән. Гыйлемгә хирыслыгы буенча аңа тиң булмаган. Авыр үзләштерүче балаларга өстәмә сабак бирүне мөгаллимнәре Әхмәдзәкигә йөкләгән. Шушы мәдрәсәдә үзе

белән бергә укып, өстәмә сабак алган иптәшләрен Әхмәдзәкинең беренче шәкертләре, дип әйтергә була .

Мәдрәсәне уңышлы тәмамлап, Әхмәдзәки хәзрәт туган авылы Колбай-Морасага кайта. Бу вакытта авыл мулласы, яшь булуына карамастан, хатыны Зәйнәпне тол, ике кызын ятим калдырып, якты дөнья белән хушлаша. Фәрдетдин кызы Зәйнәп хәлле гаиләдән чыкканга күрә, йортлары, каралты-куралары да нык була. Авыл картлары Әхмәдзәки хәзрәтне мәчеткә мулла итеп билгелиләр, тол калган Зәйнәпкә өйләнергә киңәш итәләр. Әхмәдзәки хәзрәт өлкәннәрнең киңәшенә колак салып, өйләнә, тормышы җайлана башлый. Әмма илдә вәзгыять үзгәрә, революция нәтиҗәсендә хакимияткә большевиклар килә, тотрыксызлык чоры башлана.

1925–1927 еллар арасында Әхмәдзәки хәзрәт гаиләсе белән Ош шәһәренә качып китәргә мәҗбүр була, чөнки дин әһелләрен кулга алулар, янаулар, юк итүләр башлана. Әхмәдзәки хәзрәтнең гаиләсе белән авылдан китүе шәкертләре тарафыннан төрлечә сурәтләнә. Туган авылында сабак алучы шәкертләре (Кизләү мәдрәсәсе ябылган булса кирәк) Әхмәдзәки хәзрәтнең кара исемлеккә кертелгәнен, аны шул көннәрдә кулга алачакларын әйтәләр һәм үзен кучер киеменә киендереп, гаиләсе белән авылдан чыгарып җибәрүләрен бәян итәләр .

Әхмәдзәки хәзрәт якынча 1930 елларда Казанга килгәнче бик азаплана, шул дәвердә яңа туган өч-дүрт баласы гүр иясе була. Әхмәдзәки хәзрәт юлда авылдан-авылга йөри, дин сабаклары бирә, шуның хисабына ишле гаиләсе көн күрә. Ош шәһәреннән китүләренең сәбәбе мәгълүм түгел. Казанда ике атнага якын Әхмәдзәки хәзрәт эш эзли. Бу вакытта гаиләсе вокзалда (ә кайберәүләр әйтүе буенча елга портында) көн үткәрә. Ниһаять, зоопаркта – хайваннар тыюлыгында Әхмәдзәки хәзрәтне «кара эшкә» алалар. Эшле булуы турында Әхмәдзәки хәзрәт шәкертләренә менә шулай бәян итә: «Эш таба алмый изалангач, гаиләм янына кайтыр алдын-

нан эскәмиягә утырдым да, елый-елый дога кылып, Раббымнан сорадым. Шул вакытта миннән ерак булмаган бер карт: «Кил әле монда, кил», – дип, мине чакырды. Мин: «Кирәк булса, үзең кил», – дидем. Ә карт: «Хәзер зоопаркка бар, сине эшкә алалар», – диде. Күземне ачыбрак карадым, карт юк булган. Зоопаркка бардым, чынлап та, эшче кирәк икән, эшкә алдылар», – дип берничә тапкыр сөйли. Эшчеләр өчен салынган йортның ярымподвал катында торырга фатир да табыла. Ишле гаиләгә өч бүлмәлесен бирәләр. Гомере буе «кәҗә билеты» белән йөргән Әхмәдзәки хәзрәткә паспорт та бирәләр, пропискага да кертәләр. Менә шулай итеп ул үзе туган-үскән илендә, ниһаять, «тулы хокуклы гражданин» була. Шулай да, үзен сугышка алмыйлар, чөнки хакимият аны мулла булганлыктан «ышанычсызлар» хисабына керткән була инде. Зәйнәбенең беренче иреннән калган Кәшифә исемле кызын сугышка алалар. Ул телефонистка булып хезмәт итә. Әнисе янына кайтырга, гаиләле булып балалар үстерергә насыйп булмый аңа, сугыш кырында ятып кала. Икенче кызы Фәһимәсе исән иде әле. Әхмәдзәки хәзрәтнең Зәйнәп белән уртак балалары арта: 1927 елда Суфия исемле кыз бала, 1930 елда – Әнәс, 1933 елда – Әмин, 1936 елда Әдип исемле ир баласы туа.

Нинди генә авырлыклар булса да, Әхмәдзәки хәзрәт гыйлем эстәүдән, сабак бирүдән туктамый. «Кайвакытта төнге 2-3 тә уяна идем, балам яшь, күрәм, әтием ут кабызган, алдында китап – укый. Гыйлемне яңартып торырга кирәк, тонықланмасын, дип әйтә иде», – дип искә ала килене Роза ханым Сафиуллина .

Әйтергә кирәк, Әхмәдзәки хәзрәтнең 115 данәдән торган китапханәсе Татарстанның Милли музеенда саклана. Әхмәдзәки хәзрәтнең китаплары арасында имам Закир Әбү Габдрахман Мөхәммәд бине Габделваһһаб Әл-Читсавиның «Табсыйрател мөршидин» дигән хезмәте дә була.

Роза ханым Әхмәдзәки хәзрәт улы Әдип белән 1964 елда өйләнешәләр. Никахны Әхмәдзәки хәзрәт укый. Балалары дөньяга килгәч, бабасы ир ба-

лага Морад (хәзерге вакытта ул Марат исеме белән билгеле) исеме куша. 1967 елда Әхмәдзәки хәзрәтнең өенә килеп, 19 яшьлек Тәлгать Таҗетдин дин сабагы ала башлый. 2 ел белем алганнан соң, Бохара шәһәренә китә. Алган гыйлеме шул дәрәҗәдә тирән була ки, ул иң яхшы шәкертләрдән санала. 4 еллык курсны 2 елда үзләштергәннән соң, аны Каһирә шәһәренә җибәрәләр.

1950 елларда Әхмәдзәки хәзрәт, зоопарк җитәкчелеге биргән йортта яшәсә дә, асфальт-бетон заводына күчеп «бондарь», ягъни мичкә ясаучы эшенә керешә. «Көне буе балта белән эшләп, кулларым калмый», – дип әйтүе хезмәтенең авырлыгын дәлилли. Кызлары Кәшифәнең сугышта һәлак булганлыгы сәбәпле, 1973 елны аларга Голубятников урамында фатир бирәләр. Әхмәдзәки хәзрәтләр шунда күчә. Бу фатирда хөрмәтле остаздан сабак алучылар саны ишәя. Иң беренчеләрдән булып, Юныс хәзрәт (хәзерге көндә Әстерхан мәчете имамы) белем ала башлый, шуннан Йосыф исемле энесе дә Әхмәдзәки хәзрәткә сабак алырга килә. «Бу фатирга күчкәч, сабак алучылар саны нык күбәя, исемнәрен дә истә калдырырлык түгел иде. 1974 елда зоопарктагы йортта газ чыгып, Әхмәдзәки хәзрәтнең ике улы агуланып үлә», – дип, бәян итә Роза ханым .

Пенсиягә чыкканнан соң, Әхмәдзәки хәзрәт авыр хезмәттән туктый. Шәкерте Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, остазы Әхмәдзәки хәзрәтнең гыйлем чишмәсе икәнен белеп, «Мәрҗани» мәчетендә беренче имам булып хезмәт итүче Габделхәбир хәзрәткә ярдәмгә икенче имам булырга киңәш итә. Әхмәдзәки хәзрәт кырысрак холыклы булса да, Габделхәбир хәзрәт белән уртак тел табалар, бер-берсен олылап хезмәт итәләр. Мәчеткә килүчеләр хәзрәтләр бүлмәсенә кергәннән соң, Габделхәбир хәзрәт күрешкәч кенә Әхмәдзәки хәзрәт күрешә торган була. Вәгазь сөйләү буенча да аңа тиңнәр булмый. Намазларны, вәгазьләрне имамнар чиратлашып алып баралар, Әхмәдзәки хәзрәт укыта торган атнада халык аны тыңларга дип махсус

килә иде. Дин тыелуга карамастан, җомга гыйбадәте вакытында мәчет эчләре тулып, хәтта баскычларда, ишек төпләрендә дә намаз укыдылар.

Җомга көнне имамның вәгазе беренче азанга кадәр берәр сәгать алдан башлана, шуңа күрә аны тыңларга халык алданрак җыела иде (мәсәлән, намаз вакыты сәгать 12 дә керсә, вәгазь 11 дә башлана, халык сәгать 10 нарда җыелып, сабырлык белән имам вәгазен көтеп утыралар, зал уртасыннан махсус юл калдыралар). Вәгазь башланганчы ук фарыз, сөннәт заллары шыгрым тула, имамнар килә башлагач, уртадагылар торып басып, хәзрәтләрне ихтирам белән түргә озаталар иде. Бохарада укучы шәкертләргә дә шундый ук зур ихтирам күрсәтелде, барысын да залның алгы сафына озаталар иде.

Әхмәдзәки хәзрәт мәчеттәге вазыйфаларыннан тыш халык тарафыннан бик чакырулы булды. Мәҗлесләрдә һәрчак эчтәлекле вәгазь сөйли һәм һәрбер катнашучыдан Коръән аятьләрен укыттыра иде .

1967 елны 71 яшендә җәмәгате Зәйнәб вафат була. Аны Яңа Татар бистәсе зиратына җирлиләр. Бераз вакыттан соң, Әхмәдзәки хәзрәт Шәмсеруй исемле хатынга өйләнә. Ни сәбәптәндер, озак тормыйлар, аерылышалар. Аннары Галия исемле хатынга өйләнеп, гомеренең ахырына кадәр бергә матур гомер итәләр.

1980 нче елда Тәлгать хәзрәт Таҗетдин СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәтенең мөфтие итеп сайлана. Әхмәдзәки хәзрәт үлгәнчегә кадәр шул нәзарәтнең казые булып тора.

Әхмәдзәки хәзрәтнең шәкертләре санын төгәл итеп әйтү мөмкин түгел, чөнки ул гомере буе дәгъватта була, сабак бирә, вәгазь сөйли, динебезгә өнди. Аның шәкертләре арасында Татарстанның икенче мөфтие Госман хәзрәт Исхакый, Яшел Үзән районы мөхтәсибе Габделхәмид хәзрәт Зиннәтуллин, Казан шәһәренең мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдинов һ. б. күренекле дин әһелләре була.

Әхмәдзәки хәзрәт вафат булыр алдыннан, азан әйтә, намазга баса, «Әлхәм»ен укып бетерә алмыйча намазлыгына егыла. Галия абыстай аны тотып алып диванга утырта. Әхмәдзәки хәзрәт сөйләшә алмый башлый. Шул вакытта аларга «Мәрҗани» мәчетенең мөәзине Мөнир хәзрәт белән Госман хәзрәт Исхакый киләләр. Госман хәзрәт «Ясин» чыга. «Хәзрәт, без китәбез», дип саубуллашучыларга бармагы белән генә ишарә ясарлык хәле калган була әле. Мәчеткә кайтып җитүләренә «Әхмәдзәки хәзрәт үлде», дип Галия абыстай хәбәр итә. Бу хәл 1995 елның 2 июнь көнендә була. Бу хәбәрне шәкерте Тәлгать хәзрәт Таҗетдинга да җиткерәләр. Ул вакытта Тәлгать хәзрәт Уфада мөселманнар җыены үткәрә торган була. «Миннән башка җирләмәгез», – дип, кабат-кабат шалтыратып тора. Вакыты аз, кайтып өлгерә алмас дип, өйләдән соң Госман хәзрәт Исхакый Әхмәдзәки хәзрәткә җеназа намазын укый. Зиратка алып чыгарга җыенганда, аэропорттан автобус белән Тәлгать хәзрәт Таҗетдин 40 ка якын мөселман кардәшләре белән килеп җитә. Бик ашыгу сәбәпле, ул Башкортстан Президенты Мортаза Рәхимовка мөрәҗәгать иткән була. Илбашы үзенең шәхси очкычын бирә, шуның белән Казан һава аланына төшеп утыралар. Тәлгать хәзрәт Таҗетдин остазына үзе җеназа намазын кабат укый, Яңа Татар бистәсе каберстанына алып барып, Зәйнәп абыстай янәшәсендә җирлиләр.

*Нияз хәзрәт Сабиров,*
*ТҖ МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе,*
*«Апанай» мәчете имам-хатыйбы,*
*тарих фәннәре кандидаты*

# Мөслимә

# Исламда килен белән каенана мөнәсәбәтләре

Каенаналары белән уртак тел таба алмаган киленнәргә Ислам күзлегеннән нинди киңәшләр бирергә мөмкин?

Адәм балалары бу дөньяга сынау өчен җибәрелә. Шуңа күрә дә Аллаһы Тәгалә һәр кешегә төрле проблемалар биреп, аның Раббысына, намусына тугрылыгын, кешелеклелеген һәм сабырлыгын сынап карый.

Килен белән каенана мөнәсәбәтләре яңа гына килеп чыккан мәсьәлә түгел. Каенана киленнән, ә килен каенанадан зарлануы көндәлек тормышыбызның гадәти бер күренешенә әйләнде. Еш кына каенана белән киленнең каршы торуында кемнең хаклы, ә кемнең хаксыз булуын ачыклау бик кыен була. Яшьләрнең дә үзенчә яшисе килә, үзен кызганмыйча, бар көчен, гомерен малаен тәрбияләп үстерүгә багышлаган ананың газиз улы өйләнгәннән соң кинәт кенә икенче (ә бала туганнан соң өченче) планга күчүен авырлык белән кичерүен дә аңлап була кебек.

Әйе, проблема бар һәм аның чишелешендә психологлар олы кешенең тормыш тәҗрибәсе, зирәклеге һәм сабырлыгы шактый зур роль уйный, дип әйтәләр. Гадәттә, каенаналарга килен кешегә карата хәерхаһлы мөнәсәбәттә булырга, аны «минем малайны үз кулына төшергән начар ниятле көндәш» итеп кабул итмәскә киңәш ителә. «Киленем – улымның тормыш юлдашы, аның дусты, оныкларымның анасы» дигән карашта булу хәерледер. Шул ук вакытта киленнең олы кешене зурлый, хөрмәт итә белүе, каенананың шелтә белдереп, ә бәлки тупасрак та әйтелгән кайбер сүзләрен йөрәккә якын алмыйча, тынычлык хакына дәшми кала алуы да бик мөһим.

Гаиләдә татулык, мәхәббәт хисе сүрелмәсен, яхшы мөнәсәбәтләр саклансын өчен, килен дә, каенана да аларга кагылышлы кагыйдәләрне

белергә тиеш. Ислам динендә әхлакый кагыйдәләр буларак кабул ителгән шушы киңәшләрне карап узыйк.

## Килен өчен кагыйдәләр

1. Һәрбер кияүгә чыккан хатын-кыз аның гомерлек тормыш иптәше булган ирнең анасы белән даими аралашырга кирәклеген аңларга тиеш: ул хәзер аның икенче әни дәрәҗәсендәге якын туганы. Шуңа күрә киленнәргә каенананы үз әнисе итеп күреп, аңа шундый ук мөнәсәбәт белдерергә киңәш ителә. Газиз әнкәең итеп күрә алмасаң да, каенананың синнән олырак яшьтәге кеше булуы гына да аны хөрмәтләр өчен җитди сәбәп булып тора.

2. Һәр килен кеше кайчандыр үзе каенана булачак. Күп проблемаларга шушы фикерне истә тотып карау да яхшы нәтиҗә бирергә мөмкин.

3. Килен каенана белән бергә тормаса да, ул аның хәлен еш белешергә, телефоннан шалтыратып булса да, сәламәтлеге хакында сораштырып торырга тиеш.

4. Бәйрәм көннәрендә, каенананы бүләк биреп котларга кирәк. Бу үзара мөнәсәбәтләрне яхшыртырга, туганлык җепләрен ныгытырга ярдәм итәчәк.

5. Мөнәсәбәтләр яхшы, дустанә булган очракта да, каенананы олы кеше итеп күреп, аның белән ипле, әдәпле сөйләшергә кирәк. Ирнең олырак яшьтәге туганнары янында чыкы-чыкы килеп шаркылдап көлү ислам әдәбенә каршы килә һәм үзарадагы ихтирам-мәхәббәтне киметә.

6. Һәр кешенең башкалар белми торган кимчелекле гадәте, өй әһелләре генә белә торган үзенчәлекләре була. Каенананың шундый гадәтләре турында килен чит кешеләргә сөйләп йөрергә тиеш түгел. Килен каенана серләрен үз әнисе серләрен кебек сакласа, бу аңа карата ышаныч һәм хөрмәт хисе булдырачак.

7. Каенана белән ниндидер мәсьәлә буенча фикер алышканда, килен үҗәт һәм кире булырга тиеш түгел. Каенана белән риза булмаган очракта да, низаг учагына «утын» өстәмичә: «Әни, син хаклы, ләкин минем фикерем бераз башкачарак», – дию хәерлерәктер. Ә бөтенләй дәшмичә калу динебез буенча аеруча саваплы булып санала.

8. Әгәр низаг уты кабынган икән, ничек кенә ачу чыкса да, әдәп кысаларыннан чыкмыйча, хәтерне калдырырлык тупас, начар сүзләр әйтмәскә кирәк, чөнки низаг уты сүнәчәк, ләкин әйтелгән начар сүз озак истә калырга һәм алдагы мөнәсәбәтләрне салкын, киеренке итәргә мөмкин.

## Каенана өчен кагыйдәләр

1. Улың өйләнгән икән, бераз читкәрәк китеп, балаңа үз гаиләсен булдырырга мөмкинлек бир. Әгәр ярдәм кирәк булса, ул үзе дәшәчәк. Тәрбияле малай өчен әни барыбер гомергә Әни булып калачак.

2. Каенана йортына килгән килен кеше – үз әти-әнисе өчен йөрәк парәсе булган газиз баладыр. Хәзер ул сезнең гаиләгезнең бер өлеше һәм аны Аллаһ сезгә тапшырган бер амәнәт итеп кабул итәргә кирәк (каенана кешенең үзенең дә кайчандыр ире йортына килен булып төшкән елларны искә төшерү хәерле буладыр).

3. Киленгә үз кызыңа караган кебек җылы мөнәсәбәт белдереп, илтифатлы, игътибарлы булу тиешле. Аның белән боерык биргән сыман сөйләшмәгез. Бу үзара киеренкелек барлыкка килүгә сәбәп булырга мөмкин.

4. Улыгызның хатынын ничек бар шулай кабул итегез. Һәр кешенең ниндидер кимчелеге була. Аңа күнегергә тырышыгыз.

5. Улыгыз белән килен арасында ниндидер бәхәс, ызгыш килеп чыкса, араларына кысылмаска кирәк.

6. Чаманы белмичә, көн саен ниндидер киңәш биреп киленне аптырату, яшьләрне йөдәтеп бетерү дә файда урынына зарар гына китерергә мөмкин.

7. Аерым яшәгән очракта, яшьләр йортына алдан хәбәр бирмичә барырга кирәкми. Телефоннан бик еш шалтыратып та гел аптыратып тору киңәш ителми.

8. Үз балаларының кимчелекләрен яшергән кебек, киленнең дә кимчелекләрен яшерергә, башкаларга сөйләп йөрмәскә кирәк. Хәзрәтләр билгеләп үткәнчә, кимчелек турында никадәр күбрәк сөйлисең, шулкадәр ул арта, «күперә». Ә менә «киленем шундый әйбәт, моны да эшли, тегесен дә булдыра» дип сөйләү рөхсәт ителә.

Гаилә мөнәсәбәтләре – Ислам динендә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе. Әлбәттә, тормышта төрле хәлләр булырга мөмкин, һәр очрак өчен дә бердәм универсаль киңәш, бәлки, юктыр. Шулай да, туганнар бер-берсенең кадерен белеп яшәргә тиеш. Ислам динендә бер гаилә әһелләренең берберсе өчен дога кылуы – иң күркәм гамәлләрнең берсе булып санала. Шайтан вәсвәсәсенә бирелеп, якын туганың сиңа ниндидер авырлык китерсә яисә начар сүз әйтсә, төнге тынлыкта ихлас күңелдән Аллаһка мөрәҗәгать итеп, дога кыл: «Йә Раббым! Минем шушы туганымның (каенанам, киленем...) гөнаһларын гафу ит, күңелен йомшарт, Үз рәхмәтеңнән аерма, җәннәт әһеле булып яшәргә насыйп әйлә...». Шундый дога нәтиҗәсендә үз күңелең дә йомшарып, рәнҗү хисе юк булачак, аның урынына тынгылык вә рәхәтлек хисе барлыкка киләчәк. Аллаһы Тәгалә бит безнең бик күп хата-гөнаһларыбызны гафу итә. Шулай булгач, безгә дә башка кешеләрне кичерергә өйрәнергә кирәк. Ә тормышта килеп чыккан төрле хәлләргә килгәндә, «Бәкара» сүрәсенең 153 нче аятендәге Аллаһ нәсыйхәтен гел истә тотып яшәсәк иде:

إِنَّ اللَّهَ مَعَ الصَّابِرِينَ ﴿١٥٣﴾

**««Аллаһы Тәгалә сабырлар белән бергә».**

*Ришат хәзрәт Курамшин,*

*Кукмара мәдрәсәсе мөдире*

# Мирас

*Татар журналисты, мөгаллим һәм язучы Агиев Фәхрелислам тууына 130 ел.*

# Агиев Фәхрелислам Нигъмәтулла улы

## (12.03.1887–1938)



Пенза губернасы Краснослободск өязе (хәзерге Мордва республикасы Торбеево районы) Тенеш авылында туа. Башлангыч белемне әтисеннән ала. Экстерн рәвештә имтиханнар биреп, КТУШ таныклыгы ала (1908). Беренче Казан шәһәре рус-татар башлангыч училищесы укытучысы (1908–1915), «Ак юл» балалар журналы мөхәррире һәм нәшире (1913–1916). Беренче Бөтенроссия мөселманнар съезды делегаты (1917). Панисламизм дигән мөһер сугылып, Казаннан китәргә мәҗбүр була (1916), Пенза губернасы Краснослободск өязе Юнә авылына барып урнаша. Волость ярлылар комитеты рәисе, губернадагы татарлар арасында мәгариф эшләрен оештыручы (1917–1924). Мәскәүдә РСФСР Мәгариф нәшриятында инструктор-методист, СССР халыклары Үзәк нәшриятының татар бүлегендә секретарь (1924), Үзәк татар драма театры директоры. «Солтангалиевче»лектә гаепләнеп, кулга алына (1931), Ак диңгез – Балтыйк каналы төзелешенә җибәрелә. Шәхес культы корбаны. Реабилитацияләнә.

**Фәнни-педагогик эшчәнлегенең төп юнәлешләре:** уку-укыту, тәрбия мәсьәләләре; дәреслекләр төзү.

**Төп хезмәтләре:** Кыйраәте ибтидаия. – Казан: Мәгариф, 1908. – 36 б.; Мәктүб (Пенза губернасы мәдрәсәләре турында) // Әл-ислах. – 1908. – № 24. – Б. 15; Тәрбиягә даир // Әл-ислах. – 1909. – № 58. – Б. 2; № 60.

– Б. 2-3; № 64. – Б. 3-4; Мәскәүдә булу мөнәсәбәте илә // Мәктәп. – 1913. – №2. – Б. 52-55; Мөгаллимгә // Мәктәп. – 1913. – № 8. – Б. 190; Кыйраәт төрки – Казан: Мәгариф, 1913. – 67 б.; Сукыр Ильяс: Хикәя. – Казан: Мәгариф, 1921. – 14 б.; Кызыл йолдыз: Әлифба / автордаш Тимербулат Г. – М.: Татар-Башкорт Мәркәз Бюросы, 1924. – 80 б.; Хикәяләр җыентыгы. – М.: Нәшр. кооп. матб., 1926. – 60 б.; Мәрхәмәт: Хикәяләр һәм әкиятләр / Төз. Ибраһимова Ф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 112 б.


مكتب

مندرجات:

КАЗАНЬ
Электротипографія „УМИДЪ“.
1913.

«Мәктәп» журналының беренче саны

## Мәскәүдә булу мөнәсәбәте илә

[…] Башка халыкларның мәдәнияткә авыша башлаган көннәрендә бөек каһарманлык, бөек батырчылык күрсәткән зыялы яшьләре булганы төсле, безнең яшь йөрәкләребез дә хәзерге көндә мәйдан алганнар. Безнең дә яшь зыялыларымыз, шәхси бәхетләрен онытып, халкымызга мәгърифәт кертеп, барлык мәгълүматларын шул юлда чәчеп торалар. Мәдрәсәләремездән чыккан шәкертләремез мәдрәсәдә яткан көннәрендә күргән кысынкылыкларын, рәхәтсез көннәр үткәргәнлекләрен бөтенләй онытып… хәтта дөньяда шәхси рәхәт, бәхет вә тынычлы гомер барлыгын да онытып, кырмыскалар төсле һәр якларга таралышып муллалык вә мөгаллимлек урыннарын алырга тырышалар. Бу мөхтәрәм шәкерт – яшьләремез баскан бер җирдә яңа мәктәпләр салынмый калуын берәү дә

күрсәтә алмас! [...] тәмугъдан качкан төсле мәктәптән качып көннәрен үткәрергә өйрәнгән сабыйларымыз, бонлар килгәч тә күңелләрендә туган әллә нинди мәхәббәтле теләү илә тезелешеп мәктәпкә йөри башлыйлар. Алты-җиде ел мәктәпкә утын кисәге күтәреп йөреп, берни аңламый, язу-сызу белми вә зиһеннәренә мәңге бетмәслек тупаслык урнашкан хәлләрендә калган «егет»ләрнең үк энеләре, хәзерге көндә мәктәптән һәр көн ни дә булса белеп кайталар [...] (Б. 52).

## Тәрбиягә даир

Тәрбия – башка, мөтәрәкъкый (прогрессив – Ред.) халык каршында иң кирәкле мәсьәләләрдән саналса да, бездә бу көнгә хәтле бу мәсьәлә яхшылап кына мәйданга куелганы юк. Бездә (әгәр ялгышмасам) тәрбия юлында яңа ысуллар, яңа тәҗрибәләр, яңа фәннәр вә яңа кораллар чыгару урынына, егерме биш сәналек җәдид берлән кадим көрәше бетмәгән... бездә кара такталарны, көрсиләрне вә яңа форма берлән тегелгән (кызыл төймәсез) казакиларны... җәдидлектән санап ысулы тәрбия рәтенә кертеп вә шулар хакында бер дә кирәге булмаган сүзләр сөйләнеп вакыт үткәргәндә, безнең күршеләремездә көн дә диярлек яңа тәрбия журналлары арта барып вә шул юлда ничә, ничә еллар армыйча кылган хезмәтләренең йемешләреуларак төрле яңа тәҗрибәләр мәйданга атылалар. Мөтәрәкъкый халык авылларга мөгаллим булырга теләүчеләр өчен хосусый педагогический испытательный комиссияләр, учительский семинарияләр; шәһәр мәктәпләрендә мөгаллимләр хәзерләү өчен учительский институтлар вә



Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Фәхрелислам Агиев. 1908 ел (beznenmiras.ru сайтыннан)

гимназияләргә мөгаллим хәзерләү өчен филологический факультетлар хәзерләгәндә (болар безнең күршеләремездә күп заманнан бирле булса да, хәзер шулар өстенә уларак яңа вә яңалар һәрдаим ачылмакдалар), бездә – мәдрәсәләрдә мулла, мөәзин хәзерләп чыгармакталар…

Хәзерге тормышка гына түгел, гомумән: моннан әүвәлге булган вә киләчәктәге буласы тормышка ярарлык ысулы тәрбия күрмәгән мулла, мөәзиннәр – менә безне бу көнгә хәтле тәрбияләгән зат шәрифләр! Ә бит бер уйлап караганда: татар «мәдрәсәсеннән» чыккан бер шәкерткәнең ничә төрле исеме, званиесе бар? Мөгаллим, хатыйб, мөдәррис. Шушындый исемнәрнең хуҗасы шәкерт улыб, безнең буласы тәрбияләүчемез дә шәкерт – мөгаллим. Шул исемнәргә мөбәйяи (нигезләнгән – Ред.) мәдрәсәдән чыккан шәкертләр теләсә авыл вә теләсә шәһәр мәктәпләрендә булсын, бу көнгә хәтле мөгаллимлек хезмәте өстенә алырга хакы бар иде. Бит бу урында шәкерт бер дә гаепле дә түгел? Чөнки кайда вә ничек булса да, бит тамакны туйдырырга кирәк! Шуның өстенә дә хәзергә хәтле мөгаллим булу өчен хосусый яңа тәртип буенча имтиханнар тотарга кирәккән кеби, шундый имтиханнарны тотар өчен бу көнгә хәтле урын да юк иде. Һәм хәзер дә юк. […]

## Мөгаллимгә

Көннәрең караңгы… хезмәтең авыр; күп киртәләр
Һәр адымыңда синең. Юктыр көчең бит изсәләр
Искеләр!.. Яңакларың кипкән, кысылган күкрәгең;
Тик йөзеңнең уртасында изге нурлы күзләрең
Ялтырап, уйнап торалар! Әйе, шунда серләрең –
Син карап текәлеп сабыйларга һәм әйтеп сүзләрең,
Җаннарын шатландырып, күңелләрен шат уйнатып
Син аларны укытасың: дусландырып һәм шаулатып!
Шул сабыйларның киләчәк көннәрен ап-пакь итү,

Шат кылу күңелләрен һәм рухларын көчле итү,
Кулларыннан шул сабыйларның тотып алга җитү –
Менә алдыңда синең идеал!.. Шул идеалга җитү
Юк, җитү түгел, хата әйттем, җитәргә омтылу
Шул газиз идеал өчен бар тормышың корбан кылу –
Иң мөкаддәс эш синең карашта: ялгыз шул гына!
Син шуның алдында тезләнгән, торасың тын гына…
Тор шулай син тын гына! Бул… Бул каһарман! Бул батыр!
Үл… Изел! Ләкин тырыш: үлгәндә дә тамырың катыр!
Син, фәкатъ син бу гөнаһсыз яшь буынны коткарып,
Былчырак тормыш богауыннан, илаһи ут яныр
Шул нәзек, тапсыз күңелләрдә, бәхетле кылмасак,
Бар авырлыкка түзеп, алар өчен юл салмасак –
Беттеләр дип аларны! Дөм караңгы көн туар
Шул караңгылыкта көчләнгән тәгассыйб нык кунар
Яшь, фәрештә төсле, угъланнар кашына! Җаннары
Мәңге газапта калыр! Зәһәрләнер саф каннары!..
Син канатлан, и мөгаллим! Белгәнеңне калкан ит,
Бел – якын ярдәмчең Аллаһ! Изге юлдан алга кит!

*Резедә Сәфиуллина–Әл-Әнси ,*

*КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм шәрыкне өйрәнү институтының*

*«Язма мирас һәм археография» фәнни-мәгариф үзәге җитәкчесе,*

*Россия ислам институты доценты, филология фәннәре кандидаты*

## Нигъмәтулла хаҗи

Нигъмәтулла хаҗи Сибириядә «Бухарец» [Бохаралы] дип йөртелә торган мөселманнардан иде. Ерак бабалары, сәүдә өчен Бохарадан килеп, ислам хөкүмәтләре заманында ошбу җирдә урнашып калганнар.

Нигъмәтулла хаҗи Карамшак бине Сәедүк бине Касыйм бине Шәриф бине Әшрәф исемле кемсәнең углы иде. Атасы Карамшак яшь вакытында Төмән шәһәре янында Манчыл карьясенең Габделкәрим исемле байда приказчик иде. Мәзкүр бай Семи берлә Павлодар арасында Ямеш исемле казак-рус авылында сату кылып торды. Шул җирнең гадәт-горефләрен белеп бетердегеннән, баеннан рөхсәт алып, үзенә кәсеп башлады, вә үзе илә берлектә Габделкәрим байда хезмәт кылучы Ишморад Илбәков исемле авылдаш илә берлектә сәүдә кылырга керештеләр. Әүвәлләре казакъ арасында вак-төяк галантерия берлә йөреп сәүдә кылырлар вә, анлардан җон-ябага, сыйрия маллары [чимал] алып, Төмән шәһәренә китереп сатарлар иде. Сәрмаялары артып, эшләре бәрәкәт таптыгыннан соң, Эрбет ярминкәсеннән аршынлы маллар китереп, яхшы бәһаләр илә казакларга нәсиягә [бурычка] таратырлар иде. Моннан соң Павлодар шәһәрендә кечек бер дөкян [кибет] ачып, үзләренә күрә яхшы гына мөгамәлә кыла башладылар.

Ул вакытларда кыргыз җирләре иркен, аяклы мал күп булу сәбәпле, тире, җон-ябага, кыл бихисап булу өстенә, шул нәрсәләрне алучы аз булыр иде. Безнең тырыш Карамшак бабабыз иштә ошбу форсатларның кадерен белде. Казаклардан нәрсәне арзан вә күбесен дә алмашып алыр вә Төмән шәһәренә китереп тә яхшы бәһагә сатар иде. Эрбеттән фабрика нәрсәләрен очсыз алып, казакларга файда илә таратыр иде. Ошбу сәбәпле Карамшак бабай сәрмаялы вә яхшы байлар җөмләсенә керде. Бу вакытта угыллары да, җитешеп, кул арасына керделәр вә Карамшак бабай, үзе Төмәндә торып, угыллары Рәхмәтулла илә Нигъмәтулланы үзенең шәриге

[иптәше] Ишморадка тапшырды. Анлар исә, Семи шәһәренә барып, дөкян ачтылар. Соңрак Нигъмәтулла хаҗи атасы янына Төмәнгә кайтты вә аның урынына Хәбибулла Семигә китте.

Карамшак бабай вафатыннан соң угыллары Ишморад Илбәков илә аерылыштылар вә, риваятьләргә күрә, иллешәр меӊ сум сәрмая бүлмешләрдер.

**Нигъмәтулла хаҗи.** Тәрҗемә сахибе булган Нигъмәтулла хаҗи 1829 ел 18 октябрьдә (һиҗри илә 1245 ел 2 җөмадиел-әүвәл) Табул губернасы Төмән өязе Олуг Манчыл (русча – Янбай) авылында дөньяга килде. Анасы Зарифә бинте Габделхәй иде.

Рәхмәтулла исемле агасы вә Хәбибулла исемле энесе илә берлектә өч бертугандыр. Иҗтиһад илә аталарының юлында дәвам итеп, күп байлык, хасил иттеләр. Алма-Ата, Зәйсан, Чүгүчәк, Каркаралыга кибет ачып, галантерия вә тимер нәрсәләр илә сәүдә кылдылар. Болар сәбәбеннән бик күп адәмнәр, дәүләт табып, үзләренә кәсеп итәр булдылар. Нигъмәтулла хаҗи байлыгының нигезе ошбу рәвешчәдер.

**Гаиләсе вә уллары.** Нигъмәтулла хаҗи иң элек дәфга буларак 1847 ел Кечек Манчыл карьясендә Габбас мелла Теляшев исемле адәмнең Шәрифә атлы кызын никах кылды. Бу вакытта хаҗиның яше 18 дә иде. Бу хатыны, Габидә исемендә бер кыз дөньяга килдегеннән соң, озак тормый вафат итте. Аннан соң Олуг Манчыл карьясендә Ибраһим ахун исемле затның Гаенбану исемле кызын алды (1852 елда булса кирәк). Бу да озак тормый вафат булды. Моннан соң Кечек Манчылда Габделҗәлил бай Мирсәлимовның Хәербану исемле кызын никах итте. Моннан исә Гатаулла, Хәбибулла, Әхмәдшукый, Шәүкәт исемендә угыллары вә Рәйханә, Рәхимә, Шәкимә, Шәкүрә, Мәһәрбану исемле кызлары булды. Монда мәзкүр Гатаулла 1879 да 1 гыйнварда 12 яшендә вафат итте. Бу өченче хатыны һәм 1880 ел дөнья куйды. 1881 дә балдызы Нәгыймә Габделҗәлил кызын никах кылды вә ахыр гомеренә кадәр моның илә берлектә яшәде.

Габидә исемле кызын үзенең сабак шәриге Ишморад Илбәковның олуг углы Әхмәд исемле кемсәгә вә Шәкүрә исемле кызын да үз мәсҗеденең имамы ахун Мөхәммәд Йосыф Сәгыйдовка, Шәкимә исемле кызын Олуг Манчылда могтәбәр байлардан Мөхәммәд Сәлим хаҗи Мортазин углы Габделхәким әфәндегә тәвәзеҗ итмеш [никахлаган] иде. Үзенең вафатында ялгыз Шәкимә исемле кызы гына сәламәт булып, башкалары вафат иделәр. Хәзерендә Шәкимә дә вафаттыр. Бу көндә Нигъмәтулла хаҗиның Шәкүрә нам кызыннан ике кызы вә Шәкимә исемле кызыннан бер ир бала сәламәт булып, шулардан башка зәрите [оныклары] юк. Борадәрләре Рәхмәтулла илә Хәбибулла үзеннән мөкаддәм вафат булганнар иде. Рәхмәтулланың Хәсән, Нурулла, Гарифулла исемле угыллары вә Хәбибулланың да Хаҗигәрәй исемле углы сәламәт. Бу көндә Сайдуков фамилиясен шулар йөртәләр. Нигъмәтулла хаҗиның рәфикәсе [хатыны] Нәгыймә ханым сәламәт булып, үзенең борадәре Гариф хаҗи Мирсәлимов тәрбиясендә торадыр.

**Кабере.** Нигъмәтулла хаҗиның кабере үзенең карьясе булган Олуг Манчыл мазарлыгындадыр [зиратындадыр]. Кабере өстендәге язуы: «1901 елда 73 яшендә хаҗи Нигъмәтулла мәрхүм бине хаҗи Карамшак мәрхүм рамазан шәриф 21 дә [17 декабрьдә] дәфен булды. Рәхмәтулла галәйһи вәсәгат»тер. (?) Рәсеме табылмады. Юклыгы катгый, диләр.

**Тәхсиле вә әдәбият илә иштигале.** Нигъмәтулла хаҗи яшь вакытында Манчыл карьясендә Мөхәммәдрәхим мелла, Ибраһим ахун, мелла Хәмидулла Сәгыйдов, Галимҗан бине Гүиджан, мелла Бакый хаҗи исемле затлардан тәхсил итте. Сарыф гарәби юлап шул заман рәсеменә муафикъ гакаидәләргә кадәр мөртяб укып барды. Фәкать Нигъмәтулла хаҗиның гыйлеме мәдрәсәдән түгел, бәлки үз иҗтиһады илә соңра да хасил булган гыйлем иде. Һәртөрле рисалә вә китапларны моталләга кылыр [өйрәнер]. Гыйлем әһелләре илә мөзакәрә итәр [аралашыр] иде. Ханәсе әдәби бер мәҗлес булып, күңелләргә нәшат [сөенеч] вә гайрәт бирер иде. Кыйраәт

гыйлемендә мәһарәте [сәләте] бар адәмнәргә очраса, Коръән Шәриф укыттырыр вә үзе дә: «Мәрхәмәт кылып кыйраәтемне тыңлагыз да хаталарымны әйтегез!» – дип укып күрсәтер иде. Хаҗ сәфәренә бардыгында Мисырда туктап, шәех Мөтәвәлли хәзрәтләрендә кыйраәт өйрәнде вә мәшһүр Мөкъра Кәмал әфәнде оваллларыннан кыйраәт гыйлемендә мәәзүн булды [рөхсәт алды]. Бөтен мәҗлесе гыйлем мәҗлесе булып, гыйлемнән, мәктәп вә мәдрәсәләрдән, китап вә матбугаттан, китапханә вә мәсҗедтән сөйләнер иде. Тарих вә җәгърафия, хисап вә һәят фәннәрендә, хосусан ислам тарихыннан хазый [белемле] булып гыйлем фикъһедән дә хәбәрсез түгел иде. Гыйбарәте кагыйдәле, җөмләләре чыгышлы, рәсем хаты гүзәл булыр иде. Китапханә вә мәсҗед хакындагы вакыфнамәсен үзе тәртип итмештер. Гыйлем вә мәгърифәткә булган мәхәббәте Нигъмәтулла хаҗиның башкалардан имтияз иткән [аерган] бер сыйфаты булса кирәк. Башлап русча тарала торган «Всемирный иллюстрация» исемле газетаны укырга башлады. Соңра мәшһүр «Новый время»не укуда дәвам итте. Чыккан саннарыннан башлап «Тәрҗеман»ны мөртәб моталәга кылып [укый] барды. Болардан да башка Истанбулдан төрекчә, Бәйрут вә Мисырдан гарәпчә газета вә журналлар алдырып укыр иде. Бер җирдә ят бер китап барлыгын ишетсә, дәрхаль [шул ук вакытта] сатып алыр, хакы бәһале булуына илтифат итмәс, бәлки мондый надир [сирәк] китапларның кулына төшүе өчен сөенер иде. Ошбу тарикъ [юл] илә бик күп китап җыйды. Ләкин килгән меллалар, үзләренең иске гадәтләренчә: «Мин моны алып торыйм әле!» – дип, кирәк булса-булмаса алып китәрләр вә күбесенчә китереп бирмәсләр иде. Ошбу рәвештә китапларының заигъ булачакларын [югалганын] белдегендә, Нигъмәтулла хаҗи китапларына махсус бер китапханә ачарга карар бирде. Йортына килгән меллаларга: «Менә газета укыгыз, ул бик файдалы нәрсә», – дип, кулларына «Тәрҗемән» газетасын тоттырыр. Гомерләрендә газета исемен ишетмәгән меллаларның, багана сызыкларына игътибар итми, сызыклардан атлап тоташтан укып

китүләренә мыек астыннан көлеп утырыр вә бәгъзе вакыт: «Йә, дамелла! Газета ни сөйләде?» – дип сорар иде.

**Гыйлемгә хөрмәте.** Гыйлемгә, дингә хезмәт итү тугрысында Нигъмәтулла хаҗиның имсалы [мисалы] аз табылыр. Сибириягә гыйлем нурын башлап кертүче адәм Нигъмәтулла хаҗидыр. Үзенең яшь заманнарында мәдрәсәсенә мөдәррис итеп Гыйсмәтулла хәзрәтне алды. Ошбу мәдрәсәдә һәрвакыт 300 микъдарында шәкерт булыр вә фарыз сәдакасының күбрәген хаҗи ошбу мәдрәсә шәкертләренә бирер иде. Сыйныфка аерылган шәкертләрнең иң аз алучыларына 15 сум микъдарында өлеш чыгар иде. Үз байлыгы илә һәрвакыт Мәккә вә Мәдинә, Бохара вә Мисыр, Истанбул вә Казанда шәкертләр укытыр. Троицкий, Кышкар вә Эстәрлетамак кеби урыннарда моның мосарыфы илә укучы шәкертләр күп булыр иде. Ләкин бу кадәр мосарыфны тотып читләрдә укыткан кешеләре арасында һиммәтле адәм аз чыкты. Фәкыйрь адәмнәрнең балалары да гыйлемнән өлеш алсыннар өчен 1890 елда үзенең карьясендә бер ысуле җәдидә мәктәбе ачып, Истанбулдан (асылы Русияле) Мостафа әфәнде исемендә бер мөгаллим китерде. Бу вакытта Русия мөселманнары арасында ысуле җәдидәнең исеме дә юк иде. Мостафа әфәнде кайтып киттегеннән соң, Хәйрулла әфәнде Госманов килде, аңа да берничә мәгавен [хезмәт хакы] тәгайен кылып, тәкърибә [якынча] йөз кадәр баланы ысуле җәдидә илә укыттырды. Үзе һәр көн, мәктәпкә кереп, балаларның укуларын тәфтиш кылыр [тикшерер], үзе кыйраәт укытыр вә дәресләренең яхшылануын күрсә, гаять шатланыр иде. Балаларның күңелләре күтәрелсен, мәхәббәтләре артсын өчен, һәрберенә бер формада җөббәләр кидерер, Эрбет ярминкәсеннән һәрберенә читек, кәвеш, кәләпүш кеби һәдияләр [бүләкләр] китерер иде. Балаларның дәрес китапларын Истанбул вә Бакчасарайдан үз хисабына алдырып өләшер иде. Кырымда Гаспринский хәзрәтләре тарафыннан ачылган нәмунә мәктәбенә Манчылдан адәм күндереп укыттырды вә, ысуле җәдидә тәртибе үгрәнеп кайттыгыннан

соң, шул затны үз мәктәбенә мөгаллим насыйп итте. Соңра таштан бик яхшы итеп ысуле җәдидә мәктәбе бина кылды вә моның җөмлә мосарыфын [барлык чыгымын] үзеннән тотып вафат көненә кадәр дәвам иттерде. 1892 елда мәшһүр Мөкъра Кәмалетдин хәзрәтләрен үзенә китереп, аннан кыйраәт мишыкъ итте [өйрәнде] вә Коръән Кәримне башыннан ахырына кадәр мәгънәсе илә укып чыкты. Әтрафта [тирә-якта] булган мелла вә мөгаллимәләрне, хәлфә вә шәкертләрне җыеп, Кәмал карыйдан кыйраәт иттерде. Манчыл вә аның әтрафында кыйраәт гыйлемен яхшы белүче меллаларның күп булуына сәбәп ошбудыр. Дамелла Галимҗан әл-Баруди хәзрәтләре Кәмал әфәнде илә берлектә булып, хаҗинең авылдан өч чакрым мөсафәдә [ераклыкта] утарында берлектә яттылар. Нигъмәтулла хаҗи үзенең мәктәп вә мәдрәсәләренә хисапсыз мосарыфлар тоттыгы вакытта, чит авылларда булган мәктәп вә мәчетләр өчен дә күп иганәтләр кылыр иде. Биш мең сумнарга төшереп үз авылында бер кызлар мәктәбе дә тәэсис кылды [төзеде]. Ошбуның өчен Манчыл карьясендә 25 яшьтән түбән булган ирләр вә кызлар арасында язу язарга, укырга белмәгәне юктыр.

Сәхавәте [юмартлыгы], ингам [нигъмәт бирүе, сыйлавы] вә ихсаны [ярдәме, изгелеге]. Нигъмәтулла хаҗиның сәхавәте тәгъриф итәрлек [танытып бетерерлек] дәрәҗәдән күпкә югарыдыр. Капкасы бөтен халык өчен ачык булып, кунакларга махсус бер мөсафирханә бина иттерде вә аңар да кирәк кадәр хадимнәр [хезмәткәрләр] куйды. Мөселманнарны ачык йөз илә каршы алыр иде. Азия, Казан, Төркия вә Гарәбстан мөсафирлары өчен хаҗиның гомуми бер мәнзиле [йорты] булып, һәркем шунда төшәр вә хаҗәтләрен табып китәрләр иде. Моның ялгыз гына тәгам ашавы күрелмәмештер. Хосусан шәкертләр, гыйлем әһелләре, фәкыйрь вә гаҗизләргә ингам вә ихсан мул булыр иде. Шушы кадәр мал вә гомер сарыф итүе илә дә кәсепләренә зарар китермәс, бәлки көннән-көн иҗтиһадын арттырыр, баеп торыр иде. 1881 ел 16 майда Олуг Ман-

чыл карьясендә ут казасы булып, бөтен авыл диярлек (җәмгысы 160 йорт) янды. Бу вакытта Нигъмәтулла хаҗи хаҗ сәфәрендә булып, янып торган ут өстенә кайтып төште. Ошбу вакыт Нигъмәтулла хаҗи үзенең борадәрләре Рәхмәтулла, Хәбибулла илә утыз мең сумлык агач алдылар вә бөтен карьяне бер фасадта үз кесәләреннән салдылар. Фәкыйрь вә гаҗизләр өчен 175 гадәд [санда] йорт бина иттелекләре мәрвидер [мәгълүмдер]. Өйләр һәркаюсы алтыпочмаклы булып, башлары такта илә ябылды, йорт урыннары егерме сажин булып, ихаталары вә йорт әсбаплары тәмам кылынды. Йортларның һичбере мең сумнан кимгә төшмәгәндер. Хакларын кыямәт көнендә Аллаһы Тәгаләдән алмак шарты илә фәкыйрьләрне, гаҗизләрне ошбу йортларга кертеп утырттылар. Читтән килүчеләр Манчыл карьясенең төзеклегенә вә бер фасадта тәртипле салынуына гаҗәп итәләр. Аның сәбәбе исә ошбуында язган нәрсәдер. Һәрхәлдә, сәхавәте адәм ышанмаслык иде. Берьюлы бер кешегә мең сум сәдака иткән вакытлары булды. Бәгъзе бер чакларда кесәсендә бер тиен акчасы калмас, шушы вакытта килгән сәдака әһелләренә карз [бурычка] алып бирер иде.

**Башка әхвале.** Нигъмәтулла хаҗи үз гомерендә ике мәртәбә хаҗ кылды. Әүвәлгесе 1866 елларда булып соң сәфәре 1871–1880 елларда иде. Ошбу сәфәрендә Мисыр, Шам, Кодус, Брусә шәһәрләрендә сәяхәт итте вә, һәрберендә иркенләп торып, күп кешеләр илә күреште. Мәшһүр Мидхәт пашага юлыгып, озын вакыт сохбәт итте. Яныннан видагъ итеп [аерылып] чыктыгында, Мидхәт паша Нигъмәтулла хаҗига: «Хаҗи! Дәхи [кабат] күрешербез, ләкин Сибириядә түгел, бәлки монда, мин Сибириягә бармам!» – димештер. Ошбу сәфәрендә иптәшләре Семи шәһәрендә Садыйк бай Мусин, Тары шәһәренең Насретдин Аиткин иде. Хаҗ кылып Истанбулга кайтыгыннан соң тәкрар [кабат] Мисырга барып бер ай тордыгы вә шушы сәфәрендә Мисырдан Кодуска киттегендә шәех Мөтәвәлигә бер дәфгадә [мәртәбәдә] сигез йөз сум сәдака биреп киттеге риваять кылынадыр. Бервакыт Төмәннән кайтуын тимер юл күпере астында усаллар

көтеп торганнар. Ат тотучы, бу хәлне ерактан сизеп: «Хаҗи абзый, алда куркыныч хәл булырга охшый!» – дидегендә, хаҗи: «Йә, бернәрсә дә булмас, анларның максудлары мәгълүм», – димеш. Вакыйга күпергә килеп җиттегендә усаллар каршы чыгып атны туктаттыкларында, кесәсеннән йомарлап акча алып усалларга бирмеш тә, усаллар риза булып калмышлар. Элек вакытларында һич тә уңга, сулга карамый гаять иҗтиһад илә сәүдә кылган Нигъмәтулла хаҗи, Гатаулла исемле углы вафат булдыгыннан соң, гыйлем вә моталәгага һәм дә халык илә сохбәт итеп кунак сыйлауга бирелеп киттеге риваять ителенәдер. Кунак меллалардан бере, бик уйланып, «Фикъһе әкбәр»нең «Вәхруҗ әд-җал хак» дигән сүзен укыдыгында Нигъмәтулла хаҗи да: «Әфәндем! Шуннан соң ул гыйлем җәгърафият хак вә тәгаллимә фарыз кифаят димәгәнме?» – дип сорамыштыр. Соң сәфәреннән кайткач: «Хәрам шәрифкә сөялеп фикергә гарык булып утыручы гаять солтан бер кеше күрдем. Нинди адәм булыр дип беләсем килде вә янына барып сәлам биреп күрештем. Минем кайдагы икәнлегемне сорашкан соңгында белдем, бу кеше мәшһүр Шиһабетдин хәзрәт икән. Моны бик мәһабәт вә куркынычлы вә арыслан табигатьле бер адәм дип таптым. Шиһаб исеме чыкканда, меллаларның төкләре кабаруы вә артында сөйләп йөрүләре бушка түгел икән. Артында гына булмаса, аның алдына барып сүз сөйләргә олуг батырлык кирәк. Адәм булса шундый булсын!» – дип сөйләдеге мәрвидер. Бөтен дөнья халкын кабул итүче вә һәркемгә ачык йөз илә каршы булучы Нигъмәтулла хаҗиның мәшһүр шагыйрь Акмулланы кабул итмәдеге вә бу хакта үзе: «Ул кеше Казан меллаларына, Кышкар мәдрәсәләрендә укучыларга, җәннәт – хәрам, дигән. Шул сүз хәтеремнән чыкмый. Җәннәт, тәмуг хакында андый хөкемнәр итү һич тә ярамый», – дип сәбәп бәян кылдыгы сөйләнәдер. Ахыр гомерендә Семи, Яркәнд, Колҗа тарафларына сәяхәт итте, Алма-Ата шәһәрендә рәфикасен [хатынын] калдырып, үзе Бохарага барды. Бохара мәдрәсәләрен бина кылдыручыларның һиммәтләрен [тырышлыкларын] тәхсин кылып [мак-

тап]: «Зиннәтле мәсҗед салдыруга күрә истикъбале [киләчәге] тәэмин ителгән мәдрәсә тәэсис итү [төзү] кирәк икән. Шуны яхшы белдем. Ләкин инде эш үтте», – дип сөйлидер иде.

**Мәсҗеде вә китапханәсе һәм мәдрәсәсе.** Нигъмәтулла хаҗи илә борадәрләре Рәхмәтулла вә Хәбибулла әфәнделәрнең иң олуг хәератлары – үзләре дөньяга килгән ватан асыллары Олуг Манчыл карьясенә салган мәсҗедләредер. Бу мәсҗед ике катлы булып, мавританский стильдә, алты гадәд чуен багана узерендә корылган. Унбиш гадәд гөмбәздән гыйбарәт буларак бина ителмештер. Бинасы 1884 тә башланып, 1888 дә тәмам булды. Моның асыл фасадын Нигъмәтулла хаҗи үзе төзеп бирмештер. Гәрчә тыштан күренүдә башка мәсҗедләрнең биналарыннан күп аермасы булмаса да, эчендә аермасы күптер. Тәрәзә түшәме (тупса) вә баскычлары саф мәрмәр ташыннан ясалмыштыр. Эчендә исә солтан Габделхәмид хан тарафыннан һәдия ителгән [Пәйгамбәребезнең] чәч бөртеге мөбарәк булып дикъкать илә хифыз ителенәдер. Мәсҗеденең ихатасы эчендә таштан бина кылынган өч бүлмәле биек бер китапханәсе бар. Бер бүлмәсе китаплар торыр өчен, икенчесе – моталәга [уку] урыны, өченчесе – хафиз китапка махсус истирәхәт [ял итү] урыныдыр. Китапханә һәр көн ачык торыр, сүз язып алучылар өчен каләм, кәгазь, кара хәзердер. Китапханәдә 2200 җилдтән [томнан] артык язма вә матбуг [басма] китап бар. Кулъязмалар арасында бик иске әсәрләр вә тарихи ядкәрләр муҗудтер [бихисаптыр]. Бу китапларны Бохара вә Төркестан тарафыннан вә 1880 ел икенче дәфга булган хаҗ сәфәрендә төрле шәһәрләрдән сатып алып китермештер. Китапханәнең байтак меңнәргә төшүендә шөбһә юк. Мәсәлән, өч җилд кулъязма Мохит Борһани китабын Бохарадан 700 сум бәрабәренә алдырган иде. Соңгы хаҗ сәфәрендә сарыф ителгән утыз алты мең сум мосарыфның иң күп өлеше дә китаплар өчен киткән булуында шөбһә юк. Фәкать тәәссефтер [кызганычтыр] ки, бу китапханәдән хакы илә истифадә кылудан [файдаланудан] безнең җәһаләтебез [аңсызлыгыбыз,

белемсезлегебез] манигъдыр [тыелгандыр], халыкның тәнвир [яктырту, нурландыру] вә тәвассыг әфкяренә [акылы киңәюгә] хезмәт итмәк нияте хәйриясе илә бина кылынган китапханәсенә күрә дә күбрәк. Хосусан җомга көннәрдә бер тәкам [төркем] эшсез-көчсез адәмнәр, җыелып, ат вә тире бәхәсләре илә шөгыльләнәләр вә харчивня урынында истигъмаль кылалар. Ошбу мәсҗед янында асты таш вә өсте агачтан бина ителгән мәдрәсәсе вә аның янында да таштан салынган ашханә вә җылы госелханәсе, мөгаллим өчен урыннары бар. Кәзалик [шулай ук] мәдрәсә янында ике бүлмәле, ике коридорлы мөкәмәл [камил] сурәттә таштан эшләнгән бер ысуле җәдидә мәктәбе бар. Ошбу мәсҗед вә китапханә, мәдрәсә вә мәктәпләр өчен никадәр мосарыф тотылдыгы ачык мәгълүм булмаса да (чөнки хаҗи үзе моны үзе һич кешегә сөйләмидер, сораучыга әйтмидер иде), кәнди сәламәт вакытында вәкиле булып хезмәтләрен кылучы Гайнулла әфәнде Салихов риваятенә күрә, тәхминән [якынча] ике йөз мең сумнар хиражәт тотылмыштыр. Рәхмәтулла, Нигъмәтулла, Хәбибулла байлар, безнең Русияле мөселман байларының күбесе мисалында, ошбу биналарны, салдырып та, милләт өстенә ташлап китмәделәр, бәлки ошбу кылган хәератларының кыямәт көненә кадәр дәвамы өчен (ысуле җәдидә мәктәбе хариҗ [мәктәбеннән башка]), мәсҗед, китапханә файдасына гомерлек буларак унтугыз мең сум акча вакыф итеп дәүләт банкасына тапшырмышлар иде. Моннан һәр сәнә өчен алты йөз җитмеш сум фаиз [процент] килә вә шуннан имам вә мөәззин һәм дә хафиз кятиб вә мәсҗед караучы хезмәткәрләргә айлык вазифа бирелә, керосин вә шәм кеби хаҗәтләргә сарыф ителенә вә шуннан артканы да сберегательная кассага салынадыр. Ләзем вакытта моннан алынып, Тәгъмирләренә [чыгымнарына] тотыладыр. Кылган эшне җиренә җиткереп кылу ошбу рәвештә булса кирәк. Изгелекне кылдылар, ләкин милләт өстенә ташлап китми, бәлки бөтен эшен бетереп киттеләр. Ысуле җәдидә мәктәбен исә: «Бу мәктәп инсаннарның хәяты хөкемендәдер, шуның өчен аны халык

үзләре алып барыр, хосусан авылыбызда бездән башка да байларыбыз күп, һәм саваплы эшне без үзебез генә җыеп алып, башкаларны мәхрүм итәргә теләмибез, анларга да калсын!» – дип булса кирәк, халык өстенә калдырганнардыр. Ләкин мәрхүмнәрнең хөсне зан итеп калдырган адәмнәре, үзара низаглашып, мәктәпне көч-хәл илә генә алып баралар. Бу эшләрдә дә: «Шулкадәр дәүләтле була торып, бер мәктәп тә тәрбия итә алмыйлар», – дип кешеләрдән сүз ишетмәс өчен генә булуы аңлашыладыр. Мәсҗед хозурында имам һәм мөдәррисләр өчен вакыф иткән биналар да бар. Дәресханәсе дә таштан бина ителгән.

**Әхлагы.** Нигъмәтулла хаҗиның әхлакы игътибарга алынса, һәркем өчен үрнәк булырга ярарлыктыр. Юмартлыгы илә мәшһүр булу кеби хөсне [күркәм] холкы вә адәмчелеге илә дә мөмтаз [башкалардан аерылган] иде. Бала вакытында иптәшләре илә орышып-сугышып йөрмәде, кирәк яшь вә кирәк олуг вакытында мөгамәләр вә яман сүзләргә, нигездә мокабәлә итмәде, үзе һичбер адәмне рәнҗетмәде вә гомерендә гайбәт сөйләдеге ишетелмәде. Хәтта хозурында иң фасикъ [бозык] бер адәмнең гайбәтен сәйләндегендә хуш күрмәс вә риза булмас, әгәр дә сүз озынга китә башласа, икенче бер сүз табып, шуңа борыр иде. Бер адәмнең гыйлем вә кәмяләте, хөсне холкы вә һиммәт илә тәгъриф кылынуын [танылуын] ишетсә, шуңа кәефе килер, хозурланыр вә шул сүзгә каршы: «Аны мин дә шулай зан кыладыр идем, дөрес икән!» – дип кушылыр иде. Мәҗлесендә бай вә фәкыйрь, карт вә яшь, сәлим [сәламәт] вә сәкыйм [авыру], надан вә галим өчен якты йөз күрсәтер вә һәрберенә үзләренә монасыйп сүз табар вә барчасын риза кылыр иде. Бәгъзе адәмнәр гомуми гадәткә күрә хаҗины үзләренә дошман вә наразый хисап кылып йөрсәләр дә, анларның мондый эшләрен белә торып, һәмишә анларга өлфәт вә мәхәббәт узерендә булыр иде. Гомерендә бер адәмне оялтыгы вә йөз пәрдәсен җырттыгы булмагандыр. Хадимнәре бер адәмне үз хозурына яклап китереп: «Фәлән нәрсәне угрылаган вакытта тоттык», – дидекләрендә: «Юк, бу адәм ан-

дый угры түгел, ни булса да бер ялгышлык булгандыр, җибәрегез!» – дип азат итмеш вә соңра, шул адәмне аулакка чакырып: «Хадимнәрем сине рәнҗеттеләр, риза бул!» – дип, бишәр сум сәдака биреп җибәрмештер. Иң хозурландыгы нәрсә адәм шатландырмак, кешеләрнең зарур нәрсәләрен җитештермәк, йомышларын үтәмәк, мәшәкать вә фәлакәтләрдән хиляс иттермәк вә ике дошман арасын килештермәк иде. Кыз карендәшләренә гаять шәфкатьле булып, берәр җирдән йөреп кайтканда, анларга һәдияләр алып кайтыр иде. Бәла вә казаларга тәхмил [дучар] булып никадәр кыз балалары вә бөтен ир баласы үзе сәламәт вакытта вафат итеп беттеләр исә дә, җәзәгъфәзгъ итүе, зарланып моңланып сөйләве беленмәде. Хосусан зәкявәт [зирәклек] вә рәшид [батырлык] галәмәтләре күрелгән Гатаулла исемле углы вафат булдыгында күңеленә гаять йомшаклык килсә дә, һичбер шикаять итмәде. Бер кызы вафат булган вакытта, шуны кунакларына белдерми, һәмишә анлар илә сөйләшеп утырдыгы мәрвидер. Манчыл яндыгыннан соң халыклар Нигъмәтулла хаҗи хозурына барып: «Алланың казасына, ачуына очрадык, яндык, көйдек, харап булдык бит!» – дидекләрендә хаҗи: «Һич кайгырмагыз, зарланмагыз, шикаять кылмагыз, бу Алланың ачуы түгел, бәлки нигъмәте! Алла насыйп итсә, авыл әүвәлгедән яхшы сурәттә бина кылыныр, сез әүвәлгедән бай булырсыз, югалган бернәрсә дә юк, ни өчен кайгырасыз?» – дип, фәлякәтзадәләрнең [бәхетсезлеккә дучар булганнарның] янган йортларына салкын су сибеп җибәрде вә йортларын тәгъмир кылып [төзеп] бирде. Филвакыйг [чынлыкта] халыклар бернәрсәләрен дә югалткан булмадылар.

(Ошбу тәрҗемәи хәл бу көн Павлодар шәһәрендә имам вә мөдәррис Габделгани әфәнде ибне мелла Габделкәрим тарафыннан, Гөмән якынында (авыллары мәгълүм түгел) Салих Кәмал Садыйков, Нигъмәтулла Мөслимов тарафыннан, Олуг Акъяр карьясендә мөгаллим Хөҗҗәтулла тарафыннан язылган мәктүбләрдән ңыелып тәртип кылынды. Бу адәмнәрнең бер-беренең мәктүбләре үзләренә мөстәкыйль сурәттә ба-

сылса, бик күп фикер җөмләләр булачак булды. Чөнки бәгъзе бер вакыйганы һәрбере язмыштыр. [...] Бергә җыюны зарур күрдек. Әгәр дә бәгъзе ялгышлар киткән булса, игълям кылуларын [белдерүләрен] үтенәбез.)

Нигъмәтулла хаҗины без үзебез күрдек. Уфа шәһәрендә тордыгыбыз вакытларда ике мәртәбә безгә килеп, һәрбер мәртәбәсендә байтак көннәр торып китте. Гомуми мәҗлесләрдә бергә булдык. Вакытыбызны белештереп, мәнзилебезгә [йортыбызга] килеп тә күп дәфгаләр утырды. Мәэюс [өметсез] адәм түгел, бәлки мөселманнарның истикъбальләрендә [киләчәкләрендә] өмиде зур иде. Бер кеше өстеннән шикаять кылмады, дөньядан бервакытта зарланмады, иҗтимагый түбәнлекләребезне, дин вә гыйлем тугрысында булган косурлыкларыбызны [кимчелекләребезне] кешеләр өстенә ташлап утырдыгын ишетмәдем. Русиянең эчендә вә хосусан Сибириядә «ысуле җәдидә» илә дәрес укуны ошбу зат тәэсис итте [башлап җибәрде]. Халыкларның сөйләүләренә караганда, җумартлыгы, үзенә вә мохитенә нисбәт ителдегендә, «бармакидлар» юмартлыгына охшыйдыр.

Рәхмәтулла, Хәбибулла нам борадәрләре [бертуганнары] илә берлектә вакыф иткән китапларының вакыфнамәләре Оренбург Духовный собраниесендә булган вакыфлар дәфтәренә 17 нче гадәд буларак язылмыштыр. Ошбу вакыфнамә 1302/1888 тарихында 14 нче рабигыльахир (5 декабрь) дә тәртип кылынып, ахырында: «Рәхмәтулла Карымшак углы Сәйдуков, Нигъмәтулла Карымшак углы Сәйдуков, Хәбибулла Карымшак углы Сәйдуков дия имза итмешләр вә мәһәр салмышлар. Шаһит буларак ошбу адәмнәрнең исемнәре язылмыштыр: мөдәррис мелла Гыйсмәтулла ибне мелла Сәйфетдин, Галимҗан Гүидҗан углы, Мирза Мөхәммәд Мөхәммәдзариф углы, Фәйзулла ибне мелла Мөхәммәдзариф. Мелла Сабитбаш әл-мәрхүм, Мөхәммәдкәмал мелла Хәмидулла углы, мелла Хәбибулла Мамыш углы, Рәхмәтулла Шәман углы, Мәлкәй Мортаза углы, Габделлатыйф Алиш углы, Дәүләтшаһ Габделкәрим углы,

Әхмәд Ишморад углы Илбәков, Мөхәммәдвәли Мөхәммәдкалый углы, Габделмәннаф Рәҗәб углы, Мөхәммәдшакир Мөхәммәдвәли углы, Мөхәммәдсәфәр Мәүләкәй углы, Габделҗәббар Миңлебай углы, Мифтахетдин Ишморад углы, Әхсән Мирмөхәммәд углы, Мөхәммәдгали Сәфәргөмад углы. (Ошбу вакыфнамә сурәте «Асар»да язылган булса да, теле авыр, үзе озын булдыгыннан, укучыларның ялыгуларыннан куркып, монда күчермәдек. Күрәсе килгән кеше «Асар»га мөрәҗәгать итәр.)

Безгә иң соң язган мәктүбе [хаты] ошбу: «Зиядә гыйззәтле вә мөкәррәмәтле [хөрмәтле] казый әл-ислам әфәнде хәзрәтләре җәнабы галиләренә бик күп сәлам итеп, догаларыннан риҗа [өмет] вә нияз итәбез [үтенәбез]. Сәгадәтле мөфти әл-ислам хәзрәти җәнапларына, ышандак казый әл-ислам әфәнделәргә күп сәлам әйләп, догаларын риҗа итәбез. Үзебезне Нигъмәтулла фи-әл-хал сыйххәт вә гафиять [саусәламәт] узерендә беләләр. Мелла Килдеярны Сибириягә озаткач, августта җәмәгатебез илә Төмәннән Табул, Тара, Павлодар аркылы Семигә килеп кунаклап йөрдек. Аннан Алма-Ата шәһәренә килеп, шунда үз йортыбызда тордык. Алучы булса, йортыбызны сатар идек, дисәк тә, алучы күренмидер. Зилзиләдән соң харап булган гыймарәтләр [корылмалар] күп, сатучылар да күп, имеш. Шәһәренең утырмыш бик яхшы урамнарында һәр өй янында тагда агып килгән арыклардан су шаулап агып торадыр. Һәр ике тарафта урамнарда утыртылмыш тирәк агачлары вә каюларының курасында бакчалары да бар. Җимеш агачлары күп була, имеш. Монда килсәк тә ят булып күрелмәде. Күргән вә күрмәгән меллалар, ага-эне вә әхбаблар [дуслар], гүзәл-гүзәл адәмнәр бар, имеш. Үзебезнең монда 35 сәнәдән бирле сатуларыбыз булса да, килдегебез юк иде. Декабрь башында арыклардан су тукталды, кар явып, чана төшеп торадыр. Кыш озак булмый, диләр. Түгәрәктә казак таифәсе күп. Һәр тарафтан җыелмыш һәртөрле җенесләр һәм шәһәрдә күп күреләдер. Татар нугайларның ике, сарт һәм кашкарлыларның ике, дүнкәни таранчыларның ике мәсҗедләре

бар. Дүнкәннәр хытайча [кытайча] сөйләшәләр. Җомга намазына икамәт әйткәнче, имамнары җәмәгатькә каршы аяк үзрә торып хытай теле илә вәгазь итәләр, соңрак намазга керешәләр. Гомер газизләрне теләп язучы кемнәләре Нигъмәтулла Сәйдуков. 23 декабрь. 1899 ел».

Ошбу мәктүптә мәзкүр булган Килдеяр Табул губернасы Ялутыр өязе Сөнгел волосте Табыг Габделгафур Бакин исемле бер кемсә углыдыр. Сахалин җәзирәсеннән [утравыннан] булган мөнәфи мөселманнар үзләренең диннәрен онытмас һәм дә гыйбадәт вә бәйрәмнәрен вакытларында иҗарә кылдыклары өчен дия бер имам җибәрелмәкне Духовный собраниедән сораганнар иде. Собрание исә шунда бер имам җибәрмәк өчен хөкүмәттән рөхсәт һәм дә хәзинәдән мәгашлык [акча] үтендегендә хөкүмәт тарафыннан: «Имам җибәрелмәк хакында бездән манигъ юк, ләкин хәзинәдән мәгашлык бирергә мөмкин түгел», – мазмунында [эчтәлегендә] җавап бирде. Шуның өчен мөфти хәзрәтләре әл-хаҗи Мөхәммәдьяр Солтанов бу тугрыда могтәбәр адәмнәргә мөрәҗәгать кылып караса да сикереп чыгучы бер адәм күрелмәде. Ахырында Нигъмәтулла хаҗига белдердегендә хаҗи үз мосарыфыннан Килдеярны Сахалин җәзирәсенә җибәрде. Иштә, бу адәм беркадәр йөрдегеннән соң мәмләкәткә кире кайтып, Уфага һәм килеп китте.

Халыклар, гомуми сурәттә солдат алынуга авырсынып йөрделәрендә, Нигъмәтулла хаҗи үз кавеме булган бухаристлардан солдат алынмау өчен тәәссеф кылып [үкенеп] сөйләдеген ишетеп тәгаҗҗеб иттем вә моның сәбәбен сорадым. Хаҗи исә: «Халкыбыз яшьтән үк куркак булып үсәләр, бер дә кеше күрә алмадыкларыннан вәхши табигатьле булалар, һичнәрсә белмиләр, ни сөйләүче булса, шуңа ышаналар, хәтта иң зәбун [куәтсез] халыклар да үзләрен һәртөрле юллар илә алдый алалар. Фикерләре ачылмый, зиһеннәре эшли алмый, бернәрсәгә дә йөрәкләре җитми. Әгәр дә Харьков илә Полтава, Тифилис илә Варшаваны күреп кайтсалар, аякларын кайдан алып, кая куярга икәнлеген үгрәнеп килсәләр,

дөньяның бик күп төрле хәлләре бар идеген белсәләр, бәлки бик күп файда булыр иде», – диде. Ошбу мөнәсәбәт илә хаҗига бу хикәятне сөйләдем: «Моннан кырык еллар мөкаддәм Бәләбәй өязендә Габделсаттар исемендә бер олуг мөдәррис вә шәех булган. Безнең гамәлләребез, хәлләребез арасында аның шәкертләре бар иде. Шул вакытларда башкортларның үзләренә махсус гаскәре полклар булып, халыклар бу гаскәрләргә «башкортлар командасы» дип исем биргәннәр. Габделсаттар хәзрәт шул заманның мәгълүматлы бер адәменә юлыккан да: «Түрә! Командада йөреп кайтучыларның сүзләренә күрә, «ефритлар» дигән бер кәлимә күп йөри, шул ефритлар кем булалар?» – дип сораган. Теге адәм ефритларны: «Хәзрәт, ул ефритлар Оренбург шәһәрендә казакларның башлыклары була, казаклар аның итекләрен тазарталар, хәтта атын да юып карап торалар, аның алдында булганда утырып тормыйлар, әгәр дә урамда очраса, хәтта икенче яктан бара торган вакыты булса да шып итеп туктыйлар да, аңа карап, кулларын башларына куеп хөрмәт итәләр. Ул үтеп китკәнче, аңа карап, хәтта артыннан да күзләре берлә озатып калалар», – дип тәгъриф иткән [аңлаткан]. Шуннан соң хәзрәт, халыкларның тәртип белмәүләре вә низамга ригаять итмәүләре өчен, һәрвакыт: «Безнең халык Оренбургка бармыйдыр, ефритларны күрмиләр, шуның өчен тәртип белмиләр!» – дип зарланыр булган», – диләр. Хаҗи исә моңа кәефе килеп көлде вә: «Минем фикерем хәзрәт фикеренә тугры килгән икән, бу мәсьәләдә хәзрәт миннән мөкаддәм төшенгән икән», – диде.

Мәктүпләр илә дә үзенә дәгъвәт кылган [чакырган] иде, ләкин гомерне «булса иде дә, әйдә булсын иде инде» илә үткәрдем, шуның сәбәпле китапханәсен күрү, асаре кадимәдән булган кулъязмаларын зиярәт итү безгә мисер [мөмкин] булмады. Иртәгә китәсе кичендә Баһаветдин әфәнде йортында төн буе мөсамәрә кылып [сөйләшеп] утырган идек, мәгәр дә шул мәҗлесебез ахыр гаһедебез [күрешүебез] булган икән. Шуннан соң тәкрар күрешә алмадык.

Оренбург Әхмәд, Габделгани вә Мәхмүд байларның мәктүб вә мәсҗедләр тугрысында булган һиммәтләрен, мәктәпләргә шәкертләр җыю хакындагы иҗтиһадларын хикәят иттегемдә бик мөтәэсир булды вә: күрәсең, анларның Заһирләре [ярдәмчеләр], әфкярдәшләре [фикердәшләре] бар, без моннан мәхрүм булдык», – диде.

«Һәят [астрономия] фәнендә Әхмәд Мохтар паша тарафыннан тәртип ителгән яхшы бер китап бар диләр, хаҗга баручыларга шул әсәрне алып кайтыр өчен акча да биргән идем, таба алмадык, дип, акчамны кайтарып бирделәр», – дип сөйләдегемдә көлде вә: «Бу эш сезнең файдагыз өчен шулай булган, ул китап миндә бар, мин аны сезгә һәдия кылып җибәрермен», – диде һәм дә йортына кайтуы илә мәзкүр китапны җибәрде. Китапханәбездә җилд номерлары 145–146 булган ике җилд китап, Нигъмәтулла хаҗи ядкәрләредер.

«Үзенең сәхавәте [юмартлыгы] сәбәбеннән, бөтен байлыгын вөҗүһ хәергә сарыф кылып вафат итте», – диярләр. [...] Фәкать Нигъмәтулла хаҗи үзе яшәргә тиешле булган заманнан беркадәр мөкаддәм килгән адәм иде. Шуның өчен дә гыйлем юлына түккән байлыгы нисбәт илә нәтиҗәсе азрак күрелде.

Шулкадәр кыйммәтле мәсҗед илә газиз әсәрләр җыелган китапханәне бер авылда бина кылуына сәбәп үзенең ватаны, кавем кабиләсен сөю булса кирәк. Юкса андый әсәрләр, хосусан шул дәрәҗәдә кыйммәтле китапханә, шәкерт вә мөгаллимнәр күп җирләрдә тәэсис кылынырга [төзелергә] тиешле иде.

Зур бәдәнле, ачык йөзле, зур күзле, мөлаем сүзле булып, кеше сүзен дикъкать илә тыңлар, үзе сөйләгәндә җөмләләрне өзеп, бәхәсләрне аерып бик ачык кылып сөйләр, кеше илә җиңешмәс бер сүзне тәкрар кылмас, мөдаһәнәсез [икейөзле түгел, ялагайланмый торган], халис [саф] вә риясыз бер адәм иде. Бер мәҗлестә бик күп тугрыларда вә бик күп адәмнәрдән зарландылар, сыкрандылар, шуларның һәрберенә Нигъмәтулла хаҗиның:

«Ни эшлисең соң, күпчелек!» – дип сүзе кушып торуын тәҗрибә кылып утырдым.

Нигъмәтулла хаҗи вафат итсә дә, хәераты сәясендә һәмишә хәяттадыр. Иншалла моннан соң да исеме онытылмас. Аллаһы Тәгалә гарикъ рәхмәт итсен!

Шура. – 1913. - №17. – б. 513–516; №18. – б. 545–548.

Мәкалә *Фәхреддин Ризаэддин Мәшһүр адәмнәр: «Шура» журналы сәхифәләреннән (Казан: Рухият, 2012)* китабыннан алынды

# Ислам тарихы

*(Ахыры. Башы журналның 14, 15 саннарында)*

## Иң мөгътәбәр хәдис китаплары

Коръәннән кала Ислам диненең нигезе хәдистер. Шунлыктан хәдис китаплары Коръәннән кала иң кадерле, иң хөрмәтле китаплардыр. Иң башлап язылган хәдис китабының «Әл-Мүвәттә» икәнлеген югарыда сөйләнеп узган идек. Аны тәртип итүче кешенең дүрт имамның берсе булган имам Мәлик хәзрәтләре икәнлеген дә сөйләгән идек. Әл-Мүвәттәдән соң язылган хәдис китапларының иң олуг вә иң кадерлеләре алтыдыр. Болардан берсе «Сахих Әл-Бохари» исемендәге китап булып, Коръәннән кала иң мөгътәбәр вә иң әнәбәтле китаптыр. Аңарда барлыгы 9082 хәдис бар. Бу китапны тәртип итүче кеше өченче гасырның олуг галимнәреннән булган имам Бохари хәзрәтләредер. Ул Һиҗрәтнең 194 нче елында Бохара шәһәрендә дөньяга килгән. Ул бик үткен зиһенле булу өстенә, гыйлемгә гаять дәрәҗәдә хаслы булган. Гыйлемгә гашыйк булуы аркасында ул төрле шәһәрләрдә йөреп, төрле галимнәрдән дәрес алган вә хәдис откан. Шулай итеп иң олуг хәдис галимнәреннән булып киткән. Аның ошбу «Сахих Әл-Бохари»дан башка әсәрләре дә бик күптер. Имам Бохари 62 яшькә җитеп, Һиҗрәтнең 256 нчы елында вафат булган. Кабере Сәмәрканд шәһәренә якындыр. «Сахих Әл-Бохари» төрле җирләрдә әллә ничә мәртәбә басылган булып, һәрбер дин галименең кулында бар диярлектер.

Хәдис китапларының «Сахих Әл-Бохари»дан кала иң мөгътәбәр вә иң кадерлесе – «Сахих Мөслим»дер. Бу китапта бөтенесе 12000 хәдистер. Моны тәртип иткән кеше хәдис галимнәренең иң олугларыннан булган имам Мөслимдер. Ул Һиҗрәтнең 206 нчы елда Нисабур шәһәрендә дөньяга килгән. Ул да, имам Бохари кебек, бик күп шәһәрләрдә йөреп,

олуг галимнәрдән, вә шул җөмләдән имам Бохари хәзрәтләреннән дәрес алган вә хәдис өйрәнгән.

Имам Мөслимнең ошбу китаптан башка да әсәрләре күптер. Ул 55 яшькә җитеп, 261 нче елда Нисабур шәһәрендә вафат булган. Ошбу «Сахих Мөслим» белән «Сахих Әл-Бохари»не икесен бергә кушып, «Сахихәйн»дип йөртәләр.

Коръәннән кала иң мөгътәбәр хәдис китапларының өченчесе – «Сунәнү Әби Дауд»тыр. Анда барлыгы 3800 хәдис шәриф бар. Бу китапны тәртип итүче кеше иң мәшһүр хәдис галимнәреннән булган имам Әбү Даудтыр. Ул Һиҗрәтнең 202 нче елында Бусра шәһәрендә дөньяга килгән. Ул гыйлем эстәп, бик күп шәһәрләрдә йөреп, төрле галимнәрдән хәдис өйрәнгән. Аның ошбу китапка башка да тәэлифләре күптер. Имам Әбү Дауд хәзрәтләре 73 яшендә 275 нче елда Бусра шәһәрендә вафат булган.

Алты мөгътәбәр хәдис китапларының берсе – «Сунәнү Нәсәи»дер. Моны тәртип итүче кеше 215 нче елда Хөрәсән вилаятендә дөньяга килгән имам Нәсәидер. Ул бик олуг хәдис галимнәреннән булып, бик күп шәһәрләрдә йөреп гыйлем өйрәнгән вә хәдис откан. Аның күбрәк торуы Мисырда булган. Ул шунда бик күп шәкерт җыеп, хәдистән дәрес иткән. Ахыр гомерендә Димәшкъ шәһәренә барган. Шуннан соң озак тормыйча 303 нче елда вафат булган. Кабере Мәккә шәһәрендәдер.

Иң мөгътәбәр хәдис китапларыннан бишенчесе – «Сүнәнү әт-Тирмизи»дер. Моның мөәллифе олуг хәдис галимнәреннән булган имам Тирмизи хәзрәтләредер. Ул Һиҗрәтнең 209 нчы елында дөньяга килеп, 279 нчы елда вафат булган.

Мөгътәбәр алты хәдис китабының алтынчысы – «Сүнәнү ибн Мәҗә»дер. Моның мөәллифе олуг хәдис галимнәреннән булган Ибнү Мәҗә хәзрәтләредер. Ул 209 нчы елда дөньяга килгән. Ул да бик күп шәһәрләрдә йөреп хәдис гыйлеме өйрәнгән вә хәдис откан. Ул 64 яшькә җитеп, 273 нче елда вафат иткән. Ошбу алты китапны «Сыхаху ситтә» дип йөртәләр.

Безнеңчә әйткәндә «Алты дөрес хәдис китаплары» дигән сүздер. Бу китаплар барысы да басылганнар.

Бу китаплардан башка да байтак хәдис китаплары бар. Бу калган хәдис китаплары эчендә иң мәшһүр вә иң мөгътәбәре Имам Әхмәд бин Хәнбәл хәзрәтләре тарафыннан җыелган «Мүснәдү Әхмәд» исемендәге китаптыр. Ул да хәзерге көндә басылган.

## Төрле гасырларда җитешкән олуг галимнәр

Соңгы буыннарга гыйлем таратып ислам дөньясына иң башлап остазлык кылган сәхабәләрне югарыда язган идек. Алардан соң килгән дүрт имамны да сөйләп узган идек. Ошбу дүрт имам заманында да, алардан соң да бик олуг дин галимнәре килеп киткән. Без бу урында болардан берничәсен сөйләп узачакбыз:

**– Ибнү Җәрир Әт-Тәбәри.** Ибн Җәрир хәзрәтләре өченче гасырның иң олуг галимнәреннән берседер. Ул гыйлемгә гаять дәрәҗәдә һәвәсле булып, гыйлем юлында төрле шәһәрләрдә сәяхәт иткән вә күп галимнәрдән дәрес алган. Үзенең зирәклеге вә тырышлыгы аркасында бик зур галим булып, үз гасырның имамы саналган. Ул төрле җирләрдә йөреп гыйлем алгач, Багдадка килеп урнашкан, вә ахыргы гомеренә кадәр шунда тәфсир вә хәдис галимнәреннән дәрес алган. Ул бигрәк тә тәфсир гыйлеме белән шөһрәт чыгарган. Иң башлап иң олуг тәфсир китабы язучы кеше ошбу ибн Җәрир хәзрәтләредер. Аның тәфсире «Әт-Тәфсирүл-кәбир» дип йөртеләдер. Бу иң зур, мөгътәбәр вә иң борынгы тәфсир китабыдыр. Шунлыктан ибн Җәрир хәзрәтләре бөтен мөфәссирләргә остаз саналадыр. Ибн Җәрир хәзрәтләре Һиҗрәтнең 223 нче елында Табарыстанда дөньяга килеп, 310 нчы елда Багдад шәһәрендә вафат итмештер.

**– Әл-Газали** хәзрәтләре бишенче гасырда җитешкән иң олуг галимдер. Ул олуг дин галиме булу өстенә, заманасының олуг философы вә мөтәфәккире дә иде. Ул байтак вакытлар Багдад шәһәрендәге шул

заманының иң олуг вә иң мәшһүр мәдрәсәләреннән булган «Мәдрәсә низамия»дә дәрес әйткән. Аннан соң дәрес әйтүне ташлап, суфилыкка бирелеп, бик гади бер дәрвиш кыяфәтендә күп шәһәрләрдә сәяхәт итеп йөргән. Шул вакытларда ул гелән дини мәсьәләләр белән шөгыльләнә торган булган вә бик күп китаплар язган. Аның җитмештән артык әсәрләре булып, шулар эчендә иң мәшһүре «Ихъя гөлүмүд-дин» дигән китаптыр. Бу китап вәгазь, нәсыйхәт вә әхлак китабы булып, бик кыйммәтле бер китаптыр. Әл-Газали хәзрәтләре дин гыйлеменә бик олуг хезмәт күрсәткән бер кеше булганлыктан, «хөҗҗәтүл-ислам» дип ләкыйбләнгән. Бу сүз безнеңчә «исламиятнең дәлиле» дигән сүздер. Әл-Газали хәзрәтләре Һиҗрәтнең 505 нче елында вафат булган.

**– Ибн Гарәби.** Ислам дөньясында мәшһүр галимнәрнең берсе Ибн Гарәби хәзрәтләредер. Ул җиденче гасыр башларында җитешкән галимдер. Ул 560 нчы елда Андалус мәмләкәтенең Нурсия шәһәрендә дөньяга килеп, 638 нче елда Сүрия мәмләкәтендә Димәшкъ шәһәрендә 77 яшендә вафат булган. Ул олуг галим булу өстенә, олуг суфи вә шәехләреннәндер. Ул бигрәк тә тәсаувыф хакында язган әсәрләре белән шөһрәт чыгарган. Аның 400 әсәре булып, шулар эчендә мәшһүре «Әл-фүтүхәтү әл-мәккия» исемендәге китаптыр. «Әл-фүтүхәтү әл-мәккия» хәзерге көндә басылган.

**– Әбү Нәср Әл-Курсави.** Бу зат безнең болгар төрекләреннән җитешкән олуг галимнәрдәндер. Ул Һиҗрәттән 1190 нчы елда Казанга якын Курса исемендәге авылда дөньяга килгән. Шунлыктан аны Курсави дип йөртәләр. Курсави хәзрәтләре Бохара шәһәренә барып, шунда гыйлем вә кимәләт хасил иткән. Аннан соң Русиягә кайтып, зур мәдрәсә тәэсис иткән вә күп шәкертләр җыеп, дәрес әйткән. Курсави хәзрәтләре төгәл Русия мөселманнары эчендә, хәтта бөтен ислам дөньясында шул заманның олуг галимнәреннәндер. Болгар төрекләре исә Ислам динен кабул иткән көненнән алып аның заманына кадәр аның кебек олуг галимне күрмәгәннәр. Олуг адәмнәргә хөсет итүчеләр һәрвакыт күп буладыр.

Курсави хәзрәтләре үз заманасындагы галимнәрнең барсыннан да өстен чыгып, тиңдәшсез кеше булгач, аңа да хөсет итүчеләр күбәйгән. Бохарада чагында ук, аның өстеннән әмирләргә шикаять итеп, Бохараны ташлап китәргә мәҗбүр иткәннәр. Русиягә кайткач, өстеннән шикаять итүләре вә башка төрле аны күздән төшерергә тырышулар булган. Ләкин моңа карамыйча, аның кимәләте вә шөһрәте арта гына барган. Курсави хәзрәтләре Һиҗрәттән 1227 нче елда хаҗга сәфәр иткән вә юлда Истанбул шәһәрендә вафат иткән. Кабере шундадыр. Бу вакыт аңа бары 37 яшь кенә булган. Шулай була торып аның калдырган әсәрләре байтак кына бар.

**– Шиһабетдин Әл-Мәрҗани.** Мәрҗани хәзрәтләре бу көнгә кадәр Русия мөселманнары эчендә җитешкән галимнәрнең иң олугысыдыр. Ул үз заманында ислам дөньясының да иң олуг вә иң атаклы галимнәреннән булган. Аның бабалары торган Мәрҗан исемендәге авыл исеме белән Мәрҗани дип йөртәләр. Мәрҗани хәзрәтләре Казанга 50 чакрымнар чамасында Ябынчы исемендәге авылда 1233 нче (1818 м) елда дөньяга килгән. Башта үзенең әткәсенең мәдрәсәсендә укыган. Бик үткен зиһенлелеге вә бик тырышлыгы аркасында бөтен шәкертләреннән өстен булып, шул чагында ук киләчәктә зур бер галим булачагы беленеп торган.

17 яшендә чакта дәрес укытырга да башлаган. 21 яшендә уку нияте белән Бохарага сәфәр иткән. Анда биш ел торып, шундагы олуг галимнәрдән дәрес алган. Бохарадагы шәкертләрнең иң алдынгы вә иң атаклыларыннан булып киткән. Аннан соң Сәмәрканд шәһәренә сәфәр иткән. Анда Әбү Сәгыйд исемендәге казый вә олуг галим кеше бар икән. Остазы ошбу казый Әбү Сәгыйд хәзрәтләре булмыштыр. Сәмәркандта ике ел торгач, Мәрҗани хәзрәтләре яңадан Бохарага барып биш ел торган. Шул вакыт ул Бохараның иң зур галимнәреннән саналган. Аннан Русиягә кайтып, Казан шәһәрендә имам булган. Күп шәкертләр җыеп дәрес әйткән. Тиз арада шөһрәте бөтен тирә-якка таралып, һәр җирдән үзеннән дәрес алырга шәкертләр килә башлаганнар. Ләкин Курсави хәзрәтләренә бул-

ган кебек, моның өстеннән дә шикаятьләр булган. Төрле юллар белән күздән төшерергә тырышканнар. Указы алынып, дәрестән туктатып торган чаклары да булган. Ләкин ахырда гәепсез табылып, тагы дәрес әйтүгә керешкән. Ул үлгәнгә кадәр дәрес әйтү вә китап язу белән шөгыльләнгән. Бөтен рәхәте, бөтен ләззәте китап карау, китап язу вә дәрес укыту булган. Аның бик күп мөһим әсәрләре бардыр. Ул тәэсис иткән вә ул дәрес әйткән мәдрәсә хәзерге көндә дә бар. Аны «мәдрәсә Мәрҗания» дип йөртәләр.

Мәрҗани хәзрәтләре Һиҗрәттән 1297 нче елда хаҗ өчен сәфәр итеп, Истанбул, Мисыр вә Хиҗаз җирләрендә бик олуг галимнәр белән мәҗлестәш булган. Шул вакыт аңа һәр җирдә хөрмәт күрсәткәннәр. Һәр җирдә олуглаганнар. 1298 нче елда хаҗдан кайтып, тагы да дәрес әйтергә тотынган. Һиҗрәттән 1306 нчы елда (1889 м) 74 яшендә Казан шәһәрендә вафат иткән. Кабере Казан каберлегендәдер.

## Бөтен җир йөзендә мөселманнар

Хәзерге көндә җир йөзендәге инсаннарның саны бер миллиард ярымнан ашадыр. Болар бик төрле динлеләр. Болар эчендә мөселманнар, христианнар вә яһүдиләр исемендә, тарихлары вә китергән китаплары билгеле олуг өч пәйгамбәрнең шәригатендә булганнары да бар. Ошбу өч диндә булган халыклардан иң аз яһүдиләр, иң күбе христианнардыр. Мөселманнар исә 250-300 миллион чамасы хисап итәләр.

Ислам дине вә ислам шәригате белән гамәл кыла торган халыклар арасында бик төрле кавемнәр, төрле милләтләр бар. Ләкин болар эчендә саннары иң күп булганнары төрек вә гарәп кавемнәредер. Хәзерге көндә җир йөзендәге төрек вә гарәп кавемнәреннән һәркайсы иллешәр миллион чамасында булып, бик азын алып ташлаганда, барсы да диярлек мөселманнардыр.

Төрек кавемнәре күбрәк Аурупа шәрык вә җәнүб тарафларында, Азиянең гарәби җәһәтләрендә мәгыйшәт итәләр. Гарәп халыклары исә

Азиянең җәнүб вә җәнүб-гарәби тарафларында, Африканың шимәл тарафларында мәгыйшәт итәләр.

Мөселманы иң күп булган кыйтга – Азия кыйтгасыдыр. Исламиятнең бишеге ошбу Азия кыйтгасындагы Гарәбстан мәмләкәте булып, иң башлап таралган урыннары да ошбу кыйтгадагы Иран, Әл-Җәзәир вә Сүрия мәмләкәтләредер. Азия кыйтгасыннан кала мөселманга иң бай кыйтга Африка кыйтгасыдыр. Бу кыйтганың шимәл-шәркы вә шимәл җәһәтләрендә мәгыйшәт итүчеләр бөтенләй диярлек мөселманнар. Аурупа кыйтгасында Ислам динендә булган халыкларның саны бик аз булып, бары егерме миллион чамасы хисап итәләр. Аурупаның бөтен халкына караганда, бу сан егермедән бер өлеш кенә туры киләдер. Аурупадагы мөселманнарның бик азын алганда, бөтенесе диярлек төрек кавемнәредер. Америка вә Австралия кыйтгаларында исә мөселманнар бөтенләй юкка хисап булып, сәүдә вә шуның кебек эшләр белән вакытлый барган берәм-сәрәм кешеләрдән генә гыйбарәттер.

## Русия мөселманнарында Ислам дине

Русия мәмләкәтендә барлыгы егерме миллионнан артык мөселман бар. Югарыда әйтелгәнчә, боларның бөтенесе диярлек төрек кавемнәреннәндер. Русиядә мөселманнар төрле җирләргә таралган булып, иң күп вә аның тыгыз җире Төркистан, Кавказ вә Кырым өлкәләредер. Шулай ук Семипалат, Тургай, Урал вә Әстерхан кебек дәүләтләре дә мөселманга иң бай вилаятьләрдер. Эчке Русиядә исә мөселманы иң күп губернияләр Уфа, Казан вә Ырынбур губернияләредер. Хәзерге көндә Уфа губерниясендә бер миллион ярым чамасында, Казан губерниясендә бер миллион чамасында, Ырынбур губерниясендә ярты миллион чамасында мөселман бар. Моннан кала Самара, Вятка, Пермь, Сембер, Сарытау, Пенза, Түбән Новгород, Тамбов, Рәзән вә Грозный губернияләрендә байтак мөселманнар бар.

Русия мәмләкәтенә Ислам диненең керүе төрле җирдә төрле вакытларда булган. Төркистан өлкәсенә Ислам дине беренче гасырда ук керә башлаган. Безнең Идел буе төрекләренә дә Һиҗрәтнең беренче гасыр ахырларында ук керә башлаган. Ләкин ул җирләргә Ислам диненең рәсми рәвештә кереп, таралып вә җәелеп китүе Һиҗрәттән дүртенче гасыр башында гына булмыштыр.

Ул вакытларда Идел буе төрекләре «болгар төрекләре» дип аталганнар. Алар аерым үзләренә бер зур халык булганнар. Диннәре мәҗүси дине булган. Һиҗрәттән беренче гасырда ук күп мәмләкәтләр фәтех итеп, чит халыклар белән аралашырга өйрәнгән гарәпләр безнең бабаларыбыз булган болгар төрекләренә дә килеп чыкканнар. Алар бу җирләргә берәмсәрәмләп сәүдә өчен килә торган булганнар. Менә шул гарәпләрнең холкы вә табигатьләре дә, диннәре дә безнең бабаларыбызга бик ошаган. Берәмсәрәм булса да, Ислам динен кабул итүчеләр булган. Һиҗрәттән дүртенче гасырның башларында Ислам дине безнең бабаларыбызга бик билгеле һәм дә аларның күңелләренә хак дин дип урынлашкан. Булырга кирәк, ул вакыт Болгар падишаһысы булган Алмас Силки углы. Габбасия халифәләреннән булган Әл-Мүктәдир Билләһигә, Бәгъдәд шәһәренә илчеләр җибәреп, үзе вә кул астындагы халыкларның Ислам динен кабул итәчәкләрен белдергән. Һәм дә үзләренә Ислам дине өйрәтергә, мәсҗид вә мәдрәсә салдырырга галимнәр вә һөнәр ияләре җибәрүен үтенгән. Хәлифә моның үтенечен бик шатланып кабул иткән. Шулай итеп ул Сәхсән Әр-Расиби вә Бәдр Әл-Хәрами исемендәге ике галим кул астында Болгар шәһәренә бер илче һәйәте җибәргән. Болгар падишаһысына үз тарафыннан төрле һәдияләр дә күндергән. Илче Һиҗрәттән 309 нчы елда (921 м) Багдадтан чыгып, Бохара вә Харәзем шәһәрләре аркылы керүдән Болгарга сәфәр иткәннәр. Ул вакытларда тимер юллар булмаганлыктан, сәфәр йөрү бик мәшәкатьле һәм дә бик озак вә вакытлар тели торган булган. Шунлыктан ошбу илче һәйәте юлда елга якын вакыт үткәргәннәр. Болгар шәһәренә җитүгә бер тәүлек

юл калганда, Болгар падишаһысының уллары вә кардәшләре һәм дә кул астында дүрт кечкенә ханнар боларны икмәк-тоз белән каршы алганнар.

Шәһәргә унбиш чакрым чамасы юл калганда, Алмас хәзрәтләре гаскәре белән үзе дә боларга каршы килеп җиткән. Илчеләрне күргәч, падишаһ аттан төшеп, үзләренең борынгы гадәтләренчә сәҗдә кылып, аларга хөрмәт күрсәткән. Боларның алдына алтын вә көмеш акчалар чәчтергән. Шулай итеп илчеләр белән Болгар шәһәренә кереп, боларны махсус кунак өенә төшерткән. Һиҗрәттән 310 нчы ел мөхәррәм аеның 16 сында пәнҗешәмбе көн хан хәзрәтләре үзенең сараенда илчеләр хөрмәтенә зур мәҗлес ясаткан. Бу мәҗлескә кечек ханнар, вәзирләр вә олуг түрәләр, шәһәрнең мөгътәбәрләре барсы да хәзер булганнар. Шул вакыт илчеләр хәлифәнең җибәргән бүләкләрен Алмас хан хәзрәтләренә тәкъдим иткәннәр. Бүләкләр эчендә иярләнгән яхшы бер ат булган. Хан хәзрәтләренең үзенә һәм бикәсенә кием, хан хәзрәтләренә чалма да булган. Илчеләр хан хәзрәтләренә киемнәрне үз куллары белән кидергәннәр һәм чалманы үз куллары белән чалганнар. Аннан соң илчеләр хәлифә вәзирләренең мәктүбләрен чыгарып укыганнар. Хан хәзрәтләре зур гәүдәле кеше булса да, мәктүбләр укылганда аягүрә басып торган. Аннан соң Алмас ханның вәзирләре вә кечкенә ханнары илчеләр өстенә алтыннар чәчкәннәр. Падишаһбикә дә илчеләр хозурында ошбу мәҗлестә хәзер булган. Менә моннан бабаларыбыз булган болгар төрекләренең башлап рәсми сурәттә Ислам динен кабул итүләре ошбу вакыт булмыштыр. Шул көн Болгар падишаһысы үзенең исемен Габдуллаһка алмаштырып, моннан соң Җәгъфәр бин Габдуллаһ дип аталып киткән. Ошбу көн болгар төрекләре өчен зур бәйрәм вә шатлык көне булган.

## Идарә шәргыя

«Идарә шәргыя» дип дин вә шәригать эшләре карала торган мәхкәмәгә әйтәләр. Төп Русиядә мөселманнар өчен дүрт идарә

шәр-гыя бар. Боларның икесе Кавказ, берсе Кырым, берсе Ырынбур идарә шәргыяседер. Болардан Ырынбур мәхкәмә шәргыясе иң зурысы вә мәхәлләсе иң күп булганыдыр. Эчке Русиядәге бөтен мөселман мәхәлләләре вә Сибириядәге бәгъзе мәхәлләләр ошбу Ырынбур мәхкәмә шәргыясе карамагындадыр. Ошбу мәхкәмә шәргыя «Ырынбур идарә шәргыясе» дип аталса да, үзе Уфа шәһәрендәдер. Ырынбур идарә шәргыясенең башлап тәэсис ителүе милади белән 1788 нче елда, императрица Екатерина Икенче заманында булган. Бу вакытка кадәр эчке Русия мөселманнарының дини эшләрен йөртә торган, аларга гает, җомга вә җәмәгать намазларында имамлык итә торган кешеләр булса да, боларны карый торган рәсми ислам мәхкәмәсе булмаган. Менә императрица Екатерина Икенче хәзрәтләре, кул астындагы мөселманнарга мәрхәмәт кылып, аларның дини эшләрен карый торган бер идарә шәргыя тәэсис иттергән.

Ырынбур идарә шәргыясе дүрт әгъзадан гыйбарәт булыр, боларның берсе мөфти, калган өчесе казый дип аталалар. Мөфти мәхкәмәнең рәисе саналадыр. Ошбу мәхкәмә Русия мөселманнарының дин вә шәригать эшләре карала торган бер мәхкәмә булганлыктан, мөфти хәзрәтләре Русия мөселманнарының дин башлыклары буладыр. Хәзерге көндә Ырынбур идарә шәргыясе кул астында алты мең ярым чамасы мәхәллә бар. Һәр мәхәлләнең бер мәсҗиде булып, шул мәсҗидтә имам тора торган вә шул мәхәлләнең дини эшләрен башкара торган бер яисә ике имамы бар. Имамнар, имам-хатыйп вә ахун дия өч дәрәҗәгә бүленәләр. Болар барысы да мәхәллә халкының дини эшләрен карый торган вә аларга намазларда имам тора торган кешеләр булсалар да, дәрәҗәләре дә бер береннән артыктыр. Ахунлык имамлыкның иң зур дәрәҗәсе булып, хатыйп икенче дәрәҗәдә, имам өченче дәрәҗәдәдер. Болардан башка һәр мәхәллә саен бер мөәзин дә була. Аның төп вазыйфасы җомга вә җәмәгать намазларында азан әйтү вә камәт төшерүдер. Мәхәллә имамнары юк вакытларда, мөәзиннәр дә аларның эшләрен башкара алалар.

*Сөнгатулла Бикбулат*

# Фән

# Хәнәфи мәзһәбе

Фикһ һәм игътикад мәзһәбләренең күбесе аларга нигез салучы галимнәрнең исемнәрен йөртә һәм шул исем белән таралган да. Һиҗри буенча беренче ике гасырда мәркәзе Куфа булга Гыйрак өлкәсендә Гыйрак фикһы барлыкка килә. Киләсе гасырларда ул үсеш һәм киң таралыш ала. Соңрак ул Имам Әгъзәм Әбү Хәнифә исеме буенча «хәнәфи мәзһәбе» дип атала башлый. Әбү Хәнифә – фикһ ысуллары, бүлекләре һәм аны системалаштыруга иң зур өлеш керкән кеше. Шушы мәзһәбкә караган факыйһларны һәм аны тоткан кешеләрне «хәнәфиләр» дип атыйлар.

**Нигез салучы:** Ногман ибн Сабит имам Әбү Хәнифә. Аның бабалары Куфага Хорасаннан күченеп килгән. Күпчелек галимнәр аны һиҗри исәп буенча 80 нче елда туган дип исәпли.

Ул яхшы белем ала, күп кенә күренекле галимнәрдә укый. 16 яшендә хаҗга китә. Анда галимнәр мөхитендә фәнгә гашыйк була, һәм Куфага кайткач, гыйльми мөнакашәләрдә (бәхәсләрдә) актив катнаша башлый. Башта аны кәләм мәсьәләләренә караган бәхәсләр кызыксындырса, соңрак ул тулысы белән фикһ өйрәнүгә бирелә. 18 ел дәвамында, кырык яшенә кадәр, ул остазы Хәммәд ибн Әби Сөләйманнан дәрес алуын дәвам итә. Әбү Хәнифәнең фикһтагы карашлары остазы аша, соңрак Ибраһим Нәхәги, Галкамә һәм Әсвәд аша Габдуллаһ ибн Мәсгудкә тоташа.

Моңа нисбәтле Әбү Хәнифә: «Көннәрдән бер көнне мин мөэминнәр әмире Әбү Җәгъфәргә килдем. Ул: «Ий Әбү Хәнифә, син кемнән галимлелек дәрәҗәсенә ирештең?» – дип сорады. Мин: «Хәммәд аша мин Ибраһимнан гыйлем алдым, ә ул исә – Гомәр ибн Хаттабтан, Гали ибн Әбү Талибтан һәм Габдуллаһ ибн Мәсгудтән ﷺ». Мондый җавап ишеткәч, Әбү Җәгъфәр: «Яхшы, җитте», – дип әйтте», – дигән.

Аңа хәдисләр тапшыручылар һәм ул укыган кешеләр арасында Зәйд ибн Гали Зәйн Әл-Габидин һәм Җәгъфәр Садык кебек имамнар да була.

Хәммәд вафатыннан соң Әбү Хәнифә үз укыту үзәген оештыра һәм утыз ел дәвамында мөгаллимлек итеп, бик күп мәшһүр укучылар тәрбияли. Дәресләрендә ул мөгаллимнең шәкертләргә бар сорауларга да әзер җавап бирүен күз уңында тоткан иске укыту ысулыннан китеп, мөмкин булган бар вариантлар буенча фикер алышып, мәсьәләнең чишелешен бергәләп эзләү ысулын өстен күрә. Бу үзенчәлекле ысулның нәтиҗәсе булып, Әбү Хәнифә мәзһәбе барлыкка килә. Аның үзенчәлекләре:

1. Бу бар җәмәгать мәзһәбе, чөнки аның карарлары – ул зур төркем галимнәрнең күмәк тырышлыгы нәтиҗәсе.

2. Әбү Хәнифә кардәшләрен дини дәлилләргә нигезләнеп нәтиҗәләр ясарга, соңрак, шулардан чыгып, шәригать кануннарын чыгарырга өйрәтә. Шуның белән беррәттән, мөмкин булган бар очрак һәм теләсә нинди ихтималлык истә тотылырга, ә кабул ителгән карар иң туры килгән булырга тиеш.

3. Дәресләр вакытында аның укучылары пассив тыңлаучы булмый, ә киресенчә, уртак карарны кабул итүдә актив катнашып, мәзһәбне тудыручы булалар.

4. Мәсьәләләр озак бәхәсләр дәвамында хәл ителгән. Моңа бәйле рәвештә Ибн Әби Әл-Гаввәм: «Әбү Хәнифәнең үзе белән бергәләп фикһ китапларын төзүче мәшһүр кырык укучысы була», – дип әйткән.

5. Вакыт узу белән барлыкка килгән яңа күренешләрне хәл итәр өчен берсе артыннан берсе килгән галимнәр һәрдаим тырышлык куйган.

Имам Әбү Хәнифә һиҗри буенча 150 нче елда вафат була. Моның белән күпчелек галимнәр килешә. Аның кайсы айда вафат булуы буенча гына төрле фикерләр бар. Ул шәүвәл, яки раҗәб, яки шәгъбан аенда вафат булган, дигән фикерләр бар. Аны Багдад шәһәрендә зинданда утырган вакытында агулыйлар[1].

[1] Әбү Габдуллаһ Мөхәммәд ибн Әхмәд ибн Госман Әз-Зәһәби «Мәнәкыйб әл-имам Әбү Хәнифә»

Әбү Хәнифә турында үзенең тәкъвалыгы белән билгеле булган чордашы Фүдаил ибн Гийәз болай дигән: «Әбү Хәнифә факыйһ һәм тәкъва кеше иде. Көн-төн ул фән өйрәнү белән шөгыльләнде. Ул бер үк вакытта мәшһүр факыйһ һәм зур байлык иясе иде. Әбү Хәнифә янәшәдәгеләренә һәрвакыт ярдәм кулы сузарга әзер булуы белән танылды. Аңа ярдәм сорап мөрәҗәгать итүчеләр белән ул гыйлеме вә малы белән бүлешә иде. Бар төннәрен ул гыйбадәттә үткәрә иде. Азсүзле, күп вакытын сөйләшми үткәрә иде. Хакыйкатьне иң яхшы рәвешле яклый белә иде. Хакимлек байлыгыннан һәрвакыт ерак торып, беркайчан да әмирләрдән бүләкләр алмый иде».

Ә Җәгъфәр ибн Рабигъ аның турында: «Мин биш ел Әбү Хәнифә янында булдым. Беркайчан да шулай еш һәм озак сөйләшми торган кешене очратырга туры килмәде. Әмма фикһ буенча сорау бирсәләр, ул шундук ачылып китә иде, аның сөйләме тиз елга кебек ага, ә тавышы бар тирә-якка ишетелә иде», – дип әйткән.

Бервакыт имам Мәликтән Госман Әл-Бәтти турында сорыйлар. Ул: «Урта дәрәҗәле кеше», – дип җавап бирә. Шундый ук җавапны Ибн Шубрум турында сорагач алалар. Әбү Хәнифә турында да сорыйлар. Имам Мәлик: «Әгәр ул сезгә бу агач баганаларның алтыннан эшләнгәнен кыяс юлы белән дәлилләргә тотынса, һичшиксез сезне ышандырачак. Ул мондый сәләтләргә ия булган шәхес», – дип әйткән. Имам Шәфигый да Әбү Хәнифә турында мондый сүзләр әйтеп калдырган: «Фикһта кешеләр шундый дәрәҗәдә, әйтерсең алар Әбү Хәнифәнең балалары»[1].

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөселманнарының*

*Диния нәзарәте рәисе, мөфти*

[1] Ибн Габидин

# «Хизбүт-тәхрир әл-исләми» партиясе

**2003 елның 14 февралендә Россия Югары Суды карары белән «Хизбүт-тәхрир», экстремистик оешма дип игълан ителеп, эшчәнлеге тыелды.**

«Хизбүт-тәхрир әл-исләми» («Ислам азатлык партиясе») партиясенә нигез салучы Тәкыеддин ән-Нәбһәни (1908–1977) Фәләстыйнда туган, Каһирәнең «әл-Әзһәр» университетын, соңыннан «Дәрул-Гулүм» институтын тәмамлаган. Укып бетергәч, Фәләстыйнга кайтып укытучы, ә соңыннан Әл-Кодс (Иерусалим) шәһәренең аппеляцион шәригать суды әгъзасы булып эшләгән. Иорданиянең «Әл-ихвән әл-мүслимин» дини-сәяси партиясенең эшлекле әгъзасы булган, тик соңыннан идеологик фикер каршылыклары аркасында алардан аерылып чыккан һәм 1952 елда «Хизбүт-тәхрир әл-исләми» («Ислам азатлык партиясе») партиясенә нигез салган. Бәйрут шәһәрендә вафат һәм шунда күмелгән.

## Фикерләре

1. «Хизбүт-тәхрир»нең максаты – Ислам хәлифәлеген (дәүләтен) гарәпләр җирлегендә торгызып, аннары аңа башка мөселман җирләрен дә кушып, ислам динен башка илләргә тарату. Хәлифәлек мәсьәләсенә бик зур игътибар бирүләре белән башка ислам хәрәкәтләреннән аерылып торалар. Партиянең бөтен эшчәнлеге – сәясәт белән шөгыльләнү. Үзләренең белем бирү яки дәгъвәт оешмасы түгеллекләрен һәрчак ассызыклап киләләр.

2. Хәлифәгә бәйгать бирмәгән бөтен мөселманнар җаһилият үлеме белән вафат була (ягъни зур гөнаһлы хәлдә китә) диләр. Аларның фикеренчә, соңгы 100 елдан артык вакыт эчендә вафат булган барча мөселманнар да, хәлифәт булмау сәбәпле, бу дөньядан җаһилият үлеме

белән китте. Шундый үлемгә дучар булмас өчен, мөселманнар хәлифәлекне (Ислам дәүләтен) булдыру өстендә эшләргә тиеш дип саныйлар.

Бу фикерләрен дәлилләр өчен, алар Имам Мөслим хәдисләр җыентыгында килгән Пәйгамбәребезнең ﷺ Ибн Гомәрдән ﵁ риваять ителгән хәдисен китерәләр: «(Хәлифәгә) итагать итмәгән кешенең Кыямәт көнендә яклаучысы булмас (аклана алмас), һәм әгәр (хәлифәгә) бәйгать бирмичә үлсә, зур гөнаһлы хәлдә үлгән булыр». Тик алар бу хәдисне китергәндә, күп очракта аның икенче өлешен генә әйтәләр: «Әгәр (хәлифәгә) бәйгать бирмичә үлсә, зур гөнаһлы хәлдә үлгән булыр». Шуның белән алар кешеләрне үз фикерләренә инандырырга телиләр.

Бу хәдиснең хакыйкый мәгънәсе түбәндәгечә: «Хәлифәгә итагать итмәүче һәм шул хакта тәүбә кылмаган кеше гөнаһлы (фасикъ) хәлендә үлгән була», ягъни Пәйгамбәребез ﷺ әлеге хәдисне хәлифәгә итагать итмәүче, аңа каршы чыгучы һәм шул хакта тәүбә кылмыйча вафат булган кешегә карата әйткән.

Пәйгамбәребезнең ﷺ бу мәгънәне исбатлый торган башка хәдисе дә бар. Ул Хөзәйфә ибн әл-Йәмәннән риваять ителә. Пәйгамбәребез ﷺ адашкан кешеләрне сурәтләгәч, мондый киңәш бирә: «Мөселманнар җәмәгатенә (монда Пәйгамбәр юлыннан баручы мөселманнарның күпчелеге күздә тотыла) һәм аларның Имамына (җитәкчесенә) тотыныгыз (алардан аерылмагыз)». Хөзәйфә ибн әл-Йәмән сорады: «Ә әгәр мөселманнарның хакыйкый җәмәгате һәм җитәкчесе булмаса?» Пәйгамбәр ﷺ әйтте: «Фиркаларның барысыннан да ерак булыгыз» . Пәйгамбәр ﷺ бу хәдисендә: «мөселманнарның җитәкчесе булмаса, һәм алар аны сайламасалар, җаһилият үлеме белән вафат булырлар», – димәде.

3. Мөселманнарның абсолют бөтен проблемаларына да Ислам хәлифәлегенең булмавын сәбәп итүләре.

Бу Пәйгамбәребезнең: «Миннән соң хәлифәт утыз елга сузылачак, ә аннан соң патшалык булачак» , – дигән сүзләренә каршы килә. Бу – алдан

күрүче хәдис, һәм шулай килеп чыккан да. Гадел хәлифәләр чорыннан соң да күп мөселман дәүләтләре – «хәлифәт», күп җитәкчеләр «хәлифә» исемен йөртсәләр дә, чын, асыл мәгънәдәге хәлифәт белән аларның бернинди дә уртаклыгы булмаган. Мәсәлән, шигый хәлифәләрен, кайберләре үзләрен Аллаһның гәүдәләнеше, тере илаһлар дип игълан иткән фатыймиларны искә төшерик. Ә урта гасыр хәлифәләре еш кына идарә, тәхет, таҗ өчен көрәштә һичнинди канлы корбаннар алдында да туктап калмаганнар. Шуңа күрә хәлифәт 1924 елда түгел, ә Пәйгамбәребез ﷺ кисәткәнчә, күпкә иртәрәк юкка чыккан .

4. «Хизбүт-тәхрир» партиясе куйган максатларга ирешү өчен, өч этап үтәргә кирәк, дип саный:

а) аерым шәхесләр белән гакыйдәне төзәтү өстендә эшләү, аңбелем тарату методлары белән дәгъвәт кылу (аралашулар, очрашулар, массакүләм чаралар, газета-журналлар чыгару, китаплар тарату, үз китапларын өйрәтү максатында түгәрәкләр оештыру һ. б.);

б) аерым шәхесләрне үзгәртү нәтиҗәсендә җәмгыятьнең фикере үзгәрүе;

в) аерым җитәкчеләр һәм сәясәтчеләр ярдәмендә хакимияткә ирешү.

5. Ислам хәлифәлеген торгызганчы, яхшылыкка чакыру һәм начарлыктан тыю дөрес түгел, бу эш Ислам дәүләте тарафыннан башкарылырга тиеш, дип саныйлар.

6. Бүгенге көндә хәрби җиһадны һәм гомумән көч куллануны тыялар, чөнки җиһад Ислам дәүләте тарафыннан гына алып барылырга тиеш, диләр.

Шуңа карамастан, «Хизбүт-тәхрир» хәрби переворот белән хакимиятне алу максатында, мөселман илләренең хәрби оешмаларына үтеп керергә омтыла. Бу методны алар «таләбү ән-нүсра» (ярдәм эзләү) дип атыйлар. Мәсәлән, 2009 елның июль аенда Төркиядә, «Эргенекон» исемле неофашистик төркем белән бәйле дәүләт переворотын әзерләүче «Хизбүт-

тәхрир» әгъзалары кулга алынган иде. Шулай ук, террористик төркемнәр ягында хәрби хәрәкәтләрдә (мәсәлән Сүриядә) катнашу өчен, «Хизбүт-тәхрир» мөселманнарны туплый, дигән хәбәрләр дә бар.

7. Аларга хакимиятне һәм мөселман руханиларын тәнкыйтьләү, хакимият әһелләренең һәм структураларының дәрәҗәсен төшерү, мөселманнарны хакимияткә каршы, ә дәүләтне мөселманнарга каршы кую хас. Мондый провокацияләрне алар күп оештыра.

8. Гыйбадәттә сөнни мәзһәбләрнең берәрсенә ияреләр яки иҗтиһад кылырга рөхсәт итәләр. Шул сәбәпле, алар арасында мәзһәбләрне инкяр итүчеләр дә очрый.

9. Кабер газабын һәм Дәҗҗалның чыгуын танымыйлар, бу хакта әхәд хәбәрдә килсә дә. Бу игътикади мәсьәләдә алар «Әһлүс-сүннә вәл-җәмәга» (сөнниләр) белән каршылыкка керә.

10. Тәмәке тартуны, музыка тыңлауны, порнографик сурәт һәм видеолар карауны тыймыйлар.

«Хизбүт-тәхрир» партиясенең структурасы катгый вертикаль буйсындырудан гыйбарәт. Үз фикерләрен тарату һәм тарафдарларын күбәйтү максатында, махсус түгәрәкләр (хәлка яисә хәләкат) оештырып, аерым тәртип буенча, партиянең китапларын, партиянең структурасын, аның максатларын һәм эшләү методларын өйрәнәләр. Түгәрәкләр партиянең беренчел ячейкалары булып санала, һәм алар гадәттә биш кешедән тора. Бу түгәрәкләрдә кимендә атнага бер тапкыр дәресләр алып барыла. Түгәрәкләргә йөрүче – «дәрис» (укучы), түгәрәкне алып баручы «мүшриф» дип атала. Мүшриф бер яки берничә түгәрәк белән җитәкчелек итә, дәрес бирә, китаплар тарата, казначей вазифасын үти. Мүшрифләр «нәкыйб» дигәнгә буйсыналар. Нәкыйб партиянең район күләмендәге эшчәнлеген алып бара, шулай ук укыта, листовкалар таратуны оештыра һ. б. Аена бер тапкыр мүшрифләр, эшчәнлекләре буенча хисап бирү һәм нәкыйбтан күрсәтмәләр алу өчен, киңәшмәгә җыелалар. Буйсыну

тәртибендә алга таба «мүсәгыйд» (өлкә җитәкчесенең ярдәмчесе), аннары «мәсьүл» (өлкә җитәкчесе) һәм «мүгтәмәд» – партиянең өлкә (дәүләт, республика) күләмендәге җитәкчесе тора. Барча мүгтәмәдләр партиянең хәзерге җитәкчесе Гата Хәлил Әбү Раштага буйсыналар.

«Хизбүт-тәхрир» үзе уздырган чараларда һәм митингларда, символ буларак, шәһадәт язылган кара яисә ак төстәге байракны куллана. Галимнәр арасында төрле каршылыклы фикерләр булуга карамастан, алар бу байракны Пәйгамбәребез ﷺ дәвереннән бирле ислам һәм мөселман хәлифәлегенең байрагы дип белдерәләр.

Түгәрәкләрдә өйрәнелүче төп китаплары: «Ислам низамы», «Хизбүт-тәхрир төшенчәләре», «Ислам шәхеслеге», «Ислам нәфесенең нигезләре», «Хәлифәт ничек җимерелде». Шулай ук, «Әл-вәгый» (Аң), «Хәлифәт» журналларын, төрле листовкалар тараталар.

## Таралуы

Бүгенге көндә Аурупа илләрендә, бигрәк тә Бөекбритания, Дания, Украинада бик киң таралган. Алманиядә дә, 2003 елдан тыелган булуына карамастан, тарафдарлары күп. Үзбәкстанда, гарәп илләре арасында (гарәп илләрендә дә бу партия рәсми рәвештә тыелган) Иордания һәм Ливанда иң күп таралган.

*Камил хәзрәт Вәлиуллинның*

*«Исламдагы фирка һәм төркемнәр» китабыннан*

*2017 елның 10 февралендә бөек шагыйрь Александр Сергеевич Пушкинның вафатына 180 ел булды. Харис хәзрәт Салихҗанның шушы вакыйгага багышланган мәкаләсе һәм «Әдәби сәхифә»дә шагыйрьнең хәзрәт тәрҗемә иткән шигырьләре тәкъдим ителә.*

## Бөек илһам иясе

Дәвер, заман, гасырлар аша буыннардан-буыннарга мирас булып килгән Аллаһы Хак сөбхәнәнү вә Тәгаләнең олуг нигъмәте Коръәни-Кәрим XVIII гасырның башында ук инде Аурупа дәүләт-мәмләкәтләре халыкларының милли теленә – француз, инглиз, немец, урыс телләренә дә тәрҗемә ителде.

Халыкларга әле моңа кадәр ниндидер сер-мистика, шөбһә итеп саналган Коръән нигъмәтен өйрәнергә мөмкинлек туды. Тарих сикәлтәләрендә, чагыштырмача аз гына вакыт киңлегендә элек мәҗүсилектә тереклек кылган, хаклыктан авышкан, гамәлдә саташкан кавемнәр, Испания җирләреннән Индонезия мәмләкәтләренә кадәр яшәгән адәмнәр ничек Коръәнгә җәлеп ителделәр дә мөселман булдылар? Менә шушы сөальгә җавап эзләгән Аурупа әдипләре Коръән феноменын тәрҗемәдә аңлады.

Коръәннең үзенә генә хас шигъри прозасында иксез-чиксез нур белән сугарылган аять-кәлимәләрендә нинди олуг илһам барлыгын фәһемләгән Гете, Һейне, Байроннар артыннан Александр Пушкин 1824 елда М. Веревкин тәрҗемәсендә Коръәнне укып кына түгел, тулысы белән өйрәнеп чыга. Шагыйрь кальбендә Коръәнгә мәхәббәт белән сугарылган илһам уяна һәм, ниһаять, аның «Коръәнгә ияреп» («Подражание Корану») дип исемләнгән шигъри җыентыгы пәйда була. Менә шуның өчен газиз Тукай XX гасыр башында ук инде «хәзрәти Пушкин» дип аңа олуг ихтирамын кылган. Шуның өчен дә бүген Пушкин иҗаты белән таныш булган, гафиллектән арынган әһеле Ислам ихлас күңел илән изге ният-догаларын

әдипкә юллый. Чөнки әдәбият-сәнгать дөньясында иң беренчеләрдән булып, галәмнәр хуҗасы Аллаһы Хак Сөбханәһү вә Тәгаләнең олуг нигъмәте – Коръәни-Кәримнең 33 сүрәсенең аяти кәлимәләрен кулланып, шигъри ысул белән тәфсир кылу бәхет-сәгадәтенә ирешкән бөек илһам иясе Пушкин булды. Бу фикергә дәлилләребезнең дәрәҗәсе кыя тауларга тиңләрлек. Шуларның бәгъзеләрен, исебезгә төшкәннәрен генә булса да, күңелдән кичерик. Аллаһы Раббүл-гыйззә «Бәкара» сүрәсенең мөбарәк 256 нчы аятендә:

**لَا إِكْرَاهَ فِي الدِّينِ ﴿٢٥٦﴾**

**«Ислам динендә көчләү, мәҗбүрләү юк...»**, – диде. Раббымызның ошбу кәлимәсен шигъри юлга салып, А. Пушкин:

«С небесной книги список дан  
Тебе, пророк, не для строптивых;  
Спокойно возвещай Коран,  
Не понуждая нечестивых!» _

дип, һәр бәндәгә аңлаешлы итеп тәфсир кылды. Ошбу мәгънәви тәфсирне урысчадан ана телебезгә тәрҗемә итсәк:

«Пәйгамбәр, галәмнән вәхи иңде сиңа,  
Түгел киребеткән адашканнарга:  
Тыныч кына Коръән белән өндә,  
Мәҗбүр итмә көфер, саташканнарны!» _

дигән фикер хак тәрҗемә булыр кебек тоела.

Әйе, Коръәндә мәҗбүрләү юк! Ә нәрсә бар? Фәкать өндәү, дәгъвәт, үгет- нәсыйхәт, аңлату, чакыру бар. Раббымызның:

**ادْعُ إِلَىٰ سَبِيلِ رَبِّكَ بِالْحِكْمَةِ وَالْمَوْعِظَةِ الْحَسَنَةِ ۖ وَجَادِلْهُم بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ ۚ إِنَّ رَبَّكَ هُوَ أَعْلَمُ بِمَن ضَلَّ عَن سَبِيلِهِ ۖ وَهُوَ أَعْلَمُ بِالْمُهْتَدِينَ ﴿١٢٥﴾**

**«Ий Мөхәммәд, Раббыңның юлы булган Ислам диненә кешеләрне чакыр, Коръән дәлилләре белән өндә, тәэсирле вәгазьләрең белән кешеләргә хаклыкны төшендерү өчен алар белән тартыш вә көрәш күркәм юл белән!»,** – дигән Коръән-Кәрим аятенә бинаэн А.Пушкинның:

«Восстанъ, пророк, и виждь, и внемли,
Исполнись волею моей,
И, обходя моря и земли,
Глаголом жги сердца людей», _

дип өндәгән юллары татарча шушы яңгырашны табар кебек:

«Әй Пәйгамбәр, күтәрел, чакыр,
Өндә изгелеккә, шулдыр сиңа әмерем,
Диңгезләрне кичеп, җирләр йөреп әйлән,
Хак сүз белән яндыр бәндәләрнең бәгырен».

Аллаһы Хак Сөбханәһү вә Тәгалә үзенең мөбарәк «Әррахмәән» исемен йөрткән Шәрифендә:

الرَّحْمَٰنُ ﴿١﴾ عَلَّمَ الْقُرْآنَ ﴿٢﴾ خَلَقَ الْإِنسَانَ ﴿٣﴾ عَلَّمَهُ الْبَيَانَ ﴿٤﴾

**«Галәмнәрне, мәхлукатьне вә адәмне юктан бар кылган, рәхим-шәфкать иясе Аллаһы Раббымыз дөнья вә ахирәткә Коръән-и Кәрим белән нур салды. Адәмнәр хакны нахактан (караңгылыкны яктылыктан) аера белсеннәр өчен»,** – диде. Бу аятьне әдип:

«Он (Аллах) милосерд:
Он Мухаммаду
Открыл сияющий Коран,
Да притечем и мы ко свету,
И да падет с очей туман», _
«Шәфкатьле Ул:
Ул Мөхәммәдкә

Ачты балкып торган Коръән,
Агым судай юнәлик без яктылыкка
һәм күзләрдән качсын томан», _

дип рухланган, Аллаһы Раббымызны, аның олуг нигъмәте Коръән-и Кәримне, галәмгә рәхмәт өчен, барлык адәмнәргә пәйгамбәр булып килгән Расул Мөхәммәдне ﷺ зурлаган Пушкин иҗатына ничек кенә сокланмыйсың да, ничек кенә шагыйрь белән горурланмыйсың!

Җәнабел Хак Тәгалә сүрәне дәвам итеп, бишенче аяте белән:

الشَّمْسُ وَالْقَمَرُ بِحُسْبَانٍ ﴿٥﴾

**«Кояш, ай (галәмдәге барча җисем) Раббыгыз тарафыннан чикләнгән мәгълүм хисап белән генә йөрерләр»,** – дип вәхи иңдерде. Мөхтәрәм җәмәгать, карагыз, нинди хикмәт! Чыннан да, кем генә белми вә нинди генә инсан күрми – вакыт вә иксез-чиксез киңлектә ай, кояш, планеталар, галактикалардагы йолдызлар, бихисап җисемнәр һичкайчан берләре икенчеләренә орынмыйлар, берләре икенчеләрен этәрмиләр, узышмыйлар, һичничек тә егылмыйлар. Вакыт вә киңлектә чикләнгән үлчәү илән тәртипләнгән хәрәкәттә йөриләр! Кояш, ай, барча җисемнәрне бар иткән вә бер тәртипле юнәлешкә салган, галәмдә вә үз күчәрләрендә әйләнергә боерган – беркем дә күрә алмый торган бөек тарту, куәт көченең барлыгын – ул куәт көченең галәмнәр хуҗасы Аллаһы Хак Сөбханәһү вә Тәгалә икәнлеген фәһемләгән Пушкин:

«Земля недвижна _ неба своды,
Творец, поддержаны тобой,
Да не падут на сушь и воды
И не подавят нас собой», _ диде.

Олуг әдипнең ошбу мәгънәви шигъри юлларын ана телебездә әйтергә кыюлык табыйк.

«Хәрәкәтсез» Җирне _ күкләр гөмбәзләрен,
Тотып торган Куәт көче _ Син иҗатчы,
Әйе, аумас коры җиргә һәм сулары
Таптый алмас безне килсә гарасатлары».

Бу вакытка кадәр үк инде Англиянең бөек галиме физик Исаак Ньютон тарафыннан ачылган «Дөньякүләм тарту кануны» («Закон всемирного тяготения») әдип җөмләсенә дәлил булып тора.

Дөнья малын яуламак өчен адәмнәрне алдап, фәкыйрьләрнең, мескеннәрнең каннарын суырган комсызларга фани дөнья вә кыямәт газапларын вәгъдә иткән Раббымызның фарызларына, вәҗибләренә Пәйгамбәребезнең: «Адәм баласының корсагын туфрактан башка нәрсә тутырмас», – дип әйткән хәдисенә итагать кылып, шагыйрь:

«Торгуя совестью пред бледной нищетою,
Не сыпь своих даров расчетливой рукою:
Щедрота полная угодна небесам.
В день грозного суда, подобно ниве тучной,
О, сеятелъ, благополучный,
Сторицею воздаст она твоим трудам», _

дип, рәнҗетелгәннәрне, кимсетелгәннәрне, көчсезләрне яклады. Бу юлларны түбәндәгечә ирекле тәрҗемәдә тыңласак:

«Төсен җуйган фәкыйрьлек алдында сатып намус,
Мәкер кулың белән санап, мактап сатма хәрам малың:
Галәмнәрдә барлык юмартлыкка белеп тор син Хуҗаң барын.
Кыямәтнең дәһшәтле бер көнендә, иген тулы басу кебек,
Әй, Раббым, рәхим-шәфкать, иминлекне Син чәчүче, майтаручы,
Һәр бәндәнең хәләл хезмәтенә йөздән артык итеп кайтаручы», _

дигән кәлимәләр комсызларны гафиллектән уятыр да, уйга салыр кебек.

Пәйгамбәр Ислам тәгълиматында иң олуг гөнаһларның да олуглары – ялган ант итмәк икәнлеген өммәтенә әйтеп калдырган. Аңа кадәр Аллаһы Раббүл-гыйззә, адәмнең ниндидер максатка ирешү өчен ялган ант итү түгел, хәтта дөрес ант итүенең дә еш кына тиешсез, гөнаһ гамәл икәнлеген Коръән-и Кәримдәге «Бәкара» сүрәсенең 224 нче аятендә әйткән:

وَلَا تَجْعَلُوا اللَّهَ عُرْضَةً لِّأَيْمَانِكُمْ أَن تَبَرُّوا وَتَتَّقُوا وَتُصْلِحُوا بَيْنَ النَّاسِ ۗ وَاللَّهُ سَمِيعٌ عَلِيمٌ ﴿٢٢٤﴾

**«Ий мөэминнәр, антыгызны Аллаһыга сылтау кылмагыз! Аллаһы исеме белән ант итмәгез!»**, – дип фарыз кылды. Ни өчен? Чөнки Аллаһы исеме белән ант иткән иң беренче зат Иблис иде. Коръән тотып ант итү Ислам диненә вә шәригатенә иң олуг хыянәт икәнлеген тоемлаган Александр Пушкин:

«Мужайся ж, презирай обман,
Стезею правды добро следуй,
Люби сирот и мой Коран
Дрожащей твари проповедуй», _ ягъни:
«Батыр бул. Калтыранган мәхлукка аңлат,
Ялганлыкны тапта, Хак юлдан кыю атла,
Ятимнәрне якла һәм Коръәнгә
Минем мәхәббәтемне сакла», _

дип, ялганчыларга нәфрәтен, фәкыйрьләргә Раббымызның олуг нигъмәте Коръән-и Кәримгә мәхәббәтен белдерә.

А. С. Пушкинның Исламга мәхәббәтенең төп сәбәбе Коръән сүрәләрендәге аяти кәлимәләрнең әдәби телдә язылуында вә тәҗвид моңы белән укылуында. Коръәнгә мөкиббән шагыйрь, ихлас күңел белән иҗтиһад кылып, 1824 елда Изге Китапны тәрҗемәдә өйрәнгән.

«В пещере тайной, в день гоненья,
Читал я сладостный Коран».

«Золым көндә серле мәгарәдә
Бик дәртләнеп, укыдым мин
Татлы Коръән рәхәтләнеп».

Коръән-Кәримнең хикмәтле эчтәлегенең тәэсире белән бергә әдипнең иҗатына шәхсән шәҗәрәсе дә бәйле.

Пушкин бабасының атасы (тарихка «Петр I нең гарәбе» булып кергән) Ганнибал мөселман булган. Пушкинның бик тә борынгы әби-бабалары милади 615 нче елда Мәккә кәферләренең эзәрлекләүләреннән Эфиопиягә күчкән мөселманнар булырга мөмкин. Ибраһим Ганнибал Эфиопиянең Лагона шәһәрендә туган. 10 яшьлек Ибраһимны Россиянең илчесе, Төркиядә сатып алып, Петр патшага бүләк иткән. Аңа Ибраһим (Абрам) Петрович Ганнибал исемен Петр I биргән. Ганнибаллар буыны Псковтан ерак түгел Петровское авылында яшәгән.

«В деревне, где Петра творец,
Царей, цариц любимый раб
Скрывался прадед мой араб».
«Петр төзегән авылда,
Патша, бикәләрнең сөйгән колы,
Еракларга яшеренгән минем
Бабамның да бабасы _ гарәп улы».

Бүген без, иманлы бәндәләр, Коръән-и Кәрим белән сугарылган Александр Пушкин иҗатыннан илһам алабыз. Коръән шәрифнең бихисап күп аять-кәлимәләрен шигъри ысул белән тәфсир кылган әдипкә галәмнәр хуҗасы Аллаһы Хак Сөбханәһү вә Тәгаләнең рәхмәтен, гафу-мәгъфирәтен сорыйбыз.

*Харис хәзрәт Салихҗан,*
*«Хәтер» мәчете имам-хатыйбы,*
*Татарстан Республикасы җәмәгать*
*Палатасының эксперты*

# Хөсәен ибн Әмирхан – XIX йөзнең гыйлемле шәхесе

## (иҗатының өйрәнелү тарихы)

Хөсәен ибн Әмирхан ибн Габделманнан ибн Исмәгыйл ибн Морад Әт-Талкыши (1816–1893) – XIX гасыр татар зыялыларының күренекле бер вәкиле. Ул – танылган Әмирханнар нәселеннән, үз заманындагы иң гыйлемле татар руханиларының берсе, Казандагы Яңа татар бистәсенең 6 нчы санлы мәчете имам-хатыйбы, мәгърифәтче, мөгаллим, тарихи, дини эчтәлекле китаплар авторы һәм тәрҗемәче. Хөсәен хәзрәт татар халкының тарихы, XIX гасыр татар әдәбияты һәм тәфсир фәне үсешенә зур өлеш керткән шәхес. Аның әсәрләре тулысынча Ислам рухы белән сугарылган, шул ук вакытта татар (болгар) халкы тарихына караган кыйммәтле материалларга бай. Бу әдипнең яшәгән һәм иҗат иткән чоры белән бәйле, чөнки XIX гасыр татар әдәбияты алдагы чор традицияләренә тугъры кала: үзендә халыкның дини, рухи һәм мәдәни күзаллауларын берләштерә килә, әлеге үзенчәлекләр XIX йөз татар әдәбиятының синкретик характерын билгели.

Хөсәен ибн Әмирханның туган елын билгеләүдә ике төрле караш бар: Ш. Мәрҗани 1816 нчы елны атый (20, 322 б.), ә Р. Фәхретдин исә биобиблиографик «Асар» хезмәтендә Х. Әмирханның 1893 елда 79 яшендә вафат булуын яза (34, 217 б.), димәк, аның туган елын 1814 нче дип саный. Р. Әмирхан, Хөсәен хәзрәтнең Казанда тууын, ә аның әтисе мелла Әмирхан ибн Габделманнан ибн Исмәгыйл ибн Морад ибн Әхмәд Әт-Талкышиның Казанга 1814–1816 еллар арасында күчеп килгән булуын истә тотып (бу турыда Ш. Рәхмәтуллин (23, 47–48) һәм Ш. Мәрҗани (20, 271 б.) хезмәтләрендә хәбәр бирелә), Ш. Мәрҗани фикере белән килешә.

Х. Әмирхан Чистайда һәм Казанда Исхак ибн Сәгыйт хәзрәттә, Мәчкәрәдә Габдулла ибн Яхъя Әл-Чиртуши хәзрәттә укый, соңрак гый-

лем эстәү максаты белән Бохарага китә һәм анда Ш. Мәрҗани белән бер вакытта укый. 1846 елда туган җиренә кайтып Байморад мулла кызы Бәдриҗамалга өйләнә. 1847 елда указ ала (20, 323 б.) һәм Байморад хәзрәт вафатыннан соң Яңа татар бистәсенең 6 нчы санлы Иске Таш мәчете имам-хатыйбы итеп сайлана (24, 278 б.).

Ул бар тормышын диненә һәм халкына хезмәт итүгә багышлый. 1889 елга кадәр имам вазифасын үти, башта ибтидаи мәдрәсәдә (башлангыч мәктәп), соңрак рөшди мәдрәсәдә (урта мәктәп) мөгаллимлек итә, әтисенең атаклы «Әмирхания» мәдрәсәсендә укыта. 1852 һәм 1862 елларда Диния нәзарәте тарафыннан Мәкәрҗә ярминкәсенә Казан шәһәреннән имам итеп билгеләнә (9, 21–22 б.). Хөсәен хәзрәт 1893 елда вафат була һәм Казанның Яңа татар бистәсе зиратында җирләнә (24, 141 б.).

Әдипнең тормышы һәм эшчәнлеге турында чордашлары ук яза башлый. XIX йөз ахырында Ш. Мәрҗанинең «Мустафәд әл-әхбәр фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан вә Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») хезмәте дөнья күрә. «Шәхесләр һәм истәлекле вакыйгалар» бүлегендә Х. Әмирхан турында кыска, ләкин бик кыйммәтле мәгълүмат китерелә (20, 322–323 б.). Риза Фәхретдин дә «Асар»ында хәзрәтнең тормышын һәм хезмәтен яктыртып, бастырылган ике китабы – «әл-Фәуәид» һәм «Тәварихы Болгария» – турында хәбәр итә (34, 217 б.). 1894 елгы «Календарь»да Шиһабетдин Рәхмәтуллин Казан мәчетләре тарихы һәм имамнарына багышланган «Казан шәһәрендәге һәм аның фәнәләрендәге мәсҗидләр» мәкаләсен бастыра. Анда Х. Әмирхан турында «һәр фәндә мүтәбәххир[1] ... галим кеше булган» дип яза (23, 78 б.). XX йөз башының күренекле татар язучысы Ф. Әмирханга багышланган «Фатих Әмирхан» китабында Ибраһим Нуруллин язучының бабасы Хөсәенне дә искә алмый калмый (22, 5–8 б.).

[1] Мүтәбәххир – тирәнтен өйрәнүче, галим.

Совет заманында аның исеме күләгәдә кала килсә дә, татар мәдәниятен яхшы белгән галимнең эшчәнлеге алты томлы «Татар әдәбияты тарихы»нда яктыртылмый кала алмый. Аның исеме һәм «Тәварихы Болгария» хезмәте XIX гасыр ахырының мәшһүр шәхесләре белән беррәттән атала. Ул гына да түгел, «Татар әдәбияты тарихы» авторлары алты томлыкны төзү барышында хәзрәтнең әлеге хезмәтенә таянып эш итә. Бу исә Х. Әмирханның татар историографиясен үстерүгә керткән өлешен билгели.

«Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томында Сөләйман ибн Дауд Сувари[1] турында мәкалә китерелә. Мәкалә авторлары хәбәр итүенчә, Х.Әмирхан «Нүҗүм әт-тәварих» хезмәтендә дә Суваринының «Зуһрат әр-рийаз вә нүзхәт әл-кулуб әл-мәраз» («Гөлбакча чәчәге һәм авыру калебләргә шифа») әсәреннән өзек урнаштырган була (27, 90 б.).

Соңгы елларда Х. Әмирхан иҗаты күп кенә галимнәр хезмәтендә яктыртыла. Алар арасында тарих фәннәре докторы Р. Әмирханның «Бохара гыйлемле мөдәррис» (9, 20–25 б.), «Олуг милләт хадиме» (10, 69–76 б.), «Татарская историография: востоковедческо-тюркологические аспекты» (5, 70–74 б.) мәкаләләрен; америкалы галим Аллен Франкның «Islamic regional identity in Imperial Russia: Tatar and Bashkir historiography in the eighteenth and nineteenth centuries» (44, 157–179 б.) хезмәтен һәм аның рус теленә тәрҗемәсен; Сәлим Гыйлаҗетдиновның «Әмирхан Хөсәен. Тәварихы Болгария... (Болгар тарихы...)» китабын (11); Сәлам Алишевның «Татар тарихчылары»н (3, 80–83 б.); Азат Ахуновның «Амирханов Хуса-

---

[1] Сөләйман ибн Дауд Сувари (Саксини) – XII гасыр башы язучысы. Сувар шәһәрендә туган, болгар казые Хәмид Болгарида белем алган. Фарсы телендә иҗат ителгән «Бахджат әл-әнвар мин хакыкат әл-әсрар» («Серләр ачылышының балкышы») авторы. Автор әлеге әсәрне «Нузхат аль-кулуб аль-мараз» («Авыру калебләргә шифа») исеме астында гарәп теленә тәрҗемә итә. Соңрак тагын үзгәрешләр кертә һәм «Зуһрат әр-рийаз вә нүзхәт әл-кулуб әл-мәраз» («Гөлбакча чәчәге һәм авыру калебләргә шифа») дип атый. Әлеге әсәр төрки халыклар арасында бик популяр була һәм күп кенә кулъязма җыентыкларга кертелә. Ш. Мәрҗанинең әлеге әсәрдән аерым бүлекләрне бастыруы билгеле. Бүгенге көндә «Зуһрат әр-рийаз»ның бер кулъязмасы Истанбулдагы Топ Капу музеенда саклана (27, 89 б.; 25, 155 б.).

ин. Таварих-е Булгарийа (Булгарские хроники)» хезмәтен һ. б. атап үтәргә мөмкин.

Х. Әмирханның иҗади мирасы иске татар һәм гарәп телләрендәге берничә кулъязма һәм басма китаптан гыйбарәт. Р. Гайнанов аны 14 хезмәт авторы дип билгели (9, 24 б.). Әмма ул хезмәтләрнең күпчелеге югалган, бүгенге көнгә кадәр сакланмаган. Безгә язучының XIX нчы гасыр ахырында Казанда аерым китап булып бастырылган дүрт әсәре билгеле.

Аларның иң әһәмиятлесе дип «Тәварихы Болгария»не атарга була. Әсәрнең кулъязма нөсхәсе сакланмаган, ул 1883 елда Казанның Вечеслов басмаханәсендә авторның улы Мөхәммәдзариф Әмирхан[1] тырышлыгы белән аерым китап итеп бастырыла. Безнеңчә, нәкъ шул сәбәпле кайбер галимнәр (Н. Ф. Катанов, Ш. Ш. Абилов, З. А. Ишмөхәммәтов, Т. Батыркаев) хезмәтнең авторы Мөхәммәдзариф Әмирханов дигән ялгыш фикердә тора (15, 25–26 б.; 16, 64–67 б.; 1; 14, 51 б.; 10).

«Тәварихы Болгария» – XIX гасыр татар тарихи чыганагы. Ул үзендә мөселман дөньясы, аерым төрки һәм ислам дәүләтләре, Болгар һәм Казан ханлыгы турында тарихи, күренекле шәхесләр турында библиографик мәгълүматлар туплаган. «Мөхәммәдхан Әбулгази Бахадирхан Хаваризи вә Чыңгыз кыйссасы», «Чыңгыз ханның дөньяга килгән кыйссасы», «Әмир Тимер бин Тургай Барлас кыйссасы», «Болгар кыйссасындадыр», «Болгарда вә әтрафында булган голәмә вә мәшәехләр вә нәсари аслы кыйссасында», «Болгарда булган гулямә вә мәшәихләр бәянындадыр», «Хосус Казан бәянындадыр», «Кабан күле кыйссасы», «Урысның Казан алу кыйссасы», «Бистә димәк кыйссасы», «Черек күл кыйссасы», «Хикәят. Хытай хан», «Яңа бистә димәк кыйссасы» дип аталган бүлекләрдән һәм «Мукаддәмә» («Кереш») вә «Хатимә» («Йомгак») өлешләреннән тора.

[1] Мөхәммәдзариф Әмирхан (1853–1921) – дин әһеле, Казанның 6 нчы санлы мәчете имам-хатыйбы, «Әмирхания» мәдрәсәсе мөгаллиме, рөшди мәдрәсәләрдә дәреслек сыйфатында кулланылып килгән «Әхәдисән-Нәбәуийа» («Пәйгамбәр хәдисләре» (1909) (25, с. 76), «Әхәдис әл-Кудсийа» («Изге хәдисләр» (1909), «Әхәдис әл-Кудсийа. Тәрҗемәсе илә» («Изге хәдисләр. Тәрҗемәсе белән» (1909) һ.б. дини китаплар авторы.

Әлеге хезмәтне язганда автор халык риваять-легендаларына, Кәтиб Чиләбинең[1] «Җиһаннамә»сенә, Мөхәммәдхан Әбулгази Бахадирхан Хәрәзминең[2] «Шәҗәрә-и төрк»енә, ибн Гарәбшахның[3] «Тимурнамәсе»нә, Хисаметдин Әл-Болгариның[4] «Тәварихы Болгария»сенә, Фирузәбадиның[5] «Камус»ына һ. б. дөньякүләм билгеле Шәрык чыганакларына нигезләнгән.

«Тәварихы Болгария» Х. Әмирханның чордашлары тарафыннан югары бәяләнә һәм күп еллар дәвамында мәдрәсәләрдә дәреслек буларак кулланыла (9, 23 б.). «Деятель» журналының 1898 елгы санында Н. Катанов «Кабан күле һәм Казан шәһәре турында татар риваятьләре» (15) һәм «Казан шәһәренең Татар бистәсе һәм Яңа татар бистәсе турында татар риваяте» (16) дип аталган мәкаләләрен бастыра. Анда рус теленә тәрҗемә ителеп һәм кайбер аңлатмалар белән «Тәварихы Болгария»дән риваятьләр китерә. «Православный собеседник» журналына кушымта буларак чыгарылып килгән «Инородческое обозрение»нең (21) 1912 елгы санын-

[1] Кәтиб Чиләби Мостафа бин Габдуллаһ (1609–1657) – Төркиянең танылган тарихчысы һәм библиографы. «Кашф аз-зунун ‹ан асами ал-кутуб ва-л-фунун» («Раскрытие сомнений в названиях книг и наук») библиографик сүзлеге, «Джиханнаме» («Описание мира») географик хезмәте һ.б. китаплар авторы (4, с. 21).

[2] Мөхәммәдхан Габделгази Бахадирхан Харәзми (1603–1663) –мөселман тарихы белгече, шагыйрь, төрки халыклар шәҗәрәсе турындагы «Шәҗәрәи төрк» («Родословное древо тюрок») һәм төрекмән шәҗәрәсе «Шәҗәрәи Таракима» («Родословное древо туркмен») хезмәтләре авторы (41, с. 47).

[3] Әхмәд ибн Мөхәммәд ибн Гарәбшах (1389–1450) – гарәп язучысы. «Тимурнамә» («История о Тимуре», «History of Timur») хезмәте авторы (42, с. 739–740).

[4] Хисамеддин ибн Шәрәфеддин әл-Болгари (Мөслими) – XVI гасырда иҗат ителгән «Тәварихы Болгария» хезмәте авторы. Әлеге авторның шәхесе галимнәр тарафыннан тәгаен билгеләнмәгән, чөнки әлеге исем псевдоним дип санала. «Тәварихы Болгария»дә ул үзенең Ташбилге авылындагы Мөслим баба нәселеннән булуы, Тафтазанида укуы турында яза. Ләкин күп кенә даталар дөреслеккә туры килми, шуңа хезмәт күп галимнәрнең тәнкыйтенә дучар була (33, с. 33–34; 36, с. 79–83).

[5] Фирузәбадий (Мәҗеддин Әбү әт-Тахир Мөхәммәд Ширази, 1329–1414) – Шираз янында туган, Багдад һәм Димәшкта белем алган. Иерусалим, Кече Азия, Мисыр, Мәккә һәм Һиндстанда яшәгән. Йәмәндә баш казый итеп билгеләнгән. «Камус» – гарәп теленең танылган аңлатмалы сүзлеге авторы. Бик катлаулы булуы сәбәпле, әлеге сүзлектәге аңлатмаларны иң белемле гарәпләр дә аңлап бетермәскә мөмкин, шуңа сүзлеккә бик күп комментарийлар язылган. Аларның берсе XVIII гасырда Сәет Мортаза әз-Забури (1791 елда вафат) тарафыннан төзелгән һәм «Тадж аль-›арус» («Венец невесты в деле истолкования Камуса») дип аталган (43, с. 40).

да «Новые труды по татарской истории» («Татар тарихына караган яңа хезмәтләр») мәкаләсе бастырыла. Мәкалә авторы Ә. Вәлидовның «Төрек вә татар тарихы» хезмәтен Х. Әмирханнның «Тәварихы Болгария»се белән чагыштырып анализлый (21, 74 б.).

«Материалы по истории Татарии» («Татарстан тарихы буенча материаллар») китабында татар язучылары иҗат иткән иң кыйммәтле тарихи әсәрләрдән Хисаметдин Әл-Болгариның «Тәварихы Болгария», Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфад әл-әхбар...», Каюм Насыйриның археологик мәкаләләре, Х. Әмирханның «Тәварихы Болгария» һәм М. Рәмзинең «Тәлфик әл-әхбар вә тәлких әл-әсәр фи вәкаигъ Казан вә Болгар вә мөлүк әт-татар» («Казан, Болгар һәм татар хакимнәре турында хәбәрләр, вакыйгалар, риваятьләр җыелмасы») хезмәтләре атала. Бу хезмәтләрнең кимчелеге түбәндәгечә билгеләнә: «Давая много важного фактического материала, эти четыре автора часто страдают тем недостатком, что не делают точных указаний на первоисточники» («әлеге авторлар мөһим фактик материалларны күп бирәләр, ләкин барысы өчен дә уртак бер җитешсез яклары бар: алар беренчел чыганакларга сылтама китермиләр» – Г. Н.) (19, 100 б.).

«Татарские исторические источники XII–XIII веков» китабында Х.Әмирхан исеме Хисаметдин Әл-Болгариның «Тәварихы Болгария» китабын каты тәнкыйтьләгән Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин, Ә. Рәхим һәм Г.Ибраһимовлар исеме белән беррәттән атала (32, 222 б.).

А. Ахунов билгеләвенчә, Хөсәен хәзрәт әсәрендә бар замандашларын уңай бәяли: «О ком бы из татарских деятелей ни шла речь, Х. Амирхан дает исключительно положительную оценку их жизни и деятельности. В этом его главное отличие от «Мустафада» Ш. Марджани, который не щадил своих героев, подробно описывая их неблагочестивые дела, если таковые имели место быть» (4, 11 б.) («Кайсы гына татар шәхесе турында сүз бармасын, Х. Әмирханов аның тормыш юлы һәм эшчәнлегенә фәкать

уңай бәя бирә. Нәкъ шуның белән ул Ш. Мәрҗанинең «Мостафад»ыннан аерылып тора» – Г.Н.).

«Татар шигърияте антологиясе»ндә «Тәварихы Болгария» урта гасыр шагыйре Мөхәммәд Әмин[1] исеменә нисбәтле искә алына (6, 143 б.). Аның «Гыйкаб» шигырен Х. Әмирхан үзенең хезмәтенә керткән була.

«Татар халык иҗаты. Бәетләр» җыентыгына кертелгән татар халык авыз иҗаты ядкәре «Аксак Тимер бәете» дә шул хезмәттән күчереп алынган (30, 351 б.). «Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар» (31) җыентыгының керешендә С. Гыйлаҗетдинов Х. Әмирхан исемен Ш.Мәрҗани, М. Аитов, Г. Әхмәров, Х. Атласи, М. Рәмзи, Р. Фәхретдин кебек галимнәр белән бергә атый. Ул бу авторларның барысының да Болгар яки Казанга бәйле тарихи вакыйгаларны халык риваятьләренә нигезләнеп тасвирлавын ассызыклый (31, 8 б.). Җыентыкның нигезенә алда аталган галимнәрнең хезмәтләре ята. «Иске Казан каласының корылуы», «Әби патша», «Бистә димәк кыйссасы», «Кабан» һ. б. риваятьләр «Тәварихы Болгария»дән алына.

Соңгы елларда бу тарихи хезмәт күп кенә галминәрдә кызыксыну уятты. 1994 елда америкалы галим Аллен Франк «Islamic regional identity in Imperial Russia: Tatar and Bashkir historiography in the eighteenth and nineteenth centuries» дип аталган диссертация яклый (44). Аның бер бүлекчәсен Х. Әмирхан язган «Тәварихы Болгария»гә багышлый һәм әлеге хезмәтне Хисаметдин әл-Болгари иҗат иткән «Тәварихы Болгария»нең шәрехе дип атый. Ул имамның хезмәтен Идел-Урал мөселман тарихына караган мөһим эш дип билгеле: «Mulla Husayn Amirkhanov's Tawarakh-I Husayniyah is an important transitional work in Volga-Ural historiography» (44, 177 б.). Әсәрнең галимнәр игътибарыннан читтә калуына гаҗәпләнә: «Пренебрежительное отношение, которое вызвала к себе история Амир-

[1] Мөхәммәд Әмин (XV гасырның II яртысы – 1518) – 1487–1496, 1502–1518 елларда идарә иткән Казан ханы, шагыйрь. Безнең көннәргә аның «Гыйкаб» («Үч») шигыре килеп җиткән. Н.Ф. Катанов аны рус теленә тәрҗемә иткән һәм авторын татар шагыйре дип атаган.

ханова, огорчает, т.к., наряду с другими причинами, эта история – богатый и доступный источник для изучения истории волго-уральских улемов» (36, с. 168) («Әмирханов тарихына илтифатсыз мөнәсәбәт бик борчый, чөнки, башка сәбәпләр белән беррәттән, бу тарих – Идел-Урал галимнәре тарихын өйрәнү өчен бай һәм аңлаешлы чыганак» – Г. Н.).

Күренекле алман галиме Михаэль Кемперның «Sufis und Gelehrte in Tatar und Baschkirien, 1789–1889: der islamische Diskurs unter russischer Herrschaft» (45) хезмәтендә Х. Әмирханның «Тәварихы Болгария»се Хисаметдин әл-Болгариның «Тәварихы Болгария» әсәренә тәфсилле шәрех буларак бәяләнә (18; 97, 511 б.). Кемпер Х. Әмирханның Хисаметдин әл-Болгари әсәрендәге кайбер анахронизм һәм төгәлсезлекләрне («Anochronismen und Unglaubwürdigkeiten» (45, с. 381)) тәнкыйтьләвен билгели. Мисал өчен, болгарларның Пәйгамбәр сәхабәләре аша Ислам динен кабул итүләрен һ. б.

1994 елда «Мирас» журналында «Тәварихы Болгария»нең «Махсус Казан бәянындадыр» дип аталган җиденче бүлеге бастырыла. Аның хәзерге татар теленә тәрҗемәсе Сәлим Гыйлаҗетдинов тарафыннан эшләнә (37). 2001 елда шул ук автор әсәрнең тулы текстын хәзерге татар теленә тәрҗемәсе һәм транскрипциясе белән аерым китап буларак бастыра (11). 2006 елда «Тәварихы Болгария» рус телендә дөнья күрде, әлеге хезмәт Азат Ахунов тарафыннан башкарылган, әсәрнең факсимеле һәм комментарияләр белән баетылган (4).

1884 елда Казанда Х. Әмирханның «Шәҗәрә-и галия фи бәян әләнсаб» яки «Нүҗүм әт-тәварих» (38) хезмәте бастырыла. Әсәрдә күренекле руханилар турында һәм мөселман илләре тарихына караган легенда һәм мәгълүматлар китерелә. Р. Салихов һәм Р. Хәйретдинов «Аның (Х.Әмирханның – Г. Н.) «Тәварихы Болгария» (1883) һәм «Бөек шәҗәрә яки нәселләр бәяны» (1884) кебек әсәрләре бүген дә әһәмиятләрен югалтмадылар», – дип билгели (24, с. 9). 1885 елда Х. Әмирханның «Тәварихы

Мәккәи-Мөкәррамә галә фатихиһә әфдал әс-саләт вә әкмәл әт-тәхият» («Изге Мәккә тарихы, аны ачучыга [Мөхәммәдкә] иң күркәм мактаулар һәм иң камил сәламнәр») (39) һәм ике томлы «әл-Фәуәид» («Файдалар») (40) Коръән тәфсире дөнья күрә. Бу тәфсирне Русиядә төрки телләрдә чыккан һәм халык арасында киң таралган тәфсирләрнең берсе буларак, «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр» китабында Р. Фәхретдин искә ала (35, 136 б.). Ш. Рәхмәтуллин бу тәфсир «дайрәмез лисанында улдыкыннан гаять файдалыдыр» дип билгели (23, 48 б.). Соңгы елларда «әл-Фәуәид» татар телендәге тәфсирләргә багышланган мәкаләләрдә искә алына башлады (2; 7, 91–95 б.; 8; 12; 13, 82 б.).

«Тәварихы Болгария» хезмәтеннән кала, Х. Әмирханның башка әсәрләре бүгенге көнгәчә өйрәнелмәгән. Алар бары авторның исеме белән генә искә алына киләләр. Моннан тыш, Х. Әмирханның шәхси архивларда һәм китапханәләрдә саклонучы кульязмалары һәм тәрҗемәләре дә билгеле. Алар барысы да тәфсилләп өйрәнүне таләп итә. Бу үз чиратында, татар әдәбияты тарихының күп кенә сәхифәләренә ачыклык кертәчәк, аларны тулыландырачак һәм баетачак.

**Әдәбият исемлеге:**

1. Абилов Ш.Ш. Әдәби мохит һәм ядкярләр // Татар әдәбияты тарихы.– Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1984. – Т. 1. – Б. 283–295.

2. Адыгамов А. Традиции комментирования Корана у татар. – [Эл. ресурс]: http://dumrt.ru/node/5882 (дата обращения: 07.06.3013).

3. Алишев С. Татар тарихчылары. – Казан: Татарстан китап нәшр., 2006. –206 б.

4. Амирханов Хусаин. Таварих-е Булгарийа (Булгарские хроники); пер. со старотат., вступ. ст., и коммент. А.М. Ахунова. – М.: Марджани, 2010. – 232 с.

5. Амирханов Р.У. Татарская историография: востоковедческо-тюркологические аспекты // Научный Татарстан. – 2000. – № 3. – С. 70–74.

6. Антология татарской поэзии. В двух томах / сост. Гарай Рахим. – Казань: Татарское книжное издательство, 1992. – Кн. 1. – 543 с.

7. Ахунов А.М. Исламизация Волжско-Камского региона (VII-X вв.). – Казань: Отечество, 2003. – 110 с.

8. Ахунов А.М. Коран по-татарски // Татарский мир. – 2004. – № 4. – [Эл. ресурс]: http://www.tatworld.ru/article.shtml?article=496 (дата обращения: 03.09.2013).

9. Әмирхан Р. Әмирханнар (тәфсилле шәҗәрә). – Казан: Мәгариф, 2005. – 223 б.

10. Әмирхан Р. Иманга тугърылык. – Казан: Татарстан китап нәшр., 1997. – 384 б.

11. Әмирхан Хөсәен. Тәварихы Болгария (Болгар тарихы). Төзүчесе һәм тәрҗемәчесе Сәлим Гыйләҗетдинов. – Казан: Иман, 2001. – 192 б.

12. Батыркаев Т. Кораническая экзегетика мусульман Поволжья и Приуралья (конец XVIII – начало XX вв.) // Минарет. – 2007. – № 4 (14). – [Эл. ресурс]: http://www.idmedina.ru/books/history_culture/?104 (дата обращения: 30.08.2013).

13. Исламоведение: пособие для преподавателя / Э.Р. Кулиев, М.Ф. Муртазин, Р.М. Мухаметшин и др.; общ. ред. М.Ф. Муртазин. – 2-е изд., испр. – М.: Изд-во Моск. исламского ун-та, 2008. – 416 с.

14. Ишмухаметов З.А. Социальная роль и эволюция ислама в Татарии. – Казань: Татарское книжное издательство, 1979. – 224 с.

15. Катанов Н.Ф. Татарские предания об озере Кабанев гор. Казани // Деятель. – 1898. – №1. – С. 25–26.

16. Катанов Н.Ф. Татарское предание о слободах Татарской и Навотатарской в гор. Казани // Деятель. – 1898. – № 2. – С. 64 – 67.

17.

. حسن بن اميرحان .تواريخ مكهء مكرمه على فاتحها افضل الصلوة و اكمل التحيات – قزان :قزان . ٨٨ – ١٨٨٥ – اونيويرستيتننك طبع خانهسنى بيت

18. Кемпер М. Суфии и ученые в Татарстане и Башкортостане. Исламский дискурс под русским господством / пер. с нем. – Казань: Российский исламский университет, 2008. – 675 с.

19. Материалы по истории Татарии. – Казань: Татгосиздат, 1948. – Вып. 1. – 486 с.

20. Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татарстан китап нәшрияте, 1989. – 415 б.

21. Новые труды по татарской истории // Инородческое обозрение. Приложение к журналу «Православный собеседник». – Казань: Центральная типография, 1912. – Кн. 1. – 80 с.

22. Нуруллин И. Фатих Әмирхан. – Казан: Татарстан китап нәшр., 1988. – 279 б.

23.

الدين. كاليندار. ١٨٩٤ نجى يل اوجون. شهاب الدين بن ملا عبد العزيز رحمة الله اوغاى ننك رحمة الله شهاب تأليفى قزان اونيويريسيتيتى طبع خانه سنى.– ١٨٩٣. — ٤٧–٤٨

24. Салихов Р., Хайретдинов Р. Татарстан җөмһүрияте: татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре (XVIII гасыр ахыры – XX гасыр башы). – Казан: ФЕСТ, 1995. – 278 б.

25. Сафиуллина Р.Р. Арабская книга в духовной культуре татарского народа. – Казань: Алма-лит, 2003. – 214 с.

26. Средневековая татарская литература (VIII-XVIII вв.). – Казань: Фэн, 1999. – 240 с.

27. Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. – Казан: Татарстан китап нәшр., 1984. – Т. 1. Урта гасырлар дәвере. – 565 б.

28. Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. – Казан: Татарстан китап нәшр., 1985. – с. Т. 2. XIX йөз татар әдәбияты. – 575 б.

29. Татарский энциклопедический словарь / гл. ред. М.Х. Хасанов. – Казань: Институт татарской энциклопедии АН РТ, 1999. – 690 с.

30. Татарское народное творчество. Баиты. – Казань: Татарское книжное издательство, 1983. – 351 с.

31. Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С.М. Гыйләҗетдинов. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1987. – 368 б.

32. Усманов М.А. Татарские исторические источники XII–XIII веков. – Изд-во Казанского университета, 1972. – 222 с.

33. Фәхреддин Р. Асар.– Казан: Рухият, 2006. – Т. 1. – 360 б.

34. Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. – Казан: Рухият, 2010. – 648 б.

35. Фахреддин Р. Коръән вә табагат. – Казан: «Рәшидә» Коръән өйрәнү үзәге, 2012. – 156 б.

36. Франк А. Исламская историография и «булгарская» идентичность татар и башкир в России. – Казань: Российский исламский университет, 2008. – 266 с.

37. Хөсәен Әмирхан. Болгар тарихы. Махсус Казан баянында // Мирас. – 1994. – № 10. – Б. 109–112; № 11–12. – Б. 105–110.

38.

حسن بن اميرحان. - شجرهء عليه فى بيان الانساب. نجم التواريح. سنكت بيطربورخ. – ١٨٨٤.- ٣٦٩ بيت

39.

حسن بن اميرحان. – تواريخ مكهء مكرمه على فاتحها افضل الصلوة و اكمل التحيات. – قزان: قزان اونيويرستيتىننك طبع خانهسنى. - ١٨٨٥. – ٨٨ بيت.

40.

حسن بن اميرحان.تفسير الفوا ئد. – قزان. - ١٨٨٥

41. Энциклопедический словарь /под ред. проф. И. Андреевского; издатели: Ф.А. Брокгауз, И.А. Ефрон.– СПб.: Семеновская Типо-Литография (И.А. Ефрон), 1890. – Т. 1. – 480 с.

42. Энциклопедический словарь / Ф.А. Брокгауз, И.А. Ефрон. – СПб.: ТипоЛитография И.А. Ефрона, 1894. – Т. 12. – 960 с.

43. Энциклопедический словарь / Ф.А. Брокгауз, И.А. Ефрон. – СПб.: Типография акц. общ. «Брокгауз–Ефрон», 1902. – Т. 36. – 478 с.

44. Frank, A.J. Islamic regional identity in Imperial Russia: Tatar and Bashkir historiography in the eighteenth and nineteenth centuries / A.J. Frank. – Ph.D. – Indiana University, 1994. – 229 p.

45. Kemper, M. Sufis und Gelehrte in Tatar und Baschkirien, 1789-1889: der islamische Diskurs unter russischer Herrschaft Kemper. – Berlin: Schwarz, 1998. – 516 s.

*Гөлназ Нургатина,*

*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге*

*Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты*

# КОРЪӘН ТУРЫНДА ГЫЙЛЕМ

*(Дәвамы. Башы журналның 13, 15 нче саннарында)*

## Аятьләрнең тәртипкә салынуының нигезе

Барлык борынгы һәм алардан соң килгән галимнәр шул хакта бердәм фикердә ки, Коръән аятьләренең тәртип белән урнаштырылуы аның Илаһияттән («тәүкыйфый») булуыннандыр. Ягъни, сәхабәләр Коръәнне тәртипкә салып төзегәндә Пәйгамбәребезнең ﷺ әмеренә нигезләнеп эш иттеләр, ә Пәйгамбәребез ﷺ исә бу эшкә Җәбраил фәрештәдән (عليه السلام) өйрәнде. Бу мәсьәләдә беркемнең дә шиге юк[1].

Әбү Җәгъфәр ибне Әз-Зөбәер бу мәсьәлә турында шуны әйткән: «Аятьләрнең тәртип белән урнаштырылуы Пәйгамбәребезнең ﷺ әмере белән эшләнде һәм бу мәсьәләдә мөселманнар арасында бернинди дә каршылык (ихтилаф) булмады»[2].

Әл-Казый Әбү Бәкер Әл-Бәкыйлләни «Әл-Интисар» дигән китапта болай дигән: «Аятьләрнең тәртип белән урнаштырылуы – мәҗбүри булган норма. Җәбраил «Бу аятьне шушы урынга куегыз», – дип әйтә торган булган».

Аятьләрнең тәртип белән урнаштырылуының «тәүкыйфый»лыкка[3] нигезләнгәнлеген раслый торган бик күп тәвәтүр-хәдисләр бар. Аларның барысын да монда китереп тә булмый.

Әмма без, мисал итеп, Пәйгамбәребез ﷺ тарафыннан башкарылган бу эшне ачыклап яктыртыр өчен, аларның берничәсен укучыларыбызга тәкъдим итәбез:

Әл-Бохари[4] Габдулла Әз-Зөбәернең сүзләрен китерә:

---

1 «Әл-Борһан» (1/256) һәм «Әл-Иткан» (1/60).

2 «Әл-Иткан» (1/60).

3 Коръән аятфьләренең Пәйгамбәребез ﷺ кушканча тәртип белән урнаштырылуы.

4 6/31

«Бервакыт мин Госман ибне Гаффанга» ويذرون ازواجا والذين يتوفون منكم («Сезләрдән булган кемнәр үлеп, хатыннары калган булса») дигән аять мәнсух булды (гамәлдән чыгарылды) – аны язып тормасаң да буламы, әллә инде аны шул килеш үк калдырыргамы?» – дигәч, Госман ибне Гаффан миңа болай диде: «Әй минем туганымның улы! Мин Коръән өлешләренең урыннарын берничек тә үзгәртмим», – дип».

Әхмәд һәм Мөслим[1] Гомәрнең ﵁ ошбу сүзләрен тапшыралар: «Мин Пәйгамбәребездән ﷺ «кәлалә» (берәү үлгәннән соң, аның әти-әниләре яисә балалары калмаган булса) турындагыдан да күбрәк сораганым булмады. Ул хәтта минем күкрәгемә бәреп, «Әй Гомәр, сиңа «Хатыннар» сүрәсенең азагындагы җәйге аять җитмәдемени?» – диде».

Әхмәд имам Госман ибне Әбү Әл-Гастаннан расланган иснәдле хәбәр китерә: «Мин Пәйгамбәребез ﷺ янында булган чакта кинәт кенә шуны күрдем ки, ул ﷺ акрын гына күзләрен өскә таба юнәлтеп бер ноктага карады һәм әйтте: «Әле генә минем янымда Җәбраил булып китте һәм миңа «Чынлыкта, Аллаһ сезгә гадел булырга, изгелек кылырга һәм туганнарыгызга бүләкләр биреп яшәргә боера» дигән аятьне сүрәнең менә бу җиренә куерга кушты»[2]. Шулай ук аятьләрнең төгәл үз урыннары булуын башка хәдисләр дә исбатлыйлар – бу фактлар барысы да аятьләрнең тәртип белән урнашканлыгын барыбызга да таныталар. Мәсәлән: «Ике сахыйх җыентыкта»[3] китерелгән «Бакара» сүрәсендәге соңгы аятьләрнең фазыйләте турындагы хәдисләр; Мөслим[4] җыентыгында китерелгән «Мәгарә» сүрәсендәге башлангыч ун аятьне (башка версияләрдә – соңгы ун аятьне) ятлауның фазыйләте һәм аның Дәҗҗалдан котылуга китерүе турындагы хәдис.

---

1 «Әл-Мөснәд» (1/26) һәм Мөслим (5/61).

2 «Әл-Мөснәд» (4/218) һәм «Әл-Иткан» (1/60).

3 Бохари (6/188) һәм Мөслим (2/198).

4 Мөслим (2/199).

Шулай ук Пәйгамбәребезнең ﷺ Коръән сүрәләрен урнаштырылган тәртиптә укуы турында да хәдисләр бик күп китерелә.

## Коръәндәге сүрәләрнең урнашу тәртибе

Галимнәр хәдисләрне төрлечә шәрех кылу нәтиҗәсендә сүрәләрнең бер тәртип белән урнаштырылуы турында ихтилафка килделәр. Аларның кайберәүләре «Коръән сүрәләренең тәртибен иҗтиһад кылып, сәхабәләр үзләре билгеләделәр» дип расладылар.

Галимнәрнең күпчелеге исә, Коръән сүрәләренең тәртибе сәхабәләр тарафыннан түгел, Пәйгамбәребез ﷺ тарафыннан билгеләнде, диләр. Әмма бу фикерне раслауда да алар барыбер ихтилафлы булып калдылар: кемдер сүрәләр тәртибе Пәйгамбәрнең ﷺ ачык әмере белән билгеләнде (ягъни, Пәйгамбәрнең ﷺ сүзен ишетү нәтиҗәсендә) диде; ә кемдер – Пәйгамбәрнең ﷺ укуына карап (ягъни, аны ﷺ күз белән күрү нәтиҗәсендә), – диде.

Ибне Гатыя һәм башка галимнәр «Сүрәләрнең тәртибе Пәйгамбәребез ﷺ вакытында ук билгеләнде («хәвәмим» дип аталган («хә» һәм «мим» хәрефләреннән башлана торган) «җиде иң озын сүрә» кебек һәм йөз аятьтән торган «әл-мофассал» сүрәләре кебек), ә калган сүрәләрне тәртипкә китерү эше мөселманнарның үзләренә тапшырылган булырга да мөмкин», – диләр.

Бу фикер файдасына иң көчле дәлил булып Ибне Габбасның ошбу сүзләре тора: «Мин Госманнан: «Нигә сез күп кабатлана торган «Әнфәл» сүрәсен йөзгә якын аятьле «Тәүбә» сүрәсе белән бергә куйдыгыз, ә араларына «Бисмилләһи-р-Рахмани-р-Рахим» дигән кәлимәне куймадыгыз? Сез бит (болай булгач) аны «җиде иң озын сүрә»ләр рәтенә кертәсез», – дип сораган идем». Ул миңа болай диде: «Пәйгамбәребезгә ﷺ берничә аятьттән торган сүрә өлеше иңсә, ул ﷺ үзенең кәтибләреннән берәрсен чакыртып алып: «Бу аятьләрне минә шушы сүрәнең шушы сүзләре әйтелгән урын-

га кертегез», – дип әйтә иде. «Әнфәл» сүрәсе Мәдинәдә беренчеләрдән булып иңгән сүрәләрнең берсе иде, ә «Тәүбә» исә – соңгылардан булып иңгән сүрә. Ләкин аларның эчтәлекләре шулкадәр охшаш – шуңа күрә дә мин аны («Тәүбә»не) («Әнфәл»нең) дәвамыдыр дип тә уйладым. Әмма Пәйгамбәребез ﷺ аның дәвамы булуы турында бернәрсә дә әйтмәгән хәлдә вафат булды. Шуңа күрә, мин аларны чагыштырып карадым да, һәм аларның араларына «Бисмилләһи-р-Рахмани-р-Рахим» дигән кәлимәне куймадым. Шулай итеп, аны «җиде иң озын сүрә»ләр рәтенә керттем». Бу хәдисне Әбү Давыт, Әт-Тирмизи, ибне Хиббән һәм Әл-Хәким тапшырдылар .

Әмма бу хәдисне дәлил итеп кулланырга ярамый – чөнки аның иснәде дә һәм эчтәлеге дә зәгыйфь булып санала.

Иснәденең зәгыйфьлеген анда Йәзид Әл-Фариси атлы бер «зәгыйфь рави-тапшыручы»ның исеме булуы раслый. Бу тапшыручы турында Бохари һәм башка мөхәддисләр:

«Үзе генә тапшырган – шуңа күрә (аның хәбәрләре, бигрәк тә мондый мөһим мәсьәләдә) дәлил була алмый», – дип әйткәннәр .

Ә хәдиснең эчтәлегенә килсәк, шуны гына әйтергә була – билгеле булганча, сәхабәләр Коръәнне һәрдаим укыганнар һәм җентекләп өйрәнгәннәр; шулай булгач, бу мәсьәләдә «Ничек инде аларда бу ике сүрә турында бернинди дә мәгълүмат булмаган?» дигән сорау гына куясы кала.

Әлеге әйткән сүзләрне Әл-Хәкимнең «Әл-Мөстәдрак» дип аталган китабында Ибне Габбасның бирелгән сүзләре дә куәтли. Ул әйткән: «Мин Гали ибне Әбү Талибтан сорадым: «Сез нигә «Тәүбә» сүрәсендә «Бисмилләһи-р-Рахмани-р-Рахим» кәлимәсен язмыйсыз?», – дип. Гали әйтте: «Чөнки «бисмиллә» ул – иминлек, ә «Тәүбә» сүрәсе исә – кылыч белән иңде бит». Әл-Кушайри имам болай дигән: «Дөресе шул – «Тәүбә» сүрәсендә «бисмиллә» юк, чөнки Җәбраил ﷺ аның белән җибәрелмәгән».

Коръән сүрәләренең бер тәртиптә урнашуы – фәкать Югарыдан килгән Күрсәтмә аша гына булганлыгы турында Сөннәттә бик күп дәлилләр бар.

Бу дәлиләр Госман ибне Гаффан төзегән сүрәләр тәртибен раслыйлар. Шуларның берничәсен түбәндә китерәбез:

– Беренче хәдис «Бәни Исраил», «Мәгарә», «Мәрьям», «Та-Һа» һәм «Пәйгамбәрләр» исемле сүрәләр турында. Ул Габдулла ибне Мәсгудтән килә – ул әйткән: «Алар – алдан килгәннәрдән һәм алар – миңа беренче булып килгәннәрдән» (Бохаридан) . Соңыннан сүрәләр тәртибе Ибне Мәсгуд санап чыкканча урнаштырылган.

– Шулай ук сүрәләрнең тәртибе турында Гайшә رضي الله عنها сүзләреннән дә килә. Ул хәдистән белүебезчә – Пәйгамбәребез ﷺ кичләрен йокларга яткан саен учларын кушып, аларга өреп, (сүрәләр) укый торган булган: башта «Әйт: «Ул – Аллаһ Бер...», «Әйт: «Иртәңге таң Раббысына сыенам...» һәм «Әйт: «Кешеләрнең Раббысына сыенам...». Аннары учлары белән куллары җиткән кадәр бөтен тәнен: башта башын, аннары битен һәм тәненең алгы ягын өч мәртәбә сыпыра иде». Пәйгамбәребез ﷺ тарафыннан әйтелгән ошбу сүзләрне Вәсилә ибне Әскәгъ хәбәре аша җиткергәннәр: «Тәурат урынына миңа җиде озын сүрә бүләк ителде, Зәбүр урынына миңа йөзгә якын аятьле булган сүрәләр бүләк ителде, Инҗил урынына миңа күп кабатлана торган сүрәләр бүләк ителде һәм, шуларга өстәлеп, миңа бүленелгән сүрәләр дә бирелде» (Әбү Давыт, Әт-Тәялиси һәм Әбү Гобәйд хәбәрләреннән).

Әбү Җәгъфәр Ән-Нәххас бу хәдис турында болай дигән: «Бу хәдис Коръәннең Пәйгамбәребез ﷺ тарафыннан тәртипкә салынуын раслый. Коръән, төрле төргәкләрдә язылуына карамастан, шул заманда (Пәйгамбәребез ﷺ заманында) ук тәртип белән бербөтен төргәк булarak төзелгән. Бу хәдистә Пәйгамбәребез ﷺ үз сүзләре белән Коръәннең

тәртип белән урнаштырылуын раслый һәм шулай ук «Әнфәл» сүрәсенең «Тәүбә» сүрәсе белән бердәм булмавын да исбатлый».

Сәгыйд ибне Хәлид хәбәр иткән: «Ул ﷺ «иң озын булган җиде сүрә»не бер рәкәгатьтә укыды» (Әбү Шәйбә китергән). Гаүс ибне Әбү Гаүс Әс-Сәкәфидән килгән хәдистә болай диелә: «Мин Ислам кабул иткән сәкифи вәкилләренең төркемендә идем... Пәйгамбәребез ﷺ безгә: «Миңа Коръәннең бер кисәген укып бетерергә кирәк иде, шуңа күрә мин, (шул кисәкне) укып бетермичә, аннан чыкмаска булдым», – дип әйтте. Шуннан соң без Пәйгамбәребезнең ﷺ сәхабәләреннән: «Сез ничек Коръәнне өлешләргә бүләсез», – дип сорадык. Алар безгә: «Без аның кисәкләрендә өчәр, бишәр, җидешәр, тугызар, унберәр, унөчәр сүрә берләштерәбез, ә Коръәннең соңгы кисәгендә – «Каф» сүрәсеннән башлап, барча бүленеп билгеләнгән сүрәләрне (берләштерәбез)» (Әбү Давыт, ибне Маҗә һәм Әхмәд).

Бу фикерне көчәйтә торган башка дәлилләр дә бар – әмма аларны монда китерүнең кирәге юктыр.

Кешегә Коръәндәге сүрәләрнең тәртип белән урнашуын күрер өчен аек акыллы һәм укымышлы булуы да җитәдер.

Кешеләрне сүрәләрнең югарыдан каралган тәртиптә урнаштырылган булуына (ягъни, Пәйгамбәребез ﷺ заманында ук тәртипкә салынган булуына) инандыру өчен, аргумент буларак, исбатлый торган ике дәлил бар:

1. Хәзерге вакыттагы гомуми рәвештә билгеле булган һәм гомуми рәвештә кабул ителгән сүрәләрнең тәртибе фәкать Аллаһы Тәгалә тарафыннан билгеләнүен ошбу факт раслый – «хәвәмим» һәм «таваәсин» дип аталган сүрәләр, охшашлык принцибына нигезләнеп, бер-берсе белән алмаштырылып урнаштырылганнар. Ә «әл-мөсәббәхәт» дип аталган сүрәләрнең урнашуында исә мондый тәртип бер дә күзәтелми (ягъни, «әл-мөсәббәхәт»тә «тасинмим» сүрәләре гел башка төрле («тасинмим»гә охшаш булмаган) сүрәләр белән аралашып урнашканнар – «Шагыйрьләр» һәм «Хикәя» дигән «тасинмим» сүрәләре «Кырмыска» дигән «тасин»

сүрәсе белән аерылганнар (соңгысы теге ике сүрәдән бик күпкә кыска булса да)).

Әгәр дә инде сүрәләрнең тәртибе сәхабәләрнең үзешчәнлегеннән булса – ул очракта «әл-мөсәббәхәт» дигән сүрәләр бер-бер артлы бер тәртиптә һәм башка төрле сүрәләр белән бер дә аралашмыйча гына барырлар иде, ягъни, «Кырмыска» («тасин») сүрәсенең урыны «Хикәя» («тасинмим») сүрәсеннән соң гына булырга тиеш иде.

Башка сүрәләрне дә шулай итеп тикшереп карау нәтиҗәсендә һәрбер кеше сүрәләрнең тәртип белән урнашуы – Илаһи чыганактан булуына инаначак.

Сүрәләрнең тәртип белән урнаштырылган булуларына икенче дәлил ул – күренекле имамнарның фәнни эзләнүләрендә билгеле бер төрле сүрәләрнең бер-берсе белән тәңгәл килү фактларының исбатлануы.

Шулай ук, бу мәсьәләдә барлык Ислам хокукы белгечләренең бердәм карар – иҗмагъка – килүләре дә әһәмияткә ия булган бер факт. Сәхабәләр, барысы да диярлек, бердәм булып сүрәләрнең ошбу тәртибен кабул иткәннәр һәм Коръәнне намазларында һәм кульязмалар укыганда шул тәртиптә укыганнар. Аларга берәү дә шелтә белдермәде яисә төзәтү ясамады, хәтта араларында икенче төрле тәртиптә укыганнар булган очракта да. Икенче төрле тәртипне тотучылар исә, ахыр чиктә, барыбер үзләре белгән һәм күнеккән тәртипләрен калдырырга мәҗбүр булдылар һәм күпчелек тоткан тәртипкә күчтеләр. Нәтиҗәдә, мөселман өммәте ошбу күпчелек тарафыннан кабул иткән сүрәләр тәртибен үз итте һәм бу тәртип мәсьәләсендә хәзер беркемнең дә бернинди дә дәгъвасы юк. Шулай итеп, Госман төзегән Коръән нөсхәсендәге сүрәләр тәртибе Ахыр Көнгә тикле канунлаштырылды һәм һәркемгә фәкать шул канунда гына тору йөкләнде .

*Нуретдин Гыйтырның*

*«Коръән турындагы фәннәр» китабыннан*

*(Дәвамы бар)*

# Тарих

# Дүрт ягым кыйбла:
# Арчаның тарихи халкына бер сәяхәт

*(Башы. Дәвамы киләсе саннарда)*

Арча һәм аның авыллары, юллар, халкы кемне дә сокландырырлык, алар күргән тәрбияне бездә беркемнең дә татыганы юктыр, ахрысы. Монда бар да бер башка югарырак. Тораклары төзек тә, чиста та, ә кешеләре – иманлы. Шулай булмый мөмкин дә түгел. Ничәмә буын шагыйрьләр, язучылар, галимнәр, ил батырлары, аларның да ниндиләре әле – атаклылары, барысы да шушы яктан. Юкка әйтмиләр аларда: «Кешене күтәрсәң – ил күтәрелә, илне үстерсәң – кешеләре үсә!»– дип. Рәхмәт шуны аңлый белүчеләренә!

## I

Безнең сәяхәтебез 2016 елның 27 июнь көнендә башланып китте. Көн кояшлы һәм матур иде. Халык җиләккә йөри, печәнгә төшә башлады. Без исә, бертөркем галим-голамә, кайгыртучан хуҗаларның күрсәтмәләре нигезендә юлга чыктык. Сәяхәтебез Арча якларын тарихи-мәдәни-әдәби яктан комплекслы өйрәнеп кайту максатына корылган иде. Казанда да, Арчада да хуҗалар олы фатихаларын биреп калдылар. Заманалар үзгәрде, халык йорт кыекларын яңарта, профиль калайлар белән матурлап яба. Мондый вакытта тарих тузаннары кубарылучан була.

Миңа борынгы татар китапларын барлау, өйрәнү, фәнни әһәмияте булганнарын дәүләт карамагына алу бурычы йөкләнелгән. Түбә яңартканда, кыек асларына кыстырылып куелган борынгы язма ядкәрләр килеп чыгучан. Нәкъ вакыты. Экспедиция вәзгыятьне белеп оештырыл-

ган. Ул китапларны без быел барлап калырга тиешбез. Бер-ике ел да узмас, беленмиде калыныр, тәмам юкка чыгулары бар.

Беренче тукталу урыны – Арчаның көнчыгыш тарафындагы Поченок Поник авылы. Ул «Поченок» сүзе татар телендә «Түбән» дигәннең синонимы инде, ягъни теге яки бу авылдан аерылып чыккан яңа авыл исеменә өстәмә тагыла торган аталу рәвеше. Рус сүзе «отпочковаться» дигәннән ясалган. Димәк, Поник авылыннан аерылып чыккан инде бу Поченок Поник. Дөресе – Түбән Поник аталырга тиешле, югыйсә. Әмма Арча яклары, шәһәрчәлекне сөеп, сүзне русчалатып җибәрүгә ихлас шул. Алар белән ярышып буламы?

Ә «Поник» дигәне – «түнгән»не аңлатырга тиешле. Без татарлар ул сүзне «чукынган» буларак беләбез. Мәгънәви яктан «Поченок Поник» аталышын тәртипкә китерсәк, бу авыл «Түбән Керәшен» исемен йөртергә тиеш булып чыга.

Поченок Поник авылында мөселман татарлары да яши, әмма тәүдә аны керәшен татарлары нигезләгән булып чыкты.

Раил Бикбаев, җырчы, шушы авылдан икән.

Монда безнең экспедицияне авыл администрациясе башлыгы Гөлфия ханым озата йөрде. Аның белән алдан ук килешенеп куйганнар. Беребезне дә читкә куясы түгел. Кая барабыз, кем белән сөйләшәбез – барасына да күз-колак булып тора. Булдыклы мишәр ханым. Әлки ягыннан. Сары чәчле, зәңгәр күзле. Ире Әнис тә шушында, «мишәр кызы алып бәхетле булдым» дип, мактанып та алды.

Моннан ерак түгел Ключище авылыннан хәзерге көнгә урыны гына калган. Анда руслар яшәгән. Зиратлары бетмәгән әле, диләр.

Урман эчендә дә бер авыл булган. Аны сан белән генә атап йөрткәннәр: «26 нчы авыл» дип. Анысы бөтенләй беткән. Мөгаен бер-бер сәбәп белән көчләп күчерелгән кешеләрдән җыелган булгандыр?

Поченок Поникта Исхакова Мәдинә Ибраһим кызында булдык. 1928 елгы. Аның кулында XIX йөзнең беренче яртысына нисбәтле басма китап Коръән саклана. «Әлхәм сүрәсе» һәм алга таба ике сәхифәсе ертылган, уртадан берничә бите төшкән. Аларны кулдан язып тутырганнар. Мөһере дә бар. Анда «Кәрим бине Өммейәмин» дип сугылган. Мәдинә ханым кулына әнисе Галимәдән мирас буларак килгән. Ул, урман аша тугыз чакрымнар булыр, Балтач районына караган Каенбаш авылында яшәгән. Мәдинә ханымның әтисе Ибраһим исемле булган. Аңарда да китаплар бар иде, ди. Әмма йортлары беткән инде. Димәк, ул китаплар сакланмаганнар.

Мәдинә әби һаман да яшьлеген искә алды. Тормышлар элеккеге елларда авыр булган. Бервакытны, сигез яшьләрендә икән, үкчәсе чиләнгән. Төзәлми дә төзәлми икән. Аңа: «Бүре тәмәкесе сип»,– дип киңәш иткән бер әби. Ул шулай эшләгән. Үкчәсе төзәлгән.

«Бүре тәмәкесен көтүдә күргәнем бар иде, сыер ашаганын. Ул аңа да кирәк була икән, дидем дә – тәвәккәлләдем», – диде Мәдинә әби, мәгънәле бер фикер белдереп.

Аның «бүре тәмәкесе» дигәнен кайбер якларда «бүре гөмбәсе» исеме белән йөртәләр. «Тузаны колакка керсә – чукрак каласың», диләр. Болында балалар, аның өстенә басып, эчендәге «тәмәке»сен туздырып уйныйлар иде. Димәк, юктан гына уйлап чыгарылмаган булган ул уен: чебиләгән һәм бозылган аяклар шуның тузаны йогудан соң төзәлгән.

«Поник» сүзенең мәгънәсен авылда «утын диләнкәсе», «утынлык» буларак аңлаттылар. Монда кирпеч заводы булган. Шуның мичләрен кыздыру өчен бу авылныкылар агач күмере җитештергәннәр. Шушы эшкә килеп йөри торгач, ахырда күпләр бу авылда төпләнеп тә калганнар.

Әмма хәзер ул кирпеч заводы юк икән инде. Эш беткәч, халык та тарала, бәхет эзләп чит-ят якларга китеп бара тора.

Авыл башыннан, көнчыгыш тарафыннан, инеш агып чыга да, көнбатышка таба үтә. Аның аргы ягында ике ихата күренә. Аларның

янышнан биек яр эскерт булып сузыла. Арырак – урман. Көньякка табарак – зират. Монда кирамәт бар икән. Марилар анда элек килә торган булганнар. Дини йолаларын үтәр өчен, әлбәттә.

Әмма борынгы тарихлардан хәбәрдар кешеләр беләдер: кирамәт дигәннәре – торaташ, ягъни балбал инде аның. Аларны скиф-сармат-кыпчаклар куя торан булганнар. Алар күчмә тормыш белән яшәүчеләрнең сакма-җәйләүләрендә юл күрсәткече ролен үтәгәннәр, диннәрендә гыйбадәт өчен дә файдаланылганнар. Аларны «баба ташы» дип тә атыйлар. Изге саналганнар. Ватарга, юк итәргә кыймаганнар. Ә аннары, заманалар үзгәргәч, утрак тормышта яшәүгә күчеп беткәч, ул ташлар сәүдә кәрваннарына юл күрсәтү өчен хезмәт иткәннәр. Үлем-җитемдә алар янынан мәет күмеп калдыру гадәте дә булган. Шулай каберлекләр барлыкка килгән. Торaташлар кабер ташы ролен дә үти башлаганнар.

Аларны ничә күргәнем булды, кайсыларында балбалларга хас уентыларны барларга мөмкин иде. Бәлки кемнәрнеңдер әрсез теләге белән түгел, табигать үзгәрешләренә бәйле, җилдән, яңгырдан, кардан, суыктан бозылганнардыр?

## II

Өйләдән соң безне юлыбыз Ташкич авылына алып китте. Анда истәлекле урыннар бар: минем яшьлегемнең бер ае, көннәре һәм кичләре белән, бераз хәтеремә сеңеп калган иде. Инешенең челтерәүләре һаман да колагымда, чишмәсенең татлы суы әле хәзер дә исемдә кебек. Шуңа күрә дә, авылга килеп туктауга, шул тарафка карап юл алдым. 1985 елда монда көзге кыр эшләренә бертөркем иптәшләр белән мине дә җибәргән иделәр. Басуда да, ындырда да, техника белән дә эшләп алырга туры килде. Казанга төп хуҗалары күчеп киткән бер өйдә яшәдек. Мичләренә җылы итеп яга торган идек. Шундагы учакның ялкын кайнары күңелемә сеңде, берничә шигырь яздым. «Адымлылар» поэмасы шунда иҗат ител-

де. Безнекеләр клубка чыгып китә иделәр. Ә мин – учак саклап калам. Шунлыктан бүген дә клублары кайда икәнлеген белмим. Аргы як урамнарга да барганым булмады. Кибетләренә дә мине йөгертмәделәр. Иртән су алып кайтып, көне буе колхоз эшендә булып, кичен мичкә яга һәм учагын саклый идем. Шунда яки китаплар укыдым, күңелем теләсә – иҗатка чумдым. Үземә шулай аерым бер тормыш, яшәү рәвеше кордым.

Басуда Арча педагогия училищесы студентлары бәрәңге җыя иделәр. Алар тутырган капчыкларны колхоз амбарына трактор белән ташырга дип безне җибәрделәр. Шунда бер туташның шулкадәр оста, шулкадәр җәһәт рәвештә бәрәңге җыйганын күреп, аның сылу сыйфатларына да гаҗәпләнеп, сокланудан телсез калган идем. Менә шул вакыйганы ничәмә кешегә сөйләгәнмендер, бәлки әле язганмындыр? Ташкич авылына бер барып чыгасым килеп яшәлде. Эһ ул вакытларны! Туташка барып сүз катасы идем. Әмма батырчылык җитмәде. Инде хәзер шул бичара егетне дә исемә төшердем.

Тыкрыклары, сукмаклары, чишмәләре, инешләре – берсе дә үзгәрмәгән, нәкъ элеккечә калганнар. Тик менә киртә юк, аны койма алыштырган. Ә анда, тау сыртындагы ермак сыман урында, мин белгән кечкенә наратлар инде шаулап урман булып үскәннәр. Ә арырак, төньяк-көнбатышка таба, басу-кырлар артында кирамәт урыны бар иде. Койма белән әйләндереп алынган. Ул да шул килеш, шаулы булып күренә. Агачлары –биекләр, картлар.

Тыкрыктан авылга күтәрелеп, теге җылы өйгә сәлам биреп уздым. Шул килеш, ямьле булып тора. Хуҗалары, ел да җәйләрен кайтып, төсбуяуларын яңартып китәләр икән!

Авыл уртасында иске бер бина бар иде. Аның урынында хәзер матур мәчет. Имамнары Зәбир Зарипов исемле агай икән. Аның әтисе Хәлиулла улы Мөхәммәтзариф исемле булган. «Сукыр иде, аны мәчеткә җитәкләп йөреп, дингә үзем дә кереп киттем», – дип сөйләп алды Зәбир хәзрәт.

Элек бу авылда данлыклы Борһан мулла яшәгән. Аның хакында ишеткән-белгәнен 1939 елгы Габделфәрт Мәҗитов болай сөйләде: «Без малай идек. Кыш көне җеназасы артыннан йөгереп бардык. Бер сандык китабы калды. Карт иде. Андый муллалар юк инде хәзер... Бервакыт Салавыч ягыннан туганы килде. Хатын-кыз затыннан. Нигезләренә намазлар укып китте. «Кем шулай итә инде» дип, әрнүләрен яшерә алмады, – дип, хәтта бераз моңсуланып та алды. – Борһан мулланың хатыны Салавыч авылыннан булган. Ташкич мәчетен дә шул Салавыч авылыннан бай салдырган. Хәзрәтнең кайнатасы булган ул».

Хәзер авылда Урта Азия якларыннан кайтучылар да тернәкләнеп килә икән. Тырышлар. Ничек тә аякка басарга, ныгып калырга итәләр.

Зиратларында борынгы ташларның булуы хакында ишеткәч, анда да барып килдек. Алар XIX гасырга карыйлар икән. Борынгылары да бар булыр. Әмма табылмадылар. «Аларны галим Әнвәр Хәйри язып алды, укып, өйрәнеп йөрде бервакыт. Колхозга эшкә китерелгәннәр иде. Бездә тордылар,– диде, хәтерен яңартып Габделфәрт агай. – Клубта концертлар да куеп йөрделәр әле алар. Булдыра иде...»

Шунда исемә төште: Риза Фәхретдин, үзенә хат белән: «Ул кабер ташларын уку нәрсә бирә?» – дип мөрәҗәгать итүләренә каршы: «Берни дә бирми. Акча да китерми, сәламәтлеккә дә файдасы юк. Әмма тарихларга бәйле хәтеребезне яңартуга хезмәт итә», – диепме җавап биргән. Шуны иске «Шура» журналыннан укыганым бар иде. Күңелемдә шул хәбәрне яңартып, бераз елмаеп та куйдым.

Зираттан чыккач, рухларын тынгысызлап йөрүемә гафу үтенеп, дога һәм салаватлар укыдым, әһелесенә Аллаһы Тәгаләдән ярлыкау һәм җәннәт үтендем. Бөтен дөньялык тынычланып калды. Искән җилләр туктады. Сибәләп кенә яңгыр явып алды. Озата килгән Габделфәрт агай бераз аптырашта торды. Аннары: «Казаннан, Мәрданов бугай, килгән иде. Ул ташларны, борынгыларны, аның белән тапкан идек. Кая гына киттеләр икән?» – диде.

Авыл төшеп, хушлаштык та, китеп бардык. Менә, Ташкичне кабат күреп китәргә насыйп булды. Чишмәсенең суын эчтем. Шулай ук татлы икән. Инешенең челтерәвен тыңладым. Шулай ук моңлы икән. Урамнарыннан уздым. Йортны эзләп таптым. Мичен сүткәннәр, газ керткәннәр. Тормышлар яңара тора. Утыз ел узган бит инде... Ә күп нәрсәләр искечә, хәтердәгечә калган. Бу минем яшьлеккә сәяхәтем кебек, югыйсә! Шигъри яшьлегемә!..

Сеҗе авылына кичке якта килеп җиттек. Мәчетләренә кереп намаз укыгач, имамнары Илдар Әһлиуллин белән китапханәләрен карадык. Арада иске басма китаплар да бар булып чыкты. Аларның беришләре – төрле догалыклар, икенчеләре – Коръән һәм тәфсирләр. Әхмәт Яссәвинең «Дивание-хикмәт»е, шулай ук «Бакырган китабы»ның өлешләре саклана икән. Авылда, кешеләр кулында, гарәп графикасындагы китаплар калмаган. «Андыйларны укый алмагач, сакламыйбыз инде», – дип җавап бирделәр.

Элек бу авылда удмуртлар яшәгән икән. Зиратлары да булган. Аның чыршыларын кискәннәр. Әйтүләренә караганда, удмуртларда «Сеҗе» сүзе «солы» дигән сүз икән. «Ташкичләр – арлар иде. Әни аларны «марилар» дия иде», – дип аңлатты Илдар хәзрәт. Элек мал врачы булганлыгын сөйләп алды.

Сеҗедән Гөберчәк авылына китеп, Мөхәммәт Мәһдиев музеена кердек. Элекләрне монда килгәнем бар иде. Музей ачылуда да катнаштым. Ул вакытта колхозлары бар иде әле, рәисләре Фәрит исемле кеше иде. Шуларны да сөйләшеп алдык. Музейлары булгач, авылларын карап, чиста тоталар икән. Мөхәммәт аганың бөек хыялы бар иде, ул да тормышка ашты: Гөберчәккә асфальт юл илтә.

*Фәрит Яхин, профессор,*

*филология фәннәре докторы*

# Ураза

## Уразаның әһәмияте

Рамазан аенда ураза тоту Ислам диненең өченче нигезе булып тора. Ураза тоту Һиҗрәтнең[1] икенче елыннан башлап фарыз булган.

Ураза тоту – таң атканнан алып кояш баеганчыга тикле ашау-эчүдән һәм җенси якынлыктан тыелып торуны аңлата.

Рамазан аендагы көннәр санына бәйле рәвештә ураза кайвакытта 29 көн, кайбер елларда 30 көн дәвам итә. Мөхәммәд Пәйгамбәр ﷺ үз гомерендә тугыз тапкыр ураза тотарга өлгергән, шуларның дүртесе 29 көн, ә бишесе 30 көн дәвам иткән.

Мөселманнар Рамазан аен изге ай дип хөрмәт итәләр. Нәкъ менә шушы айда Мөхәммәдкә ﷺ пәйгамбәрлек иңдерелгән һәм шуның белән Ислам диненең яңарышы башланган. Коръән дә шул изге вакытта иңдерелә башлаган. Мең айдан хәерлерәк булган Кадер кичәсе Рамазанга туры килә.

Әлеге айда мөэминнәр уразаларын тоталар. Ураза кешеләрне гөнаһлардан арындыра, явыз теләкләрдән һәм яман гамәлләрдән аларны тыеп кала. Аллаһы Тәгалә әмер иткән: **«Әй иман китергәннәр! Ураза элеккеләргә фарыз ителгән кебек, фарыз булды сезгә дә. Бәлки куркырсыз инде!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

**«Хактыр, Рамазан аенда иңдерелгәндер Коръән, туры юлны күрсәткән ачык дәлилләр белән. Бу айга ирешкән һәркем ураза тотсын».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

---

[1] Хиҗрәт – Пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ 622 елны Мәккәдән Мәдинәгә күчеп килү елы. Мөселманнар шул елдан башлап ел исәбен алып баралар.

Ураза тоту, иң әһәмиятле гыйбадәт төрләреннән берсе булып тора. Дөньяда чакта ул безне яман эшләрдән саклый. Ә Кыямәт көнендә Аллаһның гөнаһларыбызны ярлыкавына сәбәпче була, Җәһәннәмнән коткара. Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ шуны әйткән: «Изге Рамазан аен кешеләр кирәгенчә бәяли алсалар, аның бөтен ел буе дәвам итүен теләр иде»[1].

«Рамазан аеның башы – рәхмәттер, уртасы – мәгъфи-рәттер, ахыры – Җәһәннәмнән коткарадыр кешене...»[2].

## Уразаның файдасы

1. Ураза тоту әхлак нигезләрен ныгыта.

Ураза тоту Аллаһны исебезгә төшерә. Җаваплылык хисен арттыра, әдәплелек тәрбияли. Күңелләрне түбән хисләрдән һәм уйлардан арындыра, хуш күрелмәгән эшләрдән һәм кешеләргә карата начар мөгамәләдә булудан тыеп кала.

Ураза күзләребезне хәрамга караудан саклый, телебезне – ялганнан һәм хәерсез сүзләрдән, колакларыбызны – гайбәттән, карыныбызны – хәрам ризыктан, кулларыбызны – яман эшләрдән һәм аякларыбызны – хәрам артыннан чабудан саклый.

Гыйбадәт кылуның хикмәте – Аллаһ ризалыгы өчен кушканнарын үтәүдән һәм гөнаһлы эшләрдән саклanудан гыйбарәт.

2. Ураза тоту кешедә рәхим-шәфкатьлелек хисен уята.

Ачлык белән хәерчелекнең ни икәнен белмәгән кеше, якыннарының бәласен һич аңламас. Ураза тотучы исә кызгануга сәләтле, фәкыйрьгә ярдәм кулын сузарга әзер була, бәлаләрдән котылырга ярдәм итә.

1 Имам Ибне Хөзәймә, «Сахих», III, 190
2 Имам Ибне Хөзәймә, «Сахих», III, 191

3. Ураза кешегә Аллаһ биргән нигъмәтләрнең кадерен белергә ярдәм итә.

Нәрсәнең дә булса кадерен кеше югалткач кына белә. Ураза тотучы үзен Раббысының күп нигъмәтләреннән тыеп торгач, аларның кадерен яхшырак аңлый, аларны сакларга өйрәнә һәм Аллаһы Тәгаләгә биргән нигъмәтләре өчен күбрәк шөкер итә.

4. Ураза тоту кешене сәламәтләндерә.

Пәйгамбәребез ﷺ әйткән: «Ураза тотыгыз – сәламәтлеккә ирешерсез»[1].

Ураза тоту аркасында, 11 ай буе туктаусыз эшләгән аш эшкәртү әгъзалары ял итәләр һәм Рамазан ае беткәч, алар үз вазифаларын активрак башкара.

Ураза тотуның кеше организмы өчен файдалы булуын галимнәр исбатлаган. Танылган француз галиме, Нобель премиясе лауреаты, доктор Алексис Каррельнең фикеренчә, ураза вакытында организмнан анда җыелган таркалу продуктлары чыгарыла, кеше тәне бер яңарыш кичерә.

5. Ураза тоту кешене сабырлыкка өйрәтә.

Үз-үзен озак вакыт ашамый-эчми торырга күнектергән кеше, тормыш аңа хәзерләгән авырлыкларны җиңеп чыгарга әзер, бәла-казалар килгәндә түзәргә дә сәләтле, кирәк булса дошманнарга каршы торырга да көченнән килә. Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ әйткән: «Ураза – сабырлыкның яртысы»[2].

Ураза тоту мөэминнең гөнаһлары кичерелүгә сәбәп була.

Коръәни Кәримдә әйтелгән: **«...уразасын да тотка-нирләргә, хатыннарга, намусларын саклаган ирләр белән гыйффәтләрен сакла-**

1 Имам Әҗлүни «Кәшфуль-хафә», II том, 33 б

2 Имам Тирмизи, «Дәгъват», 86

**ган хатыннарга, Аллаһны еш зикер иткән ирләргә, хатыннарга ярлыкау һәм бөек әҗер әзерләп куйган Аллаһ».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:35

Мөхәммәд Пәйгамбәр ﷺ әйткән: «Кем иманлы булган хәлдә, әҗерен Аллаһтан өмет итеп, Рамазан уразасын тота икән, шуның бөтен элекке гөнаһлары гафу ителер»[1].

6. Ураза тоту Җәннәткә керүгә сәбәп була.

Мөхәммәд Пәйгамбәр ﷺ әйткән: «Хактыр ки, Җәннәтнең Әр-Райян дигән капкасы бар. Кыямәт көнендә бу капкадан ураза тотучылар керәчәк. Һәм әлеге капкадан алардан бүтән беркем дә кермәячәк. Әйтелер: «Ураза тотканнар кайда?». Һәм алар калкачак. Һәм әлеге капкадан алардан бүтән беркем дә кермәячәк. Алар анда кергәч, бу капка ябылачак һәм инде башка беркем аның аша кермәячәк»[2].

7. Кыямәт көнендә ураза шәфәгатьче булачак.

Мөхәммәд Пәйгамбәр ﷺ әйткән: «Ураза белән Коръән кыяматтә кол өчен шәфәгатьчелек кылыр. Һәм ураза әйтәчәк: «Әй Раббым минем! Мин аңа ашарга рөхсәт бирмәдем, нәфсенең теләкләренә каршы килдем. Шәфәгатемне кабул кыл!» Коръән әйтер: «Мин аның төнге йокыларына комачаулык күрсәттем. Кабул итче минем шәфәгатемне!» Аларның икесе дә (әлеге кол өчен дип) шәфәгатьчелек итәр»[3].

8. Аллаһы Тәгалә ураза тотучының догасын кабул итә.

Шул сәбәптән, ураза тоткан мөселман күп тапкыр Аллаһтан үзе өчен дөньяда һәм ахирәттә бәхетләр һәм котылыш, Ислам һәм мөселманнар өчен күп яхшылыклар сорарга тиеш була. Сөекле Пәйгамбәребез

1 Имам Бохари, «Имам»,28; «Саум»,6; имам Мөслим, «Сыям», 203

2 Имам Бохари, «Саум», 4; имам Мөслим, «Сыям», 166

3 Имам Әхмәд ибне Хәнбәл, «Мөснәд», II, 174

Мөхәммәд ﷺ шуны әйткән: «Өчәүнең догасы кире кагылмас: гаделл җитәкченең, авыз ачканга кадәр ураза тотучының, һәм золым күрүченең»[1].

«Ураза тотучының ифтар вакытындагы догасы һич тә кире кагылмас»[2].

## Уразаның төрләре

Алты төрле ураза бар.

1. Фарыз ураза. Боларга Рамазан ае уразасы, аны тотмаган өчен бүтән айларда каза итеп тотылган ураза, һәм шулай ук кәффарәт уразасы керә.

2. Вәҗиб ураза. Боларга нәзер уразасы[3] һәм нәфел уразаны калдырган өчен тотылган каза уразасы керә.

3. Сөннәт ураза. Мәсәлән: мөхәррәм аеның тугызынчы һәм унынчы көннәрендә яисә шул ук айның унынчы һәм унберенче көннәрендә тотыла торган ураза.

4. Мөстәхәб ураза. Мөхәммәд Пәйгамбәр ﷺ: «Уразаның иң мактаулысы – Давыт пәйгамбәр ﷺ тоткан ураза. Давыт ﷺ бер көн ураза тоткан, икенче көнне тотмаган», –дигәч, Габдуллаһ ибне Гомәр әйткән: «Мин күбрәк тота алам». Пәйгамбәр ﷺ җавап биргән: «Моннан да өстенрәге юк»[4]. Мөселман ай календаренең һәр аеның 13, 14, 15 нче көннәрендә, һәр атнаның дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә тотылган уразалар, һәм шулай ук Рамазан аеннан соң шәүвәл аенда алты көн, зөлхиҗҗә аеның элекке ун көнендә, шәгъбән аенда тотылган уразалар мөстәхәб уразалар булып санала.

5. Мәкруһ ураза. Мәсәлән, бер генә көн – мөхәррәм аеның унынчы көнендә, җомга көнендә генә, яки шимбә көнне генә, яки якшәмбе көнне

[1] Имам Ибне Мәҗә, I, 557 б., №1752

[2] Имам Ибне Мәҗә, I, 557 б., №1753

[3] Нәзер – Аллаһка бирелгән вәгъдә

[4] Имам Мөслим, «Сыям», 192, 203; имам Ибне Мәҗә, «Сыям», 43

генә тотылган ураза (пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә, яки җомга һәм шимбә көннәрендә, яки шимбә һәм якшәмбе көннәрендә тотарга була).

6. Тыелган ураза. Рамазан бәйрәмендә һәм Корбан бәйрәменең дүрт көнендә тотылган ураза, яки 2-3 көн буе авыз ачмый тотылган ураза.

## Рамазан аенда ураза тоту кемнәргә фарыз

Ураза тотуның шартлары:

1. мөселман булырга;
2. үз акылында булырга;
3. балигъ булырга.

Үз акылында булган һәм балигълык яшенә җиткән һәр мөселман ир, һәрбер мөслимә хатын Рамазан аенда ураза тотарга бурычлы. Бу – Аллаһның катгый әмере.

Балигълык яшенә җитмәгән балага ураза тоту мәҗбүри түгел. Ләкин шул ук вакытта, баланы кече яшьтән ураза тотарга күнектерсәң яхшырак, әмма моны эшләгәндә баланың физик үсешенә зыян китермәскә кирәк.

Хатыннар хәез көннәрендә һәм бала тапканнан соң чистарыну көннәрендә ураза тотмыйлар, ләкин бу көннәр узгач, калдырган ураза көннәрен каза итеп тутырырга тиеш булалар.

## Уразаны Рамазан аеннан кичектереп бүтән вакытта тотарга рөхсәт биргән сәбәпләр

Мөһим сәбәп булмый торып Рамазан аенда ураза тотмау – гөнаһ. Аның өчен җәза тиешле (Аллаһ Тәгалә гафу кылмаса).

Түбәндәге сәбәпләр аркасында уразаны тотмаска рөхсәт ителә:

1. Авырган вакытта. Әгәр авырту кеше ураза тоту аркасында авыруы көчәер дип яисә озаккарак сузылыр дип курка икән, аңа уразасын туктатырга рөхсәт ителә. Тазарганнан соң, ул уразаның төшереп калдырган көннәре өчен каза уразасы тотарга тиеш була.

2. Сәфәрдә булганда. Рамазан аенда озын сәфәргә чыккан кешегә (өеннән кимендә 100 км китеп) уразасын тотмаска була. Сәфәрдән кайткач, ул кеше юлда чакта ураза тотмаган көннәр өчен каза уразасын тотарга бурычлы.

Фәкать, юлда вакытта уразасын тотарга аңа берни дә комачауламаса, уразаны үз вакытында тотуы хәерлерәк.

3. Ураза тотмаска көчләп мәҗбүр ителгәндә. Әгәр ураза тотучыга, ураза тотма дип, үлем яки имгәтү белән янасалар, ул кешенең уразасын туктатырга хакы бар. Әмма соңыннан бу кеше ураза тотмаган көннәр өчен каза уразасы тотарга бурычлы була.

4. Йөкле вакытта һәм бала имезгәндә. Әгәр хатын балага йөкле вакытта яки күкрәк белән бала имезгәндә ашау-эчүдән тыелып тору үзенең яки сабыйның сәламәтлегенә зарар китерер, дип курка икән, аңа ураза тотмаска рөхсәт ителә. Баласын имезүдән туктагач, ул хатын тотмаган уразалары өчен каза уразалары тотарга тиеш була.

5. Ачыгуга һәм сусауга түзәрлек булмаганда. Әгәр ураза тотучы, шул тикле нык ачыгу һәм сусау тойганлыктан аңымны җуярмын, яисә сәламәтлегемә нык зарар килер, дип курыкса, уразасын боза ала, ә соңыннан каза итеп тотарга тиеш була. Коръәндә әйтелгән: **«Белә торып үзегезне үз кулларыгыз белән һәлакәткә илтмәгез».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:195

**«Үзегезне үтермәгез, чөнки Аллаһ сезнең өчен рәхимледер, һичшиксез».**

«Нисә / Хатыннар», 4:29

6. Картлык сәбәпле. Ураза тотарлык хәле булмаган бик олы яшьтәге кешеләргә ураза тотмаска рөхсәт ителә. Каза уразасын да тота алмаганлыктан, бу кешеләр уразаның төшереп калдырган һәр көне өчен фидия түләргә бурычлы.

## Уразаның нияте

Ураза тотуның төп шартларыннан берсе – ниятләү. Ниятсез тотылган ураза кабул булмый.

Кичтән алып таң атканчыга тикле теләсә кайсы вакытта ураза тотар өчен ният итәргә була.

Әмма ният итәр өчен иң яхшы булган вакыт – сәхәр ашаганнан соң. Фәкать, әгәр дә кеше сәхәргә уянмаса, йокысыннан соңрак торса, ул имсак[1] вакытыннан соң да ният итә ала, кояш инде чыккан булса да. Ләкин көн уртасына тикле ният итәргә өлгерергә кирәк. Иң мөһиме, имсак вакыты кергәннән соң уразаны боза торган эшләрне эшләмәскә.

Сәхәргә торырга җыенмаган кеше, иртәгесе көн ураза тотар өчен кичтән үк ният итә ала.

Рамазан аенда ураза тотылмаган очракта, уразаны бүтән айларда каза итеп тотарга кирәк. Бу очракта да ниятне кояш баегач кылырга була, әмма таң атканчы өлгерү зарури. Каза ураза өчен һәм кәффарәт ураза өчен ниятне соңарып кылырга ярамый. Бу очракта имсак вакытыннан соң ният ителми.

Ният итү күңел белән башкарыла. Моның мәгънәсе шул: киләсе көнне ураза тотарга күңеленнән теләк белдергән кеше ният иткән булып санала. Шулай ук сәхәргә торган кеше дә ният иткән булып санала. Ураза тотарга теләгән кеше үз ниятен эчтән генә дә, тавыш белән дә әйтә ала: «Аллаһ ризалыгы өчен, ихлас күңелдән иртәгесе көннең Рамазан ае уразасын тотарга ният иттем». Гарәпчә ният кылу мөстәхәб булыр: **«Нәүәйтү ән әсуумә саумә шәһри рамәдаанә минәл-фәҗри иләл-мәгъриби хаалисан лилләәһи тәгааләә».**

---

1 Имсак – иртәнге сәхәрнең тәмам булган вакыты

## Сәхәр һәм ифтар

Ифтар – ураза тоткан көнне кич белән авыз ачу, ә сәхәр – ураза тотасы көнне таң атканчыга кадәр ашап-эчеп алу. Таң атканчы йокыдан торып сәхәр ашау мөстәхәб булып санала.

Изге Коръәндә әйтелгән: **«Ашагыз һәм эчегез, иртә белән яктырып, ак җепне кара җептән аерганчыга кадәр, аннары ураза тотыгыз, төн җиткәнчегә кадәр».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:187

Сәхәрне кичтән түгел, ә нәкъ менә таң атуның беренче билгеләре күренә башлар алдыннан ашасаң яхшы була, чөнки бу очракта аның савабы күбрәк. Расүлүллаһ ﷺ әйткән: «Сәхәрдә ашагыз һәм, шул рәвешле, ураза тотар өчен үзегезне ныгытыгыз. Көндез йоклап алыгыз – бу сезгә төнлә белән тәһәҗҗүд намазына торырга ярдәм итәр»[1].

«Таң атканчы ашагыз, чөнки монда бәрәкәт бар»[2].

Бохаринең «Сахихенә» ясаган шәрхында Ибне Нәҗәр сәхәрнең бәрәкәтле булуының түбәндәге билгеләрен санап чыккан:

1. Сәхәр – сөннәт гамәлләрнең берсе.

2. Без сәхәр ашавыбыз белән китап әһелләреннән аерылып торабыз. Безгә бит һәрвакыт алардан аерылып торырлык итеп гамәл кылу тиешле.

3. Сәхәр безгә гыйбадәт кылыр өчен көч бирә.

4. Сәхәр безнең гыйбадәттәге ихласлыкны арттыра, чөнки иртүк тамак ялгап алганлыктан, без ач булуны ул тикле авыр кичермибез һәм бик нык хәлсезләнмибез. Шулай булмаганда, болар безне игелекле эшләрдән читкә этәрер иде.

5. Сәхәр безгә нәфесебезне нык күзәтергә ярдәм итә, чөнки ачулы булу еш кына бик нык ачыгудан килә.

1 Имам Ибне Мәҗә, «Сыям», 22

2 Имам Бохари, «Саум», 20; имам Мөслим, «Сыям», 45

6. Сәхәр вакытында укылган дога кабул ителә.

7. Йокыдан сәхәргә торгач, без тәһәҗҗүд намазын укый алабыз, зикер белән шөгыльләнер өчен мөмкинчелегебез туа.

Ураза тотар алдыннан түбәндәге сүзләрне (гарәпчә) укып, тел белән ният кылу мөстәхәб санала:

نَوَيْتُ أَنْ أَصُومَ صَوْمَ شَهْرَ رَمَضَانَ مِنَ الْفَجْرِ إِلَى الْمَغْرِبِ خَالِصًا لِلّٰهِ تَعَالَى

**Нәвәйтү ән әсуумә саумә шәһри рамадаанә минәл-фәҗри иләл-мәгриби хаалисан лилләәһи тәгаалəә**

«Аллаһы Тәгалә өчен, ихласлык белән таң вакытыннан башлап, кояш батканчыга кадәр Рамазан уразасын тотарга ният кылдым».

Исламның бөек галимнәре болай дигәннәр: «Кем Рамазан аенда, ашарга рөхсәт ителгән сәгатьләрдә бераз ач калса, шул бөтен ел буена, киләсе Рамазанга кадәр шайтанның яманлыгыннан сакланган хәлдә була».

Үз көнен гыйбадәттә, ураза тотып үткәргән мөэмин кешегә ифтар берни белән чагыштырып булмаслык шатлык, ахирәттә әҗер-савап китерә. Мөхәммәд Пәйгамбәр ﷺ әйткән: «Ураза тоткан мөселман өчен ике төрле шатлык бар: берсе – ифтар вакытында, икенчесе – Аллаһның хозурына килеп баскан вакытта»[1].

«Ураза тотучыны ашаткан кеше алачак савап ураза тотучының савабына тиң була, әмма аның савабын да һич кенә дә киметми»[2].

«Берегез ифтар кылса, хөрмә белән авыз ачсын, чөнки анда бәрәкәт бар. Инде хөрмә тапмасагыз, су белән авыз ачыгыз, чөнки ул чиста була»[3].

1 Имам Бохари, «Саум», 9; имам Мөслим «Сыям»,163

2 Имам Тирмизи, «Саум», 81

3 Имам Тирмизи «Зәкәт», 26; имам Әбү Давыт «Саум», 21

Ифтар вакытында авыз ачканда укыла торган дога:

اَللَّهُمَّ لَكَ صُمْتُ وَبِكَ آمَنْتُ وَعَلَيْكَ تَوَكَّلْتُ وَعَلَى رِزْقِكَ أَفْطَرْتُ فَاغْفِرْ لِي يَا غَفَّارُ مَا قَدَّمْتُ وَمَا أَخَّرْتُ

**Әллааһүммә ләкә сумтү вә бикә әмәнтү вә галәйкә тәвәккәлтү вә галәә ризкыйкә әфтартү фәгъфирлии йәә гаффәәрү мәә каддәмтү вә мәә әххартү.**

«Аллаһым, шушы уразамны Синең өчен тоттым, Сиңа гына иман китердем һәм Сиңа тәвәккәл иттем. Синең ризалыгың белән авыз ачам. Әй гөнаһларны гафу итүче Аллаһым, минем әүвәлге гөнаһларымны да, соңгы гөнаһларымны да ярлыка».

## Уразаны бозмый торган хәлләр

Онытканлык белән ашау-эчү (җенси якынлык кылу). Әгәр кеше үзенең ураза тотканлыгын исенә төшерү белән ашау-эчүне туктатып, авызына капкан ризыкны чайкап чыгарса, уразасы дәвам итә. Әгәр ураза тотканын исенә төшергәннән соң капкан ризыгын йотып җибәрергә өлгерсә, уразасы бозыла. Түбәндәге хәлләр уразаны бозмый:

1. Колакка су эләгү.
2. Күзгә дару тамызу.
3. Ураза тоткан вакытта су коену.
4. Үзең махсус косарга теләмәгәндә косып җибәрү.
5. Йоклаганда үзлегеннән мәни чыгу (поллюция).
6. Кан бирү.
7. Ялгыш кына тамакка тузан яки төтен эләгү.
8. Төкерекне йоту.

## Ураза вакытында эшләнүе мәкруһ булган гамәлләр

1. Нәрсәнең дә булса тәмен татып карау (йотмыйча гына).

2. Авызга тулган төкерекне йотып җибәрү.

3. Кешене хәлсезләтерлек дәрәҗәдә күп тапкыр кан бирү.

4. Интектергеч эш.

## Ураза вакытында эшләнүе мәкруһ булмаган эшләр

Шуларны эшләү тыелмый:

1. Ислемай иснәү яки куллану.

2. Мисвәк яки теш щеткасы кулланып теш чистарту.

3. Авызны чайкау.

4. Борын эчен чайкау.

5. Юыну.

## Уразаны боза торган, әмма каза уразасын гына таләп итә торган хәлләр

1. Ашарга яраксыз нәрсәләрне йоту (кәгазь, туфрак, мамык кебек).

2. Борынга дару тамызу.

3. Суны очраклы рәвештә йоту, мәсәлән, авызны яки борынны чайкаганда.

4. Авызда тупланган төкерекне йотканда, аңа катнашкан чит нәрсәләрне дә йоту.

5. Уразаны бозарга мәҗбүр булганда.

6. Йоклаган кешенең тамагына башка берәү су агызганда.

7. Үз-үзеңне мәҗбүр итеп коскан чакта авызны тутырып косу.

8. Ялгышып, вакытыннан алда авыз ачу (ахшам намазының вакыты керде дип уйлап).

9. Сәхәр вакыты чыкканнан соң ялгышлык белән ризык ашау (әле таң атмады дип уйлап).

## Уразаны боза торган һәм каза уразасы белән кәффарәтне үтәүне таләп итә торган хәлләр

Әгәр Рамазан аенда ураза тоткан кеше шул эшләрнең берәрсен белә торып һәм гозерсез эшли калса:

– ашаса, эчсә яки дару капса (таблетка яки сыеклык);

– җенси якынлык кылса;

– тәмәке тартса,

аңа бозылган уразасын каза итеп, көнен көнгә тутырып тотарга кирәк була һәм ул кәффарәт үтәргә тиеш. Кәффарәт – Рамазан ае уразасын белә торып бозган өчен бу дөньяда бирелгән җәза. Рамазан ае уразасыннан тыш башка уразаларны бозган өчен кәффарәт үтәлми.

Кәффарәт рәттән 60 көн ураза тотудан тора. Әгәр кәффарәт өзелсә, яңабаштан 60 көнлек ураза тотарга кирәк. Кәффарәт уразасы тоткан хатыннар хәез көннәрендә аны туктатып торалар һәм бу көннәр тәмамлангач, яңадан дәвам иттерәләр.

Кемнәр җитди сәбәп белән 60 көнлек уразаны тота алмый икән, 60 фәкыйрь мөселманның тамагын туйдырырга (иртәнге һәм кичке аш ашатырга) тиешләр (тәкъвалы мөселманнарны тапсаң яхшырак була). Динсез кешеләргә кәффарәт бирелми. Ризык җитәрлек күләмдә һәм сыйфатлы булырга тиеш (мәсәлән, бодай икмәге). Бер фәкыйрьгә 120 тапкыр иртәнге аш яисә кичке ашны ашатырга мөмкин. Яисә 60 кешегә иртәнге аш, 60 кешегә кичке ашны ашатсаң ярый.

Бирелергә тиешле ризыкның бәясен акчалата бирергә дә була. Бер фәкыйрьгә 60 көн буе яисә 60 кешегә бер көндә бирсәң була. Әгәр бөтен сумманы бер көндә бер кешегә генә бирсәң, бер көнлек кәффарәт кенә булып санала.

Әгәр кеше бер Рамазан аенда берничә тапкыр уразасын белә торып бозса (яки берничә Рамазан аенда уразасын белә торып бозса), бөтен очраклар өчен бер кәффарәт бирсә җитә.

Әбү Һөрәйрә ﵁ тапшырган: «(Бервакытны) без Пәйгам-бәр белән бергә утырганда, аның янына ниндидер бер кеше килеп шуны әйтте:

– Әй Аллаһның Расүле! Һәлак булдым мин!

– Ни булды сиңа? – дип Пәйгамбәр ﷺ сорады.

– Мин ураза вакытында хатыным белән якынлык кылдым.

– Азатлыкка чыгарыр өчен колларың бармы синең?

– Юк.

– Ике ай буе рәттән ураза тота аласыңмы?

– Юк.

– Алтмыш фәкыйрьнең тамагын туйдыра аласыңмы?

– Юк.

Әбү Һөрәйрә ﵁ әйтте: «Шуннан соң Пәйгамбәр ﷺ бераз вакыт тын калды. Без шул хәлдә булган чакта, Пәйгамбәргә бер кәрзин тулы хөрмә китерделәр. Ул сорады: «Сорау биргән кеше кайда?

– Мин монда, – дип җавап бирде.

Шуннан соң Пәйгамбәр ﷺ әйтте:

– Ал боларны һәм сәдака итеп тарат.

Теге кеше әйтте:

– Мин боларны үземнән фәкыйрьрәк кешеләргә өләшергә тиешме, әй Аллаһның Расүле? Аллаһ белән ант итәмен, Мәдинә шәһәрендә минем гаиләмнән дә фәкыйрьрәк гаилә юк.

Шуннан соң Пәйгамбәр ﷺ тешләре күренерлек итеп елмайды, аннары соң болай диде:

– Бар, бу хөрмәләр белән үз гаиләңне туендыр».

## Игътикаф

Игътикаф – Раббыбызга гыйбадәт кылу нияте белән билгеле бер вакытка мәчеттә яки башка берәр урында калу.

Әбү Хәнифә мәзһәбе буенчә, 3 төрле игътикаф була:

1. Вәҗиб игътикаф. Мәсәлән, бер кеше, Аллаһ аның нинди дә булса тәгаен теләген үтәсә, фәлән көн игътикафта калачакмын, дип, Аллаһы Тәгаләгә ант итсә. Бу очракта, аның әлеге теләге кабул булган вакыттан алып, игътикаф аның өчен вәҗиб була. Я булмаса бер кеше, төгәл шартын куймыйча, билгеле көннәр санында игътикафта калырмын дип ант итеп, игътикафны үзе өчен вәҗиб итә.

2. Сөннәт игътикаф Рамазан аеның соңгы 10 көнендә башкарыла.

3. Нәфел игътикаф. Игътикафның бу төре өчен махсус вакыт яки билгеләнгән көннәр саны юк. Кеше үзе теләгән кадәр көнгә игътикафта калырга ният итә ала, хәтта бөтен гомере буена.

Әбү Хәнифә мәзһәбе буенча, игътикафның дәвамлыгы бер көннән дә азрак булмаска тиеш. Игътикаф өчен бик зур савап языла, аның файдасы һәм бәрәкәте санап бетергесез.

Игътикафта булыр өчен иң хәерле урын – Мәккәдәге Әл-Хәрам мәчете, аннан кала – Мәдинәдәге Ән-Нәби мәчете, ә аннан соң – Кодыстагы Бәйтүл-Мөкаддәс.

Үз шәһәреңдәге җәмигъ мәчет дәрәҗәсе ягыннан алар артыннан килә, һәм иң соңыннан – өеңә иң якын булган мәчет. Югарыда санап кителгәннәрнең барысы ир-атлар өчен генә. Хатыннар исә игътикафны, кайбер галимнәрнең фикеренчә, өйләрендә дә үткәрә ала, әмма моның өчен бүлеп бирелгән махсус урын булырга тиеш. Шул рәвешле, монысы хатыннар өчен эшләнгән бер кулайлык.

Әгәр Аллаһы Тәгаләнең әлеге бөек бүләген тиешенчә бәяли алсак, әлбәттә, без игътикафта калыр өчен көчебездән килгәннәрнең барысын да эшләр идек. Гомерендә тагын ничә Рамазан аен каршы алачагын бере-

без дә белә алмый. Бәлки нәкъ менә бу Рамазан безнең өчен соңгысыдыр, ә аннан соң – дөньяда бөтен кылганнарың өчен хисап бирү вакыты!

Аллаһның Расүле ﷺ әйткән: «Кадер кичәсен Рамазанның соңгы ун төнендәге так төннәр арасыннан эзлә»[1].

«Рамазан ае җиткәч, күк капкалары ачыла, Җәһәннәм капкалары ябыла, чылбырлар белән шайтаннар богауланып куела»[2].

## Фидия

Ураза тотарлык хәле булмаган озак авырган кешеләр һәм бик олы яшьтәге кешеләр уразаның төшереп калдырылган һәр көне өчен фидия түлиләр.

Фидиянең күләме нәкъ фитр сәдакасы шикелле хисаплана. Фидияне Рамазан аеның башында да, уртасында һәм ахырында да бирергә була.

Фидияне үзең теләгәнчә бер генә фәкыйрь кешегә бирергә яисә берничә кешегә таратырга да мөмкин.

Әгәр мөселман кешенең фидия өләшергә көченнән килми икән, ул вакытта Аллаһтан гафу теләргә тиеш.

Әгәр озак авырган кеше инде тазарса, яисә карт кешегә уразасын тотарлык көч-хәл керсә, алар калдырган көннәре өчен уразаны каза итеп тотарга бурычлы. Әлеге очракта бирелгән фидияләре сәдака булып санала.

## Фитр сәдакасы

Бәйрәм көне җиткәндә бурычлары булмаган һәм нисабка ия булган мөселман кеше өчен фитр сәдакасын бирү вәҗиб булып санала. Фитр сәдакасы бирер өчен мал-мөлкәткә тулы ел буе хуҗа булырга яки арта барган мал-мөлкәт булырга тиеш дигән шарт куелмый.

---

1 Имам Бохари «Ләйләтүл-Кадр» 3

2 Имам Бохари «Саум» 5; имам Мөслим «Сыям» 1, 2, 4, 5

Фитр сәдакасын Рамазан аенда өләшәләр, моның өчен иң хәерле вакыт – Рамазан бәйрәме көнне бәйрәм намазына кадәр. Шулай ук аны бөтен бәйрәм көне дәвамында бирсәң дә була. Хәлле мөселман өчен фитр сәдакасын үзе өчен дә, балигъ булган балалары өчен дә бирү вәҗиб. Гадәттә фитр сәдакасы итеп түбәндәге азык-төлек төрләренең берәрсе билгеле бер күләмдә бирелә:

1. Бодай – 1,6 кг.
2. Солы – 3,2 кг.
3. Йөзем – 3,2 кг.
4. Хөрмә – 3,2 кг.

Фитр сәдакасын азык-төлек белән дә, шуның бәясе кадәр итеп акчалата да бирергә була. Мохтаҗ кешегә күбрәк файда китерә торган нәрсәне сәдака итеп бирсәң хәерлерәк. Фитр сәдакасы бүлеп өләшенми, күләме зур булмавы сәбәпле аны бары тик бер кешегә бирәләр. Бер фәкыйрьгә бердән артык фитр сәдакасы бирергә була. Фитр сәдакасын биргәндә аның бирүең турында ният ителә һәм ишетелерлек итеп әйтү шарт түгел.

Нисаб микъдарында мал-мөлкәте яки акчасы булган һәм Рамазан аенда ураза тотмаган кеше шулай ук фитр сәдакасы бирергә тиеш була.

Бәйрәм көнендә фитр сәдакасы таратып, бай мөселманнар фәкыйрьләрне сөендерә. Фитр сәдакасын бирү, мөэминнең тоткан уразасы кабул ителүгә сәбәп була, аны газаплы үлемнән һәм кабер газабыннан коткара.

## Рамазан аенда җитди сәбәпсез уразасын калдырган кешенең хәле

Рамазан аенда ураза тоту – динебезнең катгый әмере. Барлык мөселманнар да аны үтәргә бурычлы.

Әгәр мөселман кеше, җитди сәбәп булмый торып, Рамазан уразасын тотмый калдырса, көнен көнгә тутырып уразаны каза итеп тотарга тиеш була.

Әгәр мөселман кеше, җитди сәбәп булмый торып, башланган уразасын бозса, ул каза уразасын тоту өстенә кәффарәт тә түләргә мәҗбүр була.

Рамазан аенда, җитди сәбәп булмый торып, ураза тотмаган кеше гөнаһлы булып санала һәм бу гөнаһысы өчен Аллаһ каршында җаваплы була. Ураза тотарга дигән Аллаһ әмерен үтәмәгән кешегә тәүбә итәргә кирәк. Мондый гөнаһ кылган кеше Аллаһтан гафу сорарга һәм вакыт уздырмыйча каза уразасы тотарга, ә кирәк булган очракта, кәффарәт түләргә тиеш.

Расүлүллаһ ﷺ әйткән: «Аллаһ аларга рөхсәт иткән кешеләрдән башка (юлчылар, балага йөкле хатыннар, авырган кешеләр һәм башкалар) әгәр кемдер Рамазанда уразасын боза калса, калган гомере буе гел ураза тотса да, бу көнне тутыра алмас (шул кадәр савап алмас)»[1].

---

1 Имам Бохари, имам Әбү Давыт, «Әт-Тәҗ» II, стр. 68

## Тəравих намазы

Тəравих намазы Рамазан аенда укыла. Ул 20 рəкəгатьтəн тора. Тəравих намазы ирлəр һəм хатыннар өчен сөннəт мүəккəдə булып санала, ураза тотучылар өчен дə, берəр төрле авыру яки сəфəрдə булу сəбəпле ураза тотмаучылар өчен дə. Тəравих намазын мəчеттə уку – сөннəт, аны үтəгəн өчен зур савап вəгъдə ителгəн. Əмма əлеге намазны өйдə берүзең укысаң да ярый.

Мөхəммəд Пəйгамбəр ﷺ əйткəн: «Рамазан аенда, бу айның изге ай икəнлегенə ышанган хəлдə һəм əҗер-савабын бары тик Аллаһтан гына өмет итеп, тəравих намазын кылучыга аның барлык элекке гөнаһлары кичерелə»[1].

«Аллаһ Рамазан аенда ураза тотуны сезнең өчен бурыч иткəн. Ə мин исə аның төнендə кыямда торуны, ягъни тəравих намазын сөннəт иттем. Кем иманлы йөрəк белəн, савап алу телəге белəн Рамазан аенда ураза тотса һəм тəравих намазын укыса, гөнаһлардан котылыр, яңа туган сабый бала сыман булыр»[2].

### Тəравих намазын уку

Тəравих намазын бары тик ястү намазыннан соң гына укырга була. Рамазан аенда витр намазы тəравих намазыннан соң укыла. Əмма витр намазын тəравих намазыннан алда укырга да рөхсəт ителə.

20 рəкəгатьле тəравих намазында сəламне һəр ике рəкəгатьтəн соң яки һəр дүрт рəкəгатьтəн соң бирергə була.

---

1 Имам Бохари, «Иман», 27; имам Мөслим «Мосафирин», 174

2 Имамнар Əхмəд ибне Хəнбəл һəм Нəсəи хəдислəр җыентыгы

## Җәмәгать белән (икешәр рәкәгатьле) тәравих намазын уку

Тәравих намазын ястү намазының фарызыннан һәм сөннәтеннән соң укыйлар.

Имамның нияте: «Аллаһ ризалыгы өчен тәравих намазын имам булып укырга ният иттем». Имам «Аллаһу Әкбәр» дип кулларын берләштереп, кендек астына куя.

Имамга иярүче җәмәгатьнең нияте: «Аллаһ ризалыгы өчен тәравих намазын имамга ияреп укырга ният иттем». Имамның тәкбиреннән соң җәмәгать тә тәкбир әйтә һәм кулларын берләштерә.

Шуннан соң имам белән җәмәгать эчтән генә «Сәнә» догасын укыйлар. Имам эчтән «Әгузү-бисмилләһне» укый, ә җәмәгать бу вакытта берни дә укымый. Аннары соң имам «Фәтихә» сүрәсен һәм Коръәннән тагын бер сүрәне тавыш белән укый. Имам белән җәмәгать рөкүгъ-сәҗдә кылалар һәм шуннан соң икенче рәкәгатькә басалар.

Имам эчтән «Бисмилләһне» укый, аннан соң «Фәтихә» сүрәсен һәм Коръәннән тагын бер сүрәне кыскырып укый. Аннары һәммәсе дә рөкүгъ һәм сәҗдәләр кылалар, соңыннан утыралар.

Утырып торганда имам белән җәмәгать рәттән «Әт-тәхият»не, «Салават», «Раббәнә әтинә» догасын эчтән генә укыйлар. Соңыннан башларын уңга һәм сулга борып, «Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһ» дип сәлам бирәләр.

Югарыда санап кителгән хәрәкәтләр икешәр рәкәгать итеп ун тапкыр кабатлана һәм шул рәвешле рәкәгатьләр саны егермегә җитә. Шуннан соң җәмәгать белән витр намазының 3 рәкәгатен укыйлар.

## Тәравих намазын (икешәр рәкәгать итеп) берүзең уку

Бу намаз иртәнге намазның сөннәте кебек укыла. Бары тик нияте генә башкача: «Аллаһ ризалыгы өчен тәравих намазын укырга ният кылдым». 2 рәкәгатьле намазны 10 тапкыр кабатлыйлар. Шуннан соң витр намазының 3 рәкәгатен укыйлар.

## Тәравих намазын җәмәгать белән (дүртәр рәкәгать итеп) уку

Имамның нияте: «Аллаһ ризалыгы өчен тәравих намазына имам булырга ният кылдым». Имам «Аллаһу Әкбәр» дип, кулларын берләштереп, кендек астына куя.

Имамга ияручe җәмәгатьнең нияте: «Аллаһ ризалыгы өчен тәравих намазын имамга ияреп укырга ният иттем». Имамның тәкбиреннән соң җәмәгать тә тәкбир әйтә һәм кулларын берләштерә.

Шуннан соң имам белән җәмәгать эчтән генә «Сәнә» догасын укыйлар. Имам эчтән «Әгузү-бисмилләһне» укый, җәмәгать бу вакытта берни дә укымый. Аннары соң имам «Фәтихә» сүрәсен һәм Коръәннән тагын бер сүрәне тавыш белән укый. Имам белән җәмәгать рөкүгъ-сәҗдә кылалар һәм шуннан соң икенче рәкәгатькә басалар.

Имам эчтән «Бисмилләһне» укый, аннан соң «Фәтихә» сүрәсен һәм Коръәннән тагын бер сүрәне тавыш белән укый. Аннары һәммәсе дә рөкүгъ һәм сәҗдәләр кылалар, соңыннан утыралар һәм «Әт-тәхият»не укыйлар.

Өченче рәкәгатькә торып баскач, имам эчтән «Бисмилләһне» укый, аннан соң «Фәтихә» сүрәсен һәм Коръәннән тагын бер сүрәне тавыш белән укый. Имам белән җәмәгать рөкүгъ һәм сәҗдәләр кылалар һәм дүртенче рәкәгатькә торып басалар.

Дүртенче рәкәгатьтә имам эчтән «Бисмилләһне» укый, аннан соң «Фәтихә» сүрәсен һәм Коръәннән тагын бер сүрәне тавыш белән укый. Аннары имам белән җәмәгать рөкүгъ һәм сәҗдәләр кылалар, соңыннан утыралар.

Утырып торганда имам белән җәмәгать рәттән «Әт-тәхият»не, «Салават», «Раббәнә әтинә» догасын эчтән генә укыйлар. Соңыннан башларын уңга һәм сулга борып, «Әссәләмү галәйкүм вә Рәхмәтуллаһ» дип сәлам бирәләр.

Югарыда санап кителгән хәрәкәтләр дүртәр рәкәгать итеп биш тапкыр кабатлана һәм шул рәвешле рәкәгатьләр саны егермегә җиткерелә.

Шуннан соң җәмәгать белән витр намазының 3 рәкәгатен укыйлар.

## Тәравих намазын (дүртәр рәкәгать итеп) берүзең уку

Ният: «Аллаһ ризалыгы өчен тәравих намазын укырга ният иттем». Бу намаз иртәнге намазның сөннәте кебек укыла. 4 рәкәгатьле намазны 5 тапкыр кабатлыйлар. Шуннан соң витр намазының 3 рәкәгатен укыйлар.

Пәйгамбәребез ﷺ сәхабәләренең үрнәгендә, һәр дүрт рәкәгатьтән соң, беразга тукталып, Аллаһы Тәгаләне мактаулар сүзләре әйтсәң һәм зикер кылсаң яхшы була, кыска гына вәгазь тыңлап алырга да була.

Аллаһы Тәгаләне шул рәвешле олыларга була, 3 тапкыр кабатларга:

سُبْحَانَ ذِى الْمُلْكِ وَالْمَلَكُوتِ. سُبْحَانَ ذِى الْعِزَّةِ وَالْعَظَمَةِ وَالْقُدْرَةِ وَالْكِبْرِيَآءِ وَالْجَبَرُوتِ. سُبْحَانَ الْمَلِكِ الْحَيِّ الَّذِى لَا يَمُوتُ. سُبُّوحٌ قُدُّوسٌ رَبُّ الْمَلَآئِكَةِ وَالرُّوحِ. لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ نَسْتَغْفِرُ اللهَ. نَسْئَلُكَ الْجَنَّةَ وَنَعُوذُ بِكَ مِنَ النَّارِ.

**Сүбхәәнә ҙил-мүлки үәл-мәләкүүт. Сүбхәәнә ҙил-гиззәти үәл-гәҙамәти үәл-кудурати үәл-кибрийәә’и үәл-җәбәруут. Сүбхәәнәл-мәликил-хәййил-ләҙи лә йәмүүт. Сүббуухүн куддүүсүр-раббүл-мәләә’икәти үәр-**

**руух. Ләә иләәһә ил-ләллааһү нәстәгъфирул-лааһ. Нәс'әлүкәл-Җәннәтә вә нәгүүҙү бикә минән-нәәр**

«Җирдәге һәм күктәге мәхлукатның хуҗасы булган Аллаһы Тәгаләне данлыймын. Көч, кодрәт һәм бик олуглык иясе булган Аллаһы Тәгаләне данлыймын. Бөтен галәмнең патшасы һәм беркайчан үлмәячәк, һәрвакыт терек булучы Аллаһы Тәгаләне данлыймын. Ул Аллаһы Тәгалә бөтен кимчелекләрдән бик пакь һәм мөкатдәс Зат, бөтен фәрештәләрнең һәм Җәбраил фәрештәнең Раббысы. Бер Аллаһы Тәгаләдән башка илаһи зат юк. Без гөнаһларыбызның ярлыкавын сорыйбыз. Йә Рабби, без Синнән Җәннәтне сорыйбыз һәм тәмугътан Сиңа сыгынабыз».

*«Ислам дине нигезләре» китабыннан*

*«Хозур» нәшрият йорты*

# Нәсыйхәт

# Җәмгыять аңында мораль принциплар үзгәрү процессы

## «... мин аларга җирдәгесен бизәп күрсәтермен...»

Хәзерге заманда дөньяда, кызганыч, әхлакый принциплар тискәре үзгәреш кичерә. Кешеләр әкренләп бозыклыкларны уңай күренеш, яхшы мораль сыйфатларны исә тискәре нәрсә итеп кабул итә башлый. Бу хәл җәмгыятьнең әхлакый нигезләрен җимерә. Әлеге күренеш никадәр тизрәк тарала торган булса, шулкадәр кешелек җәмгыяте чын әхлак принципларыннан ераклашачак. Бүгенге көндә бу җәмгыятьнең иң җитди һәм актуаль мәсьәләләреннән берсе булып тора.

Ислам дине буенча бу дөнья – адәм баласы өчен сынау урыныдыр. Шул сынау нәтиҗәләренә карап, кеше йә җәннәткә керәчәк, йә җәһәннәм газабына дучар ителәчәк. Нәтиҗәләрне белер өчен Аллаһы Тәгаләнең Ихтыяры һәм Хикмәте белән дөньяга шайтан җибәрелгән[1]. Коръәндә әйтелгәнчә[2], беренче кеше (Адәм ﷺ) яратылганнан соң, инсан белән иблис арасында аяусыз көрәш башланган һәм ул Кыяматкә кадәр дәвам итәчәк.

Шайтан хәйләсе һәм мәкере хакында Коръәндә болай диелә:

إِنَّ الشَّيْطَانَ لَكُمْ عَدُوٌّ فَاتَّخِذُوهُ عَدُوًّا ۚ إِنَّمَا يَدْعُو حِزْبَهُ لِيَكُونُوا مِنْ أَصْحَابِ السَّعِيرِ ﴿٦﴾

**«Чынлап та, шайтан ул – сезнең дошманыгыз һәм сез аны дошман итеп күрегез. Ул үзенә ияргәннәрне ялкынлы ут эчендә яшәргә чакыра».**

«Мәләикә / Фәрештәләр», 35:6

Башка бер аятьтә түбәндәге сүзләр бар:

1 Шайтан – җеннәрдән берсе.

2 Коръән, 2:36.

**قَالَ رَبِّ بِمَا أَغْوَيْتَنِي لَأُزَيِّنَنَّ لَهُمْ فِي الْأَرْضِ وَلَأُغْوِيَنَّهُمْ أَجْمَعِينَ ﴿٣٩﴾ إِلَّا عِبَادَكَ مِنْهُمُ الْمُخْلَصِينَ ﴿٤٠﴾**

> **«Ул (Иблис) әйтте: «Йа Рабби! Мине саташтырганың өчен мин аларга җирдәгесен бизәп күрсәтермен һәм, әлбәттә, аларны аздырырмын. Синең сайланган (яки самими) колларыңнан башкаларны».**
>
> «Хиҗер», 15:39–40

Ягъни, шайтан кеше кылган гамәлләрне шундый итеп бизәячәк ки, ул кеше яман, гөнаһлы гамәлләрне хәерле итеп, хәерлесен исә яман итеп күрәчәк. Хәзерге заманыбызда җәмгыятьнең билгеле бер өлеше, аеруча яшь буын вәкилләре, Ислам һәм гомумкешелек әхлагы хупламаган эшләрне табигый нәрсә итеп кабул итә, андый эш эшләүдә бернинди яманлык күрми. Әлбәттә, гомумән алганда, кеше яхшыдан яманны аера, аларның асылын аңлый. Әмма әшәке гамәл «матур киемгә» төрелсә, ягъни башка, матуррак исем белән аталса, аның әдәпсезлек (гөнаһлылык) статусы яшерелсә, хәл бөтенләй үзгәрә. Шайтан, кешене юлдан яздырырга теләсә, аңа гөнаһны гөнаһ итеп күрсәтми, аңа икенче сыйфат, башка исем бирә, бизәп куя, бәндәнең күзен шулкадәр пәрдәли ки, ул гөнаһның гөнаһ икәнлеген дә оныта.

Нәкъ шундый хәлне Адәм ﵇[1] белән Һава ﵇ кичерәләр. Риваятьләрдән мәгълүм ки, шайтан аларны Аллаһы Тәгалә тыйган агачның җимешләреннән авыз итәргә котырткан. Һәр кеше үлемнән курка, бу курку кешенең табигатенә салынган. Адәм ﵇ пәйгамбәр булса да, кеше кичерә торган бөтен хис-тойгыларны дә кичергән. Шайтан, шуннан

[1] Адәм пәйгамбәр, башка пәйгамбәрләрнең исемен, шулай ук Һаваның (Библиядә - Ева) һәм кайвакыт Әһле бәйт исемнәре әйтелгәннән соң мөселман әдәбе буенча «галәйһис-сәлам», галәйһас-сәлам», галәйһимәс-сәлам» сүзләре кушып әйтелә.

файдаланып, Адәмгә عليه السلام әлеге агач җимешләрен ашаса, мәңге үлмәячәген вәгъдә иткән.

Коръәндә болай диелә:

فَوَسْوَسَ لَهُمَا الشَّيْطَانُ لِيُبْدِيَ لَهُمَا مَا وُورِيَ عَنْهُمَا مِن سَوْآتِهِمَا وَقَالَ مَا نَهَاكُمَا
رَبُّكُمَا عَنْ هَٰذِهِ الشَّجَرَةِ إِلَّا أَن تَكُونَا مَلَكَيْنِ أَوْ تَكُونَا مِنَ الْخَالِدِينَ ﴿٢٠﴾
وَقَاسَمَهُمَا إِنِّي لَكُمَا لَمِنَ النَّاصِحِينَ ﴿٢١﴾

**«Шайтан аларны (Адәм белән Һаваны) алардан яшеренгән гаурәт җирләрен ачарга вәсвәсәләде. Ул аларга: «Раббыгыз сезгә бу агачны фәрештәгә яки үлемсезгә әйләнмәвегез өчен тыйды», – дип әйтте. Ул аларга болай дип ант итте: «Чынлап та, мин сезгә эчкерсез рәвештә яхшылык теләүчемен».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:20–21

فَوَسْوَسَ إِلَيْهِ الشَّيْطَانُ قَالَ يَا آدَمُ هَلْ أَدُلُّكَ عَلَىٰ شَجَرَةِ الْخُلْدِ وَمُلْكٍ لَّا يَبْلَىٰ
﴿١٢٠﴾

**«Әмма шайтан аны котыртып, болай диде: «Йа Адәм! Сиңа мәңгелек һәм бетмәс-төкәнмәс хакимият агачын күрсәтимме?»**

«Та Һа», 20:120

Коръәндәге бу сүзләр хәзерге дөньяда барган процесслар өчен дә мисал булып тора.

Беренче мисал: Кешене бозык, гөнаһлы эшләрдән тыеп торучы төп сыйфатларның берсе – оялчанлык хисе. Бу хис күркәм әхлак билгесе. Билгеле ки, оятлы кеше рөхсәт ителгән белән тыелганны, яхшы белән яманны бик әйбәт аера, шул рәвешчә, үзен һәрвакыт контроль астында тота. Кешеләрнең иң оятлысы булган Пәйгамбәребез ﷺ оялчанлык сыйфаты-

на бик зур әһәмият биргән һәм бу хакта болай дигән: «Чынлап та, беренче рисаләттән (пәйгамбәр сүзеннән) кешеләргә түбәндәгеләр ирешә: әгәр оят белмәсәң, теләсәң ни эшлә». Бервакыт Пәйгамбәребез ﷺ бер кеше янынннан узып барганда аның бертуганын оятлы булуы өчен тиргәгәнен ишеткән. Пәйгамбәребез туктап, аңа болай дигән: «Тимә аңа, тиргәмә, чөнки оялчанлык диннән килә». Шулай ук бер хәдистә: «Оялчанлыкта хәердән башка нәрсә юк», – дип әйтелә[1].

Кызганыч, хәзерге заманда элекке принциплар югалып, әлеге оялчанлык хисен кешенең кимчелеге, җитешмәгән ягы итеп саный башладылар. Ягъни, оятлы кеше үз көченә ышанмый торган, «җебегән» булып чыга. Оятсызлыкны исә «ирек», үз эчеңә йомылмаганлык билгесе итеп мактап телгә алалар.

Һичшиксез, бу хәлләр әхлакны икенче планга күчерүдән, аңа әһәмият бирмәүдән килә. Коръән аятендә:

قَالَ رَبِّ بِمَا أَغْوَيْتَنِي لَأُزَيِّنَنَّ لَهُمْ فِي الْأَرْضِ وَلَأُغْوِيَنَّهُمْ أَجْمَعِينَ ﴿٣٩﴾ إِلَّا عِبَادَكَ مِنْهُمُ الْمُخْلَصِينَ ﴿٤٠﴾

**«Ул (Иблис) әйтте: ... мин аларга җирдәгесен бизәп күрсәтермен...»** – дип әйтелә.

«Хиҗер», 15:39–40

Югарыда сурәтләнгән күренеш гомуми мораль, тәрбия принципларына тулысы белән каршы килүче стандартларны пропагандалаудан башка нәрсә түгел. Шайтан белән кеше арасындагы баш арадашчы ул – җәмәгатьчелек фикере, икенче төрле әйткәндә, тирә-юньдәгеләр. Алар аерым шәхескә бик көчле йогынты ясый. Кеше күпчелек фикеренә һәм

1 Сборник научных статей (Выпуск 1). Религия и право в поликонфессиональном и полиэтническом обществе. – Казан: Русия ислам институты. Ислам гакыйдәсе кафедрасы. Ислам хокукы кафедрасы, 2010. – Б.141-142.

гамәленә яраклаша башлый, нәтиҗәдә затлы принципларның өстенлеге дә күренми башлый.

Икенче мисал: Ислам күзлегеннән караганда, зина, тәнне ачып гаурәт җирләрне күрсәтү, уйнаш бөек гөнаһлар рәтенә керә. Мондый гөнаһны кылып тәүбә итмәгән кеше Аллаһы Тәгаләнең җәзасын күрәчәк.

Гаурәтне күрсәтү турында Коръәндә болай диелә:

وَلَا يُبْدِينَ زِينَتَهُنَّ ﴿٣١﴾

**«...алар үз зиннәтләрен ачып күрсәтмәсеннәр...»**

«Нур», 24:31

Башка бер аятьтә Аллаһ әйтә:

وَلَا تَقْرَبُوا الزِّنَىٰٓ ۖ إِنَّهُ كَانَ فَاحِشَةً وَسَاءَ سَبِيلًا ﴿٣٢﴾

**«Зина кылмагыз һәм аңа юл бирүче бөтен нәрсәдән сакланыгыз. Чөнки ул – ачыктан-ачык гөнаһ, кабахәтлек һәм әшәке юл».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:32

Бүген зина, уйнашчылык, шәрәләнү җәмгыять тормышына ирек, мода һәм сәнгать исемнәре белән керә. Мәсәлән, төп темасы зиначылык булган кинода актер булып катнашу уйнаш саналмый, ул сәнгать категориясенә керә, имеш. Тәнне ачып күрсәтү (шәрәләнү) «бернинди бозыклыгы булмаган» «мода» сүзенә төрелә. Әгәр сез кешегә гаурәт җирләрне капламаган киемне киюен әйтеп күрсәтеп оялтырга теләсәгез, сезгә «модада һәм мәдәнияттә берни аңламаган таш гасыр кешесе» ярлыгын тагачаклар.

Әхлак турында сүз чыкса, кешегә кирәкле йогынты ясау бик җиңел. Мәсәлән, әгәр аңа «гаурәт җирләрне ачучы кием» тәкъдим ителсә, ул тәкъдим итүчегә ризасызлык белдерәчәк, чөнки мондый тәкъдим аны

кимсетәчәк. Әмма инде шул ук кием «модалы кием» дип тәкъдим ителсә, кеше кызыксынып аны алырга да мөмкин.

Шулай итеп, әшәке эшне матур сүз белән исемләү нәтиҗәсендә ул эш алай ук әшәке булып кабул ителми башлый. «Оятсызлык», «уйнаш» кебек сүзләр урынына «күңел ачу», «шаярышу» кәлимәләре куйгач, хәлләр бөтенләй үзгәрә.

Өченче мисал: Хәзерге дөньяда абортлар саны артуы берәүгә дә сер түгел. Кешеләр абортны табигый, гадәти медицина процедурасы дип саныйлар, аның тискәре нәтиҗәләре турында бик сирәк уйлыйлар. «Авырга узуны өзгәннән соң хатын-кыз күпмедер вакыт җиңеләеп калу хисе кичерә, «кризистан» чыгу чарасы табылуына сөенә. Әмма тора-бара бу хис урынына борчылу тойгысы килә. Аның үз-үзен хөрмәт итүе кими, ул үзен гаепле итеп саный башлый, ашаудан һәм йокыдан кала, аны сәбәпсез курку баса, йоклаганда ямьсез төшләр керә, ул төшләрдә тумый калган бала аңа йә нәфрәтләнә, йә, киресенчә, аннан ярдәм сорый... Шулай итеп, шәхес үзенең кешелек асылыннан ерагая. Мондый кичерешләр хатын-кызны бөтен нәрсәдән ятсынуга китерә»[1].

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә әйтәдер:

وَلَا تَقْتُلُوٓا۟ أَوْلَٰدَكُمْ خَشْيَةَ إِمْلَٰقٍ ۖ نَّحْنُ نَرْزُقُهُمْ وَإِيَّاكُمْ ۚ إِنَّ قَتْلَهُمْ كَانَ خِطْـًٔا كَبِيرًا ﴿٣١﴾

> **«Фәкыйрьлеккә төшүдән куркып, балаларыгызны үтермәгез, чөнки Без аларны да, сезне дә ризыкландырырбыз. Чынлап та, балаларны үтерү – авыр гөнаһ».**
>
> «Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:31

Нәрсә соң ул аборт? Ислам динендә аборт, башкача әйтсәк, «йөклелекне өзү» кеше үтерүгә тиңләнә, зур гөнаһ итеп санала. Исламда

[1] Нуруллина Г. Женщина в исламе. – М.: Издательский дом «УММА», 2003. – Б. 140.

аборт ясату бары тик йөклелек хәле хатын-кыз гомеренә куркыныч тудырса гына рөхсәт ителә. Шәригать буенча, абортны балага узганнан соң кырык көн эчендә ясау мәслихәт күрелә. Кайбер очракларда абортны балага узганнан соң 120 көннән дә калмыйча ясау киңәш ителә, әмма бу мөддәт башка чара булмаган вакытта гына тәкъдим ителә[1].

Бүгенге көндә тумаган баланың яралгысын үтерү «аборт» дип атала. Бу сүзнең мәгънәсе һәркемгә мәгълүм, ләкин гади кеше аны тыныч, хәтта битараф кабул итә, чөнки бу сүз турыдан-туры «үтерү» мәгънәсен аңлатмый. Йөклелеген өзәргә карар кылган булачак ана аборт ясату турында медицина оешмасына мөрәҗәгать иткәндә нишләгәнен төшенеп җитми. Әмма аңа турыдан-туры «сез балагызны үтерергә телисезме?» дип сорау бирсәң, ул вакытта хатын-кызларның бик азы гына аборт ясатыр иде, чөнки һәр хатын-кызның күңеленә аналык хисләре салынган. Тик бу хисләр теге яки бу факторлар[2] аркасында үз кыйммәтен югалталар, күңел тупаслана.

Дүртенче мисал: Спиртлы эчемлекләрнең төрләре, аларның кеше күңелен мавыктырырлык исемнәре.

Коръәни Кәрим алкогольле эчемлекләр кулллануны тыя. Аллаһы Тәгалә әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِنَّمَا الْخَمْرُ وَالْمَيْسِرُ وَالْأَنصَابُ وَالْأَزْلَامُ رِجْسٌ مِّنْ عَمَلِ الشَّيْطَانِ فَاجْتَنِبُوهُ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ ﴿٩٠﴾ إِنَّمَا يُرِيدُ الشَّيْطَانُ أَن يُوقِعَ بَيْنَكُمُ الْعَدَاوَةَ وَالْبَغْضَاءَ فِي الْخَمْرِ وَالْمَيْسِرِ وَيَصُدَّكُمْ عَن ذِكْرِ اللَّهِ وَعَنِ الصَّلَاةِ ۖ فَهَلْ أَنتُم مُّنتَهُونَ ﴿٩١﴾

[1] Тәфсиллерәк мәгълүматны Нуруллина Г. «Женщина в исламе» китабыннан карагыз. – Б. 138-144.

[2] Мәсәлән, абортның фаҗигалелеген аңлап җиткермәү.

**«Әй сез, иман китергәннәр! Чынлап та, исерткеч эчемлекләр, комар уеннары, таш корбан чалу урыннары (яки потлар) һәм багучылык уклары – барысы да шайтан гамәлләреннән булган шакшылыктыр. Аннан сакланыгыз, бәлки, уңышка ирешерсез. Чынлап та, шайтан исерткеч эчемлекләр һәм комар уеннары ярдәмендә арагызда дошманлык белән нәфрәт орлыгы чәчеп, сезне Аллаһны зикер итүдән һәм намаздан йөз чөертергә тели. Сез (ул эшне башкарудан) туктамассыз микән ни?»**

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:90–91

Аятьтәге тыю бөтен спиртлы эчемлекләргә, алар нинди исем белән аталмасын, кагыла. Ягъни, аракы, шәраб, сыра, коньяк һ. б. барысы да тыелган эчемлекләр рәтенә керә. Бер риваятьтә болай диелә: Гомәр ﷺ[1] беркөнне Пәйгамбәр ﷺ минбәренә менеп әйтте: «Аллаһ хәмерне ул йөземнән, хөрмәдән, бодайдан, кара бодайдан яки балдан ясалса ясалсын – барысын да тыйды, чөнки шәраб кеше акылын миңгерәйтә». Ягъни, кеше зиһененә зарар китергән һәр нәрсә тыела.

Еш кына адәм баласы шайтан тозагына эләгә дә, исерткеч эчемлектән аерыласы килмичә аңа башка, матуррак исемнәр куша. Бу хакта Пәйгамбәребез ﷺ болай дигән: «Өммәтемнең беренче кылган гөнаһы хәмер эчү булыр». Сәхабәләр аңлап җиткермичә: «Бу мөмкинме соң, йә Расүлүллаһ, Коръәндә Аллаһ аны эчүне тыя бит?» – дип сорагannар. Җавабында Пәйгамбәребез ﷺ әйткән: «Алар бу эчемлекләргә башка исемнәр куеп, рөхсәт ителгәнгә санарлар»[2]. Чыннан да, хәзерге заманда, мәсәлән, гарәп илләрендә, алкогольле эчемлекләр «әл-мәшрубатеррухийә» (ягъни «рухи эчемлекләр») дип атала.

---

1 Әбү Хафс Гомәр бинел-Хаттаб – Мөхәммәд Пәйгамбәрнең ﷺ сәхабәсе, хәзрәти Әбү Бәкердән ﷺ соң икенче хәлифә.

2 Габдрахим Утыз-Имяни ал-Булгари. «Антология татарской богословской мысли». – Казан: Татар. китап нәшрияты, 2007. – Б.176.

Икенче яктан, кешеләр спиртлы сыекчалар организмга уңай тәэсир ясый, дип үз-үзләрен алдыйлар. Тик Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтәдер:

**يَسْأَلُونَكَ عَنِ الْخَمْرِ وَالْمَيْسِرِ ۖ قُلْ فِيهِمَا إِثْمٌ كَبِيرٌ وَمَنَافِعُ لِلنَّاسِ وَإِثْمُهُمَا أَكْبَرُ مِن نَّفْعِهِمَا ۗ وَيَسْأَلُونَكَ مَاذَا يُنفِقُونَ قُلِ الْعَفْوَ ۗ كَذَٰلِكَ يُبَيِّنُ اللَّهُ لَكُمُ الْآيَاتِ لَعَلَّكُمْ تَتَفَكَّرُونَ ﴿٢١٩﴾**

> **«Алар синнән шәраб белән мәйсир турында сорыйлар[1]. Әйт: аларның икесендә дә кешеләр өчен зур зыян һәм күпмедер файда бар, әмма зыяны файдадан күбрәк...»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:219[2]

Хәмер эчү гадәте җәмгыятькә бик күп зарар китерә. Бу – ачык хакыйкать. Алкоголь организмга килеп кергәннән соң аның бөтен әгъзаләренә җимергеч тәэсир ясый. Аны даими рәвештә куллану кешене алкоголизм кебек куркыныч авыруга җиткерә. Бу чир – токсикоманиянең бер формасы, аның төп күрсәткечләреннән берсе – эчендә этил спирты булган матдәләр куллануга хирыслык. Кешедә хәмергә карата психик һәм бәдәни (физик) бәйлелек формалаша, абстинент синдромы (махмыр халәте) барлыкка килә, шәхес физик һәм социаль яктан деградациягә дучар була.

Бишенче мисал: Төрле сихерчеләр, экстрасенслар, күрәзәчеләрнең күпләп барлыкка килүе.

Ислам дине буенча, сихерчелек, багучылык яки гаиптән хәбәр бирү зур гөнаһлар категориясенә керә. Пәйгамбәребез ﷺ көннәрнең берсендә болай дигән: «Җиде бөек гөнаһтан сакланыгыз!» Сәхабәләр сораганнар: «Йә Расүлүллаһ! Ул гөнаһлар нинди гөнаһлар?» Пәйгамбәребез ﷺ

1 Гарәп телендә «мәйсир» сүзе «комар уеннары» мәгънәсен аңлата.

2 www.mukmin.narod.ru/alko.html

әйткән: «Ширек кылу, сихерчелек итү...»[1]. Шулай итеп, сихерчелек белән шөгыльләнү һәм сихерчегә бару Исламда тыелган гамәлләрдән санала.

Күрәзәлек итү, күрәзәчеләргә йөреп киләчәкне «белергә» теләгән кешеләргә килсәк, бу хакта риваятьтә әйтелгәнчә, Пәйгамбәребезнең ﷺ хәләл җефете хәзрәти Гайшә ؓ болай дигән: «Кайбер кешеләр Мөхәммәд ﷺ янына килеп, багучыларның гаиптән хәбәр бирүләре турында сорашканнар. Җавабында ул:

– Алар хәбәр иткән бөтен сүзләр да ялган! – дип әйткән.

Әмма килүчеләр дәвам иткәннәр:

– Йә Расүлүллаһ! Ләкин ул багучыларның күрәзәлекләре кайбер вакытта раска чыга бит.

Мөхәммәд ﷺ мондый сүзгә болай җавап кайтарган:

– Дөрескә чыккан мәгълүматларны җеннәр фәрештәләрдән урлыйлар һәм үзләренең дуслары багучыларга җиткерәләр. Алар исә бер дөрес сүзгә йөз ялган сүз өстиләр (һәм кешеләргә шуны сөйлиләр)»[2].

Башка бер риваятьтә Пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйтүе хәбәр ителә: «Кем дә булса күрәзәгә яки багучыга барып, аларның сүзенә ышанса, ул кеше бу гамәле белән миңа иңдерелгәнне (Коръәнне) кире кагуын күрсәтер». Ислам гакыйдәсе буенча, бөтен барлыкның Яратучысы (Халикы) бары тик Аллаһтыр, киләчәкне Ул гына беләдер, Аннан башка берәү дә белми.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

**وَعِندَهُ مَفَاتِحُ الْغَيْبِ لَا يَعْلَمُهَا إِلَّا هُوَ ۚ وَيَعْلَمُ مَا فِي الْبَرِّ وَالْبَحْرِ ۚ وَمَا تَسْقُطُ مِن وَرَقَةٍ إِلَّا يَعْلَمُهَا وَلَا حَبَّةٍ فِي ظُلُمَاتِ الْأَرْضِ وَلَا رَطْبٍ وَلَا يَابِسٍ إِلَّا فِي كِتَابٍ مُّبِينٍ ﴿٥٩﴾**

[1] Әл-Бохари, Мөслим

[2] Әл-Бохари, Мөслим

**«Бөтен серләрнең (гаибнең) ачкычлары Аллаһтадыр. Аннан башка берәү дә гаибне белми...»**

«Әнгәм / Терлек», 6:59

Фәкать Аллаһы Тәгалә генә киләчәкне билгеләде. Башка кем дә булса тәкъдир ителгәнне белә дип әйтү аны Яратучы белән бер дәрәҗәгә куюга тиңдер, бу исә бөек гөнаһ булган ширекнең (күпилаһлык) бер күрсәткечедер.

Бүген сихерчеләр һәм күрәзәчеләр бик популяр булып китте. Бу бигрәк тә хатын-кызларга кагыла[1]. Бу күз буучылар үзләрен «чирләрдән савыктыручылар» дип атыйлар. Ягъни, алар кешеләрне төрле авырулардан, бәла-казалардан, гаилә проблемаларыннан һәм башкалардан коткаралар, имеш. Әмма мондый кешеләрнең төп максаты – кеше хакына кереп байлык җыю. Аларның «савыктырулары» бик күп халыкка киресенчә, зарар гына китерә. Мондый имчеләрнең эше нәтиҗәсендә якын туганнар бозылыша, ирләр хатыннарын аерып җибәрә, кешеләрнең матди торышы бозыла, адәм балалары төрле сырхауларга дучар була, психик авыруларга әйләнә. Әгәр бу сихерчеләрне һәм «экстрасенсларны» алдакчы, хәрамчы дип чын исемнәре белән атап йөртсәләр, алар тозагына күпкә азрак кеше төшкән булыр иде.

Дәвалаучылар чын, намуслы булганда, эшләрен шәригатькә туры китереп башкарганда, Ислам дине аларга каршы чыкмый, шелтәләми. Мәсәлән, кайбер риваятьләрдә Расүлуллаһ, әгәр дәвалаучылар Коръән аятьләрен әйтеп һәм Исламга хилаф булмаган әфсен сүзләрен кабатлап кешеләрне дәваласа, аларга каршы килмәгән, дип әйтелә. Гауф бине Малик ﵁ сүзләренә таянып, болай диелә: «Исламны кабул иткәнгә кадәр без авыру кешеләрне әфсен-төфсен итеп өшкерәдер идек. Бервакыт Пәйгамбәр ﷺ безгә әйтте: «Ул әфсеннәрегезне миңа күрсәтегез! Әгәр бидгать булмаса, аларны кулланырга ярый».

[1] Тормыш күрсәткәнчә, күрәзәлек, багучылык, им-томчылык белән күбрәк хатын-кызлар кызыксына.

Тагын бер чын (сәхих) хәдистә Мөхәммәднең ﷺ чирле кешеләр янында «Фәтихә» сүрәсе укылуын хуплаганлыгы хәбәр ителә.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шуны әйтергә кирәк: адәм баласы төрле вәсвәсәләргә, коткыга шактый ук җиңел бирелә. Билгеле, бу коткылар без күрсәткән мисаллар белән генә бетми. Дәвам итеп, аларга гыйффәтне саклау, гаилә булдыру, аның тулылыгын, ата-аналы булуын сакларга тырышу кебек темаларны да өстәргә мөмкин. Бу мәсьәләләрдә, беренчедән, «нәфес» (хайвани дәрт) зур роль уйнаса, икенчедән, наданлык мөһим урын алып тора. Ләкин адәм баласының, хайваннан аермалы буларак, акылы бар. Ислам игътикады буенча, ул Аллаһның башка мәхлукларыннан өстен[1]. Кешегә акыл һәм башка камил сыйфатлар бирелгәнгә күрә, Халикъ аны җирдә «хәлифә» – идарәче итеп куйды. Шуның өчен мөэмин кеше аның тирә-ягында булып торган хәлләрнең һәм күренешләрнең чын асылын тулысынча белергә, аларны аек акыл белән бәяләргә һәм бары тик зарар китерүче шайтанның коткысына бирелмәскә тиеш.

*Рафикъ Рафаэль улы Йосыпов,*
*Казан Ислам университеты мөгаллиме,*
*Ислам фәннәре факультеты мөдиренең урынбасары*

[1] Аллаһы Тәгалә Коръәндә (17:70) әйтәдер: «Һичшиксез, Без Адәм улларына шәрәф (хөрмәт) бүләк иттек һәм алар Безнең әмер белән җирдә һәм суда йөрделәр. Без аларга нигъмәтләр һәм башка мәхлукларга караганда өстенлек бирдек».

# Йәгез, бер дога

## Мигъраҗ кичәсе намазы

Мигъраҗ кичәсендә укыла торган һәм мөстхәб саналган намаз бар. Пәйгамбәребез ﷺ: «Раҗәб аенда бер (үзенчәлекле) төн бар. Ул төндә кылган гыйбадәте өчен кешегә йөз ел гыйбадәт кылган кебек савап язылачак. Һәм бу – раҗәб аеның 27 нче төне», – дигән.

Бу төндә һәр рәкәгатендә «Әл-Фатиха» сүрәсен һәм тагы берәр нинди сүрә укып, һәр ике рәкәгатеннән соң сәлам биреп 12 рәкәгать намаз укыган, соңыннан йөз тапкыр «сөбхан Аллаһи вәлхәмдү лиЛләһи вә лә иләһә илләЛлаһу вәЛлаһу әкбәр» сүзләрен әйткән. Һәм шуннан соң йөз тапкыр («әстәгъфируЛлаһ» дип әйтеп) истигъфар укыган, йөз тапкыр салават әйткән һәм шушы көнне ураза тотып, бу яки бакый дөнья өчен нәрсәдер сорап дога кылган кешенең бар догалары кабул булыр. Әгәр алар гөнаһлы нәрсәләргә бәйле булмасалар», – дип әйткән[1]. Хәдисне Әнәс ибн Мәлик тапшырган.

## Бәраәт кичәсе намазы

Ибн Әбү Шәйбә, ибн Гасәкир, Бәйһәкый, ибн Зәнҗүйә, Дәйләми, Динәври, Табәри кебек мөхәддисләрдән тапшырылган хәдистә болай диелгән: «Бу төнне Аллаһ Тәгалә фәрештәләргә түбәндәгеләрне хәбәр итә: киләсе елда кемгә нинди тәкъдир язылган; кем бай, ә кем фәкыйрь булачак; кем югары дәрәҗәгә күтәреләчәк, ә кем түбәнсетеләчәк; кем туачак, ә кем үләчәк; һәм ничә кеше хаҗга барачак»[2].

Бәраәт кичәсендә махсус намаз уку мөстәхәб санала. Моның турында тапшырылган хәдисләр зәгыйфь булсалар да, билгеле булганча, изге

1 Бәйһәкый, Фәдаилүл-әүкат, №12, 97-98 б., Шүгабүл-иман, № 3531, 5/346; Ибн Әсәкир, Әл-Гамәли фәдлүл-раҗәб, 6 б.

2 Бәйһәкый, Шүгабүл-иман, № 3839-3840, 5/253; Ибн Әбү Шәйбә, Әл-Мүсәннәф, 3/103; Дәйләми, Мүснәдүл-фирдәвес, №2410; Табәри, Җәмигүл-бәян, 21/10; ибн Гасәкир, Тариху мәдинәти Димәшкъ, 61/250; Суюти, Әд-Дурруль-мансур, 1253-254

гамәлләр кылуга килгәндә, зәгыйфь хәдисләргә нигезләнергә мөмкин. Бу төнне гыйбадәттә үткәргәнгә күп савап каралган.

Әлеге риваятьләр буенча, Бәраәт төнендә укыла торган намаз «саләтүл-хайр» (игелек намазы) дип атала. Күп кенә риваятьләрдә ул намазның йөз рәкәгатьтән торуы һәм һәр рәкәгатьтә «Әл-Фатиха» сүрәсеннән соң ун тапкыр «Әл-Ихлас» сүрәсе укылырга тиешлеге хәбәр ителә.

Гали ибн Әбү Талиб ﷺ тапшырган риваятьтә Пәгамбәребезнең ﷺ: «Ий Гали! Әгәр кемдер шәгъбан аеның уртасында (15 нче төнендә) йөз рәкәгать намаз укыса һәм һәр рәкәгатендә «Әл-Фатиха» сүрәсеннән соң ун тапкыр «Әл-Ихлас»ны укыса, Аллаһ Тәгалә бу төндә аның теләсә нинди теләген үтәр. Әгәр ул кеше бәхетсез дип язылган булса, бәхетле дип кире язылган булыр.

Гали, мине хакыйкать белән җибәргән Аллаһ исеме белән ант итәм, Әл-Ләүхүл-мәхфүздә бар да инде язылган: «Фәлән һәм фәләннең улы бәхетсез итеп яратылган, әмма Аллаһ бу язуны җуйды һәм аны бәхетлеләрдән язды».

Аллаһ Тәгалә бу (бу намазны укыган) бәндәсе янына җитмеш мең фәрештәсен җибәрер, алар аның киләсе елга кадәр алачак савапларын язып, гөнаһларын җуеп, дәрәҗәсен күтәреп торырлар. Шул кеше киләсе ел җиткәнче вафат булса, шәһит кебек китәр. Аның бар кылган һәм кылачак намазлары кабул булыр. Хәтта әти-әнисе җәһәннәмгә эләгеп, ул алар өчен дога кылса, Аллаһ аларны җәһәннәмнән чыгарып җәннәткә кертер, тик алар Аңа һичбер зат тиңләгән булмасалар.

Мине хак илчесе итеп җибәргән Аллаһ исеме белән ант итәм, ул кеше Аллаһ Тәгалә аңа җәннәттә әзерләгән урынын күрмичә, бу дөньядан китмәс», – дип әйтүе китерелә[1].

[1] Газали, Ихъя голүмүд-дин, 1/203; Зәбиди, Итхафүс=сәгадә, 3/425; Габделкадыйр Җәйләни, Әл-Гунйә, 1/348-349; Әбү Габдуллаһ Әл-Хубәйши, Китәбүл-бәракә, № 529-531, 192-193 б.; Исмәгыйл Хаккы, Рухүл-бәян, 8/403

## Кадер кичәсе намазы

Кайбер риваятьләрдә Кадер кичәсендә иң азы – ике рәкәгать, уртача – йөз рәкәгать, ә иң күбе – бер мең рәкәгатьле намаз укылуы хәбәр ителә[1].

Бу намаз бары ике рәкәгатьтән торса, «Әл-Фатиха» сүрәсеннән соң һәр рәкәгатьтә ике йөзешәр аять уку кирәк. Бу намаз йөз рәкәгатьтән укылса, «Әл-Фатиха» сүрәсеннән соң һәр рәкәгатьтә бер тапкыр «Әл-Кадер» һәм өч тапкыр «Әл-Ихлас» укылырга тиеш. Һәр рәкәгаттән соң Пәйгамбәребез ﷺ Гайшәгә ؓ өйрәтеп калдырган әлеге доганы укырга кирәк:

اللَّهُمَّ اِنَّكَ عَفُوٌّ تُحِبُّ الْعَفْوَ فَاعْفُ عَنِّي

«Йә Аллаһ! Син – Гафу итүче һәм (гөнаһлы бәндәләреңне) гафу итәргә яратасың. Гафу итче мине!»[2]

Бу намазны нәкъ шушы рәвешле уку мәҗбүри түгел, әмма аны шушылай уку мәслихәт булуын хәбәр итүче риваятьләр бар. Төп максат булып исә мөселманнарның бу төнне гыйбадәт һәм зикердә үткәрүе тора.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөселманнарының*

*Диния нәзарәте рәисе, мөфти*

---

1 Исмәгыйл Хаккы, Рухүл-бәян, 10/372

2 Ибн Мәҗә, Дога: 5, №3850, 2/1265

## Җеназа намазын уку тәртибе

Мәет алдындагы соңгы вазыйфаларыбызның берсе – җеназа намазын уку. Җеназа намазын мәчет эчендә уку хупланмый.

Намаз түбәндәге тәртиптә башкарыла: мәетне җәмәгать алдына, Кәгъбәтуллаһка перпендикуляр рәвештә яткыралар. Имам мәетнең күкрәге турысына баса, калган мөселманнар аның артында рәтләргә тезелә, әлеге рәтләрнең бердән артыграк – өч, биш яисә җиде рәт булуы шарт. Җеназа намазын кайтарып уку мөмкин булмаганлыктан, аңа тәяммүм[1] белән басу да рөхсәт ителә. Мәетнең Аллаһы Тәгалә каршында дәрәҗәсе озатучылар саны белән түгел, җеназа намазында катнашучылар саны белән бәяләнә. Җеназа намазы авыр бер намаз түгел. Ничек укылганын өйрәнсәк, мәетне догасыз, үзебезне дә савапсыз калдырмабыз.

Җеназа намазы дүрт тәкбир белән аягүрә укыла. Иң элек ният кылына. Ниятнең ничек укылганын мөәзин каты тавыш белән җәмәгатькә әйтә. Аннан соң имам, кулларын күтәреп, беренче тәкбирне ала һәм кулларын баглый. Җәмәгать тә шуны эшли.

Беренче тәкбирдән соң «Сәнә» догасы укыла:

سُبْحَانَكَ اللّٰهُمَّ وَبِحَمْدِكَ وَتَبَارَكَ اسْمُكَ وَتَعَالٰى جَدُّكَ وَ لَآ اِلٰهَ غَيْرُكَ

**Сөбхәәнәкәл-Лааһүммә үә бихәмдикә үә тәбәәракәсмүкә үә тәгәәләә җәддүкә үә ләәә иләәһә гайрук**

Мәгънәсе: «Әй Аллаһы, Сиңа дан һәм мактау булсын! Синең исемең мөбарәк һәм дәрәҗәң олуг. Синнән башка бернинди илаһи зат юк».

Бу доганы укып бетергәч, имам, кулларын күтәрмичә, «Аллаһү әкбәр» дип, икенче тәкбирне ала. Җәмәгать тә, кулларын күтәрми һәм эченнән генә икенче тәкбирне ала.

[1] Тәяммүм алу тәртибе 54 нче биттә китерелә

Икенче тәкбирдән соң салават догалары («Әллааһүммә салли» – «Әллааһүммә бәәрик») укыла.

اَللّٰهُمَّ صَلِّ عَلٰى مُحَمَّدٍ وَ عَلٰى اٰلِ مُحَمَّدٍ كَمَا صَلَّيْتَ

عَلٰى اِبْرٰاهِيمَ وَ عَلٰى اٰلِ اِبْرٰاهِيمَ اِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ

اَللّٰهُمَّ بَارِكْ عَلٰى مُحَمَّدٍ وَ عَلَى اٰلِ مُحَمَّدٍ كَمَا بَارَكْتَ

عَلٰى اِبْرٰاهِيمَ وَ عَلٰى اٰلِ اِبْرٰاهِيمَ اِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ

**Әллааһүммә салли гәләә Мүхәммәдин үә гәләә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә гәләә Ибрааһиимә үә гәләә әәли Ибрааһиимә иннәкә хәмиидүм-мәҗиид. Әллааһүммә бәәрик гәләә Мүхәммәдин үә гәләә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә гәләә Ибраһиимә үә гәләә әәли Ибраһиимә иннәкә хәмиидүм-мәҗиид**

Мәгънәсе: «Йә Рабби, Ибраһим галәйһиссәламгә һәм аның гаиләсенә рәхмәтеңне биргән кебек, Мөхәммәд галәйһиссәламгә һәм аның гаиләсенә дә рәхмәтеңне бир. Дөреслектә, Син – мактаулы һәм олуг зат. Йә Рабби, Ибраһим галәйһиссәламгә һәм аның гаиләсенә бәрәкәтеңне биргән кебек, Мөхәммәд галәйһиссәламгә һәм аның гаиләсенә дә бәрәкәтеңне бир. Дөреслектә, Син – мактаулы һәм олуг зат.

Аннан соң имам, кулларын күтәрмичә, өченче тәкбирне ала.

Өченче тәкбирдән соң җеназа догасы укыла.

Җеназа догасын белмәгәннәргә туган телендә дога кылып тору да рөхсәт ителә.

Әгәр дә мәет ир кеше булса, түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِحَيِّنَا وَمَيِّتِنَا وَشَاهِدِنَا وَغَائِبِنَا وَصَغِيرِنَا وَكَبِيرِنَا وَذَكَرِنَا وَأُنْثَانَا. اَللَّهُمَّ مَنْ أَحْيَيْتَهُ مِنَّا فَأَحْيِهِ عَلَى الْإِسْلَامِ. وَمَنْ تَوَفَّيْتَهُ مِنَّا فَتَوَفَّهُ عَلَى الْإِيمَانِ.

اَللّٰهُمَّ إِنْ كَانَ هَذَا الْمَيِّتُ مُحْسِنًا فَزِدْ فِي إِحْسَانِهِ وَإِنْ كَانَ مُسِيئًا فَتَجَاوَزْ عَنْهُ.

**Әллааһүммә-гфир лихәййинәә үә мәййитинәә үә шәәһидинәә үә гаа’ибинәә үә сагыйринәә үә кәбииринәә үә ҙәкәринәә үә үнс̣әәнәә. Әллааһүммә мән әхйәйтәһүү миннәә фә’әхйиһи гәләл-исләәм. Үә мән тәүәффәйтәһү миннәә фәтәүәффәһү гәләл-иимәән**

**Әллааһүммә ин кәәнә һәҙәл-мәййитү мүхсинән фәзид фии ихсәәниһи үә ин кәәнә мүсии’ән фәтәҗәәүәз гәнһ**

Мәгънәсе: «Йә Рабби, тереләребезне һәм үлгәннәребезне дә, монда булучыларны һәм монда булмаучыларны да, кечкенәләребезне һәм олыларыбызны да, ирләребезне һәм хатыннарыбызны да ярлыка. Йә Рабби, тере булганнарыбызга Ислам дине буенча яшәргә насыйп ит, ахирәткә китүчеләргә иман белән вафат булырга насыйп ит. Йә Рабби, әгәр ошбу мәет изге кеше булса, изгелеген арттыр, әгәр гөнаһлы кеше булса, гөнаһларын гафу кыл».

Әгәр дә мәет хатын-кыз булса, доганың соңгы юлы түбәндәгечә укыла:

اَللّٰهُمَّ إِنْ كَانَتْ هَذِهِ الْمَيِّتَةُ مُحْسِنَةً فَزِدْ فِي إِحْسَانِهَا وَإِنْ كَانَتْ مُسِيئَةً فَتَجَاوَزْ عَنْهَا.

**Әллааһүммә ин кәәнәт һәҙиһил-мәййитәтә мүхсинәтән фәзид фии ихсәәниһәә үә ин кәәнә мүсии’әтән фәтәҗәәүәз гәнһ**

Мәгънәсе: «Йә Рабби, тереләребезне һәм үлгәннәребезне дә, монда булучыларны һәм монда булмаучыларны да, кечкенәләребезне һәм олыларыбызны да, ирләребезне һәм хатыннарыбызны да ярлыка. Йә Рабби, тере булганнарыбызга Ислам дине буенча яшәргә насыйп ит, ахирәткә китүчеләргә иман белән вафат булырга насыйп ит. Йә Рабби, әгәр ошбу мәет изге кеше булса, изгелеген арттыр, әгәр гөнаһлы кеше булса, гөнаһларын гафу кыл».

Ир баланы яисә акылга сай кешене җирләгәндә, доганың соңгы юлы түбәндәгечә укыла:

اَللَّهُمَّ اجْعَلْهُ لَنَا فُرَطًا وَاجْعَلْهُ لَنَا أَجْرًا وَذُخْرًا وَاجْعَلْهُ لَنَا شَافِعًا وَمُشَفَّعًا.

**Әллаһүммә-җгәлһү ләнәә фуратан үәҗгәлһү ләнәә әҗран үә ẓухран үәҗгәлһү ләнәә шәәфиган үә мүшәффәгән**

Мәгънәсе: «Аллаһым! Бу ир баланы (мәетне) җәннәттә безне каршы алучы вә ахирәт бүләге кыл. Аллаһым! Бу ир баланы (мәетне) безнең өчен шәфәгатъче кыл вә шәфәгатеннән Үзең разый бул».

Җеназа акылга сай хатын-кызга яки кыз балага укылса, доганың соңгы юлы түбәндәгечә укыла:

اَللَّهُمَّ اجْعَلْهَا لَنَا فُرَطًا وَاجْعَلْهَا لَنَا أَجْرًا وَذُخْرًا وَاجْعَلْهَا لَنَا شَافِعَةً وَمُشَفَّعَةً.

**Әллаһүммә-җгәлһәә ләнәә фуратан үәҗгалһәә ләнәә әҗран үә ẓухран үәҗгалһәә ләнәә шәәфигәтән үә мүшәффәгәтән**

Мәгънәсе: «Аллаһым! Бу кыз баланы (мәетне) җәннәттә безне каршы алучы вә ахирәт бүләге кыл. Аллаһым! Бу кыз баланы (мәетне) безнең өчен шәфәгатъче кыл вә шәфәгатеннән Үзең разый бул».

Аннары дүртенче тәкбир алыныр. Дүртенче тәкбирдән соң берни укылмас. Уңга һәм сулга сәлам бирелер. Шуның белән җеназа намазы тәмам булыр.

Җеназа намазын кыскача шул рәвештә күрсәтеп була:

Беренче тәкбир, «Сәнә» догасы.

Икенче тәкбир, салават догалары.

Өченче тәкбир, «Җеназа» догасы.

Дүртенче тәкбир, аннан берни укылмыйча, сәлам бирелә. Намаз тәмам була.

Динебез кешеләрнең хәер-догасына һәм таныклыгына әһәмият бирә. Шуның өчен җеназа намазын укыгач, җәмәгатьтән: «Яхшы кеше идеме?» – дип сорала. Җәмәгать тә: «Яхшы кеше иде. Аллаһының рәхмәтендә булсын», – дип җавап бирә. Шулай итеп аның яхшылыгына таныклык иткән булалар.

Шундый бер хәдис бар. Җыелганнарның яныннан мәет белән үтеп киткәннәр. Кешеләр мәет турында мактау белән сөйләгәннәр, ә Гомәр ﵇: «Бу һичшиксез», – дип әйткән. Аннан соң башка мәет белән үтеп киткәннәр, кешеләр тагын мәет турында мактау белән сөйләгәннәр, ә Гомәр ﵇ тагын: «Бу һичшиксез», – дигән. Аннан соң өченче мәетне алып киткәннәр, һәм бу юлы кешеләр мәет турында начар сөйләгәннәр, Гомәр ﵇: «Бу һичшиксез», – дип әйткән. Бер кеше сораган: «Нәрсә һичшиксез, әй мөэминнәр әмире?» Ул әйткән: «Мин Пәйгамбәрнең ﷺ сүзләрен кабатлыйм гына, ул әйтте: «Дүрт башка мөселман мактаган һәрбер кешене Аллаһ җәннәткә кертәчәк». Аннан сораганнар: «Ә әгәр алар өчәү булсалар?» Ул: «Һәм өчәү дә», – дип җавап биргән. Аннан яңадан сораганнар: «Ә икәү?» Ул: «Икәү дә», – дип җавап кайтарган, һәм әгәр бер генә шундый кеше табылса, нәрсә булачагы турында сорап тормаганнар .

Шуңа күрә мәетнең яхшы икәнен таныклау кирәк әйбер булып тора.

*«Мәет озату йолалары» китабыннан*

*«Хозур» нәшрият йорты*

# Әдәби сәхифә

# Александр Сергеевич Пушкин

## Пәйгамбәр (Пророк)

Кара чүлдә рухи бушлыкта
Тилмереп мин зарыкканда,
Җәбраил галәйһиссәлам
Пәйда булды минем алда.

Йомшак кына төштә кебек
Тидереп алды күзләремә канатын,
Калтыранган бөркет сыман
Ул нишләрен мин карадым.

Хикмәт-серле яңгыравык тавыш
Белән кагылды ул колагыма:
Тетрәнде күкләр, очты фәрештәләр,
Диңгез асты юллар, хәшәрәтләр,
Ишеттем мин барысын да анык кына.

Миңа турыдан-туры сыенды ул,
Хәйләлеккә оста булган
Гөнаһлы телемне йолкыды ул.
Беректерде авызыма
Урт тешеннән кызыл канын
Ачып торган елан угын.

Кылыч белән ярып ачты күкрәгемне,
Тартып алды эшләп торган йөрәгемне.

Ялкынланып янып торган күмер утын
Кадап тыкты хәлсезләнгән җәсәдемә.

Ятамын мин бу бушлыкта вафат кебек,
Ишетелде Хак Тәгалә чакыруы аваз булып:
«Әй Пәйгамбәр, күтәрел, чакыр,
Өндә изгелеккә, шулдыр сиңа әмерем,
Диңгезләрне кичеп, җирләр йөреп әйлән,
Хак сүз белән яндыр бәндәләрнең бәгырен!»

1826

## Коръән аятьләренә охшатулар (Подражания Корану)

(өзекләр)

I

Ант итәм мин так вә җөп белән,
Ант итәм мин кылыч вә җиһад белән,
Ант итәм мин иртәнге йолдыз белән,
Ант итәм мин икендедә фарыз белән:

Юк, ташламадым мин, бәгърем, сине.
Кемне соң мин юату канатыма салдым,
Мин аны яратып, мәхәббәтем башына алдым,
Һәм аяныч золымлыктан саклап калдым?

Мин түгелме соң сусау көндә сиңа су бирүче,
Чүл сулары сине сугаручы?
Мин түгелме соң синең телгә илһам өстәп
Акыллар өстеннән кодрәт Хаким булучы?

Батыр бул. Калтыранган мәхлүккә аңлат,
Ялганлыкны тап та, Хак юлдан кыю атла,
Ятимнәрне якла һәм Коръәнгә
Минем мәхәббәтемне сакла!

III
Пәйгамбәр, галәмнән вәхи инде сиңа,
Түгел киребеткән адашканнарга;
Тыныч кына Коръән белән өндә,
Мәҗбүр итмә көфер саташканнарны!

Ни сәбәп соң тәкәбберләнә кеше?
Әллә шәрә, дөньяга килгәнгәме,
Әллә сулышы гасырда кыска булгангамы,
Зәгыйфь туып, зәгыйфьлектә үлгәнгәме?

Әллә Хак Тәгалә вафат иткәнгәме, һәм
Үз рәхмәте белән терелткәнгәме?
Кем шатлыкларда, әче кайгы язмышларда аны яклый,
Нинди куәт күктән аның көннәрен саклый?

Җиләк-җимеш аңа биргәнгәме,
Икмәк, хөрмә, зәйтүнгәме,
Аның хезмәтен хөрмәт кылыр,
Әйләншәһәр, һәм калку, һәм иген кыры?
Тик фәрештә ике тапкыр быргыдан өрер;
Күкрәп җиргә күк селкенер:
Ир туган читкә чабар агасыннан,
Һәм угыл бала качар анасыннан.

Кыяфәтен, төсен җуйгач куркудан;
Барысы да Раббымызның хозурына агылыр,
Үлекләр белән ялкында капланып,
Имансызлар, саташканнар абыныр.

IV
Әүвәледән Синең белән, йә Кодрәт көчем,
Мин изгелектә ярышмак булам,
Тәкәбберлектән акылым җуям,
Ялварамын: «Ярлыка, йә Иләһә Ходам!»

«Дөньяда җиргә бирәм тереклек,
Һәм җәзам булыр үлем,
Тереклекнең дә, үлемнең дә,
Бердәнбер Хуҗасы мин Үзем», – диде Ул.

Шулай ук: «Тормыш – Яшәү бирәм,
Һәм үлем белән җәза кылам», – диде Ул.
Синең белән, Раббым, «Мин тигезлектә»,
Булса иде барлык ният-гамәл изгелектә!» – дидем мин.

Ачуың чыккан синең сүзеңнән,
Бозыклыкны мактаудан туктап, әйтик:

Күтәрәм мин кояшны көнчыгыштан;
Күтәр аны син көнбатыштан!

V
«Хәрәкәтсез» Җирне – күкләр гөмбәзләрен,
Тотып торган Куәт көче – Син иҗатчы,
Әйе, аумас коры җиргә һәм сулары
Таптый алмас Безне килсә гарасатлары.

Син кояшны яндырдың бу дөньяга,
Әйе, яктырта ул җирдә вә күкләрдә дә,
Җитен мае сыман сугарылып, әйтерсең лә,
Яктырта ул затлы пыяла күк галәмнәрдә дә.

Иҗатчыга баш иегез; Кодрәтле Ул;
Бәгырьләрне куырырдай эссе көндә
Җибәрә Ул болыт вә җилләрен дә;
Бирә җиргә Ул агач вә игеннәрен дә.

Шәфкатьле Ул: Ул Мөхәммәдкә
Ачты балкып торган Коръән,
Агым судай юнәлик без яктылыкка
Һәм күзләрдән качсын томан.

VII
Уян, куркуга талган:
Синең мәгарәңдә
Таң атканда
Изге ут янган.
Калебтән догам белән,
Пәйгамбәр, коткар мине
Наян төшләрдән,
Яман уйлардан!

Тыйнаклыкта, догада бул
Кояш чыкканчы,
Галәм китабын укы
Таң сызылганчы!

VIII
«Төсен җуйган фәкыйрьлек алдында сатып намус,
Мәкер кулың белән санап, мактап сатма хәрам малың:
Галәмнәрдә барлык юмартлыкка белеп тор син Хуҗаң барын.
Кыямәтнең дәһшәтле бер көнендә, иген тулы басу кебек,
Әй Раббым, рәхим-шәфкать, иминлекне Син чәчүче, майтаручы,
Һәр бәндәнең хәләл хезмәтенә йөздән артык итеп кайтаручы».

Әгәр дә, хәрам хезмәт белән дөнья малын син ауласаң,
Хөсетләнеп саранлыкта фәкыйрь хакын санамасаң,
Мескеннәргә хәләл булган нигъмәтләрне кире каксаң,
Шуны бел: бер уч тузан булып очар җыйган хәрам малың.

IX
Алҗыган юлаучы Аллага ялварган:
Юк күләгә. Сусаган ул, хәлдән тайган.
Өч көн нәм өч төн йөргән чүлдә адашкан,
Эссе, тузан, күрми күзләр, ялгыз буранда калган.

Киселгән миһер, өзелгән өмет, йөргән әйләнеп,
Ни могҗиза! Пальма. Төбендә кое. Алган шәйләнеп.
Йөгергән ул. Коега сыенган.
Эчкән туйганчы. Суында коенган.

Тәмам кипкән тел вә тән хәл алган,
Юлаучы исә ишәген кочып йокыга талган…
Җир, күкләр Хуҗасының рәхмәте булган,
Мескеннәр өстеннән аккан күп еллар
Юлаучыларны юксынып бүген кем елар!

Юлаучыга уяныргa сәбәп булып «сукты сәгате»,
Ни булганын аңлый алмый бетте тәгате.
Шул мизгелдә килде аңа серле бер аваз:
«Кайчан соң син чүлдә тирән йокыга талган?»
«Кичәге күктә кояш балкыды иртәнге таңда.
Димәк, кичәге таңнан бүгенгесенә мин йокыда калган».

Ләкин аваз: «Әй юлаучы, син озак йокладың;
Кара: яттың яшьлектә, тордың картлыкта
Сусыз ком чүле тәмам корыды,
Кое да салкын, пальма череде.
Буранлы далада юктыр комның артык кирәге,
Күренәдер барханнарда ишәгеңнең аксыл сөяге».

Хәсрәт алмаш кайгы басканда бабай
Калтыранды, башын асты, үксеп елады агай.
Шул мизгелдә ком чүленә могҗиза килде;
Үткәндәге хәтфәлекләр яңадан иңде;
Торды пальма, куаклыклар көрсенеп куйды;
Саф, салкын кое көмеш суларын үзенә җыйды.

Әүвәл черегән вә таралган ишәкнең сөякләре җыела;
Хайван тәненә җан өрә, куәт-хәрәкәт тоела;

Ә юлаучы исә күч, аң, шатлыкны сизә;
Каннарының юлларында яңадан туган яшьлек гизә;
Изгелектә сугарылган куанычтан күкрәк тула:
Һәм Аллага тапшырып юлга юлаучы чыга.

1824

*Харис хәзрәт Салихҗан тәрҗемәсе*

## Муса Акъегет



Муса Мөхәммәтҗан улы Акъегетов (1864–1923) – татар язучысы, мөгаллим.

1886 елда Казанда университет типографиясендә беренче татар романы – Муса Акъегетнең «Хисаметдин мелла» әсәре – басылып чыга. 1887 елда Муса Акъегет Кырымга Бакчасарай шәһәренә барып, «Тәрҗеман» газетасы редакциясендә эшли.

Төркиядә Мөлкия (дәүләт учрежденияләрендә эшләүче хезмәткәрләр хәзерләүче) мәктәбен бетерә.

1908 елларда аның «Мәтин» исемле газет чыгаруы, ә соңрак, 1914 елдан башлап, Казаннан сатып алынган китапларны тәртипкә салу буенча Истанбул китапханәсендә эшләве турында мәгълүмат бар. Шулай ук икътисад буенча фәнни эшләр яза. Соңгы көннәренә кадәр ул китапханәдә эшли.

### Хисаметдин мелла

(Милли роман яки хикәя)
(1886)

I

Русия уртасында Идел елгасыннан ерак түгел бер татар авылы бардыр. Авылның халкы ике йөз кадәр өй булып, атын тулысынча әйтеп тормыйбыз, шуңа күрә, хикәябезне җиңел аңлатмак өчен, атын бары «Н» хәрефе илә генә ишарә итәбез. «Н» авылының йортлары гади йортлар кебек агачтан вә башлары кайберләренең саламнан, кайберләренең такта-

дан ясалмыштыр. «Н» авылында ике мәчет бар. Бер урамлы авыл булып, урамы озын вә киндер. Урамы озаеп, кыйбла тарафындагы очында борылып, суга юл чыгадыр.

Халкының башлыча тормыш өчен хезмәте игенчелектер. Ләкин күп кенә кешеләре башка шәһәрләргә, мәсәлән, Әстерхан, Ростов, Казан кебекләргә эш вә сәүдә өчен йөрерләр. Шунда «Н» авылында урта мәчеттән ерак түгел бер кечкенә йорт бар.

Бу йорт үзе кечкенә булса да, тактадан башы, анбары вә төзек сарайлары иясенең иҗтиһадлы-тырыш вә хезмәт сөючән адәм идегене күрсәтерләр иде. Бу йортта мулла хатыны тол Зөлхәя вә улы Хисаметдин мелла атлы адәмнәр торырлар иде. Мелла Хисаметдиннең мәрхүм атасы указный мелла булмыш исә дә, улы атасының юлыннан китмәде.

Ике-өч ел моннан элек мелла Хисаметдин госманлы (Төркия) җиреннән укып ватаны «Н»га кайтты. Хәзер дә үзе өенең икенче бүлмә чигендә сабыйларга дәрес бирер иде. «Н»лыларның кайберләре Хисаметдин меллага теләктәшлек итәрләр иде, чөнки ике ел эчендә язу язмак, язу танымак, хисап гыйлеме, дин гыйлеме балаларына өйрәтте. Әмма күп кенә кешеләр бу укытучыны, яхшы белмәдекләреннән, сөймәсләр иде. Мәсәлән, авылның указный мулласы карт Бикбулат мулла әфәнде Әхмәтша углы, көнчелек итеп, аны сөймәс иде вә мәҗлесенә килгәннәргә әйтер иде: «Ни өчен бу юләр наданга балаларыгызны бирәсез, тәүфыйктан чыгарыр, китерегез минем үз мәдрәсәмә, ул иҗек үгрәтмәс, тугрыдын-тугры сүрә укытыр, аның ысулы тәдрисе җаиз дәгел , мәсәлән, а-ба укытыр, әмма әүвәл әлиф сенә бәсендә кирәк». Вә шул рәвешле асылсыз сүзләр берлә Хисаметдин мелланы хурлар иде. Күп халык карт мулланың сүзенә шәригать сүзе кебек инаныр иде. Әмма Хисаметдин мәктәбендә укытмыш вә тәҗрибә итмеш кешеләр, карт мулланың буш сүзләренә ышанмыйча, Хисаметдин меллага камил теләктәшлек итәрләр иде. Хисаметдин мелла исә морфология һәм синтаксис белеменнән генә түгел, хәтта мөселман

хокук белеменнән, хәтта философия фәненнән Истанбулда шәкертлектә тәмам хәбәрдар булган иде. Татар муллаларының кайберләре, үзләре аз белдекләреннән, күп белүче башкаларга көнчелек итеп, сөймәдекләре мәгълүмдер.

Хисаметдин мелла хәрәкәт вә кәсеп сөюче кеше иде: ун дисәтинә үзенең җире бар иде. Гәрчә бер хезмәтче тотса да вә күп чакта яз вакыты иген эшендә башка хезмәтчеләр ялласа да, күп вакыт үзе дә кара иген эшене эшләр иде. Моның аркасында Хисаметдин мелла рәхәт вә башкаларга ихтыяҗсыз тормыш итәр иде.

Хикәябез якында гына узган заманнарга карыйдыр, бәйләнешледер.

Кыш якынлашмыш вакытлар. Җомга көн намаздан әүвәл Хисаметдин мелла «Тәфсире бәйзави» китабыны укып утыра иде.

Йөзенә баксаң, бу егерме биш яшьлек егеткә гаҗәпләнерсең. Йөзе гүзәл ачык. Яңарак чыкмыш кечек сакалы вә мыеклары, вә кыска чәче коңгырт төстә булып, матур йөзенең гүзәллеген тагын да арттырадыр. Нурлы вә күк күзләре китап битенең юлыннан юлына йөгереп үтәрләр. Башында бәрхет тәкыясының көмеш ае ялт-йолт ялтырар иде.

Тәфсирне куйды. Бүлмәсендә йөрер. Йөзеннән тирән фикергә талдыгы беленер. Йөргәндә биек буены вә ир кыяфәтене күрсәң, гашыйк булырсың. Шул вакытта тәрәзәдән волостной идарәсе хезмәтчесенә күреп, капкага тугры барып: «Һай, килдеме?» – дип шатланып кычкырды. Әлеге хезмәтче: «Килде», – диеп, моңа бер кәгазь бирде. Кәгазьне алып, егет бик тә шатланды. Бу кәгазь – Русия исламнарының сәламәтене вә күркәм тормышыны яклаган «Тәрҗеман» газетасы иде. Хисаметдин мелла үзенең милләтене, ягъни татарларны бик сөюче адәм иде... Хәтта Бикбулат мулла үзене дошман күрсә дә, ул һич дошман күзе белән аңа бакмас иде. Чөнки яхшы белә иде ки, бу дошманлык хәсәдлек-көнчелектән килер. Хәсәдлек кебек зур бәлагә дучар булган адәмне Хисаметдин мелла түгел дошман күрмәк, киресенчә, аяр иде. Теге газетаны ачып укый башлады...

«Ошбу номер илә «Тәрҗеман»ның ярты еллыгы тәмам ула. Бу номерга алдыгымыз... вә дәһа, вә дәһа... Никадәр генә читенлекле вә көч бер эш исә дә, күпнең файдасы өмет ителгән хезмәттән...» Ахырына кадәр инде болай укыр... «Мин булсам да, сез булсагыз да, бер фәкыйрь, бер байгуш күрсәк, җанымыз авырып, кайгы хасил булыр. Бер хаста-авыру, хәлсез күрсәк, ярдәм бирергә бер әмәл вә чара үгрәтмәк морад идәрсез. Я үлем түшәгендә яткан бер кеше күрсәк, күземезгә – яшь, күңелемезгә мәрхәмәт килер, дәхи авыруга дучар булган хайван күрсәк, ачынып ах-вах йдәмез дә, бер түгел, биш түгел, меңнәрчә дин вә күңел кардәшләремезнең төрле авыру-газапка дучар улып, наданлык вә һөнәрсезлек кеби ике олуг вә мәрхәмәтсез дошманның кулына төшеп җан биргәнен күрмәеп, җаныбыз тоймаеп, күңелемез агламаеп, гакылымыз чаралар күрмәеп тордыгымыз күп язык вә хәйран калырлык түгелмедер». Шул җирдә Хисаметдин мелла кайгы-хәсрәткә чумып туктады вә күзләренә яшь килде. Бер-ике фикердән соңра укуын дәвам итеп: «Әйе, никадәр гаҗәптер ки, бер адәмнең хәленә мәрхәмәт итәрбез дә, бер миллион адәмгә – бер милләткә мәрхәмәтебез юктыр»... Бу җирдә үз-үзене тота алмаеп, мелла еламага башлады вә укымага тәкате калмаеп, бары тик: «Афәрин, Исмәгыйль кардәшем», – дигән сүзләрне генә әйтә алды.

Болай ачы борчылуын, елавын ишетеп, анасы бүлмәгә керде.

– Нихәл, улым?

Хисаметдин үзен елаудан тыеп: «Аначыгым, бер нәрсә юк, атамны ядыма алдым, кайгыландым», – дип җавапланды.

Хәлбуки, укучыларыбыз! Ул атасыны һич ядына алмады. Русиядә торучы ун миллион ислам кардәшләрене ядына алды. Атасы нигә хаҗәт. Ул инде вафат, Аллаһ җәннәт бирсен. Әмма ун миллион мөселман тере калды. Аурупадан башка – госманлылар вә мисырлылар вә һиндлеләр безнең наданлык вә ваемсызлыктан көләләр, ни аяныч! Әмма мәгълүматлы улмак өчен нәрсә кирәк? Укуны сөю кирәк, дип фикерләнә-фикерләнә, Хиса-

метдин мелла янә бүлмәсендә йөренә башлады. Чыланган «Тәрҗеман»ны исә өстәлгә ташлады.

II

Җомга намазыны укыдыктан соңра, Хисаметдин мелла, атыны чанага җигеп, кайбер кирәк нәрсәләр алмак өчен, шәһәргә юлланды.

«Н»дан губернатор утырган шәһәргә бары ике-өч сәгатьлек юлдыр, ләкин бару юлы бик кыен иде: кырда юл утырмыйча, кар бераз яумыш иде. Фәкать ачык туфраклы җирләр дә бар, мондый вакытларда арба илә чыксаң, көпчәк кай чакта карга кереп әйләнмидер, чана илә китсәң, карсыз җирләрдән кичмәк кыен була; вәлхасыйль-кыскасы, мондый вакытта татарча: «Ни арба, ни чана», – диерләр.

Юлында туры килгән бер тауга менеп барганда, арттан ике ат җигелгән бер арба килеп җитте.

– Бу кем алда? – дип сорады арбада утырып баручы яшь әфәнде ат куучысыннан.

– Бу – тап шул Хисаметдин мелла, кайсысыны мин сезгә бик галим диеп сөйләгән идем. Истанбулда укымыш. Безнең муллаларга авыз ачарга да бирми.

Яшь әфәнде күптән бу кеби кеше илә таныш булуны теләр иде. Ничә мәртәбә Хисаметдин мелла хакында гаҗәеп сүзләр ишетмеш иде. Шуңа күрә яшь әфәнде, куучыга арбаны чана илә тигезләргә боерып, меллага эндәшеп, сүзен болай башлады:

– Шәһәргә моннан ничә чакрым булыр, әфәндем?

– Унике, унбиш булыр.

– Юл бик начар; кай җирле сез, әфәндем? – сорады яшь әфәнде.

– Нун авылыннанмын. Сез яхшы иткәнсез, әфәндем, арба җиккәнсез, мин хата иттем, чанада бик авыр.

– Хөкүмәт эше булмаса иде, мин бу вакыт һич юлга чыкмас идем.

– Нинди хөкүмәт эше, әфәндем? – дип сорады мелла.

– Гимназия хөкүмәте. Безнең кагыйдә вә кануннарымыз шундый ки, вакытына килергә кирәк.

– Канунга буйсынган адәм рәхәт булыр. Бу юлны зәхмәттәй санасак, һичбер эшкә ярамамыз, – диде Хисаметдин мелла.

Бәс шәһәргә җиткәнчегә кадәр яшьләр сөйләшеп килеп юлны кыскарттылар. Бу сөйләшүдән яшь әфәнденең гимназия укучысы икәнлеге аңлашылды. Вә бу ике яшь юлчы, әңгәмәдәш булып бара торгач, бер-берсене бик яратыштылар. Хәтта ки Хисаметдин мелла гимназистны шәһәрдә барып күрергә сүз биреп аерылды. Гимназист дигәнебез бу губернадагы бәкләрдән Әбүзәр Дәүләтгилдиев исемле бәк иде. Әмма без Хисаметдин мелла артыннан китик әле.

Ул шәһәрдә постоялый дворга, ягъни гавам мөсафирханәсенә төште. Бу мөсафирханә килүчеләр өчен зур бер өйдән вә бер янә артта кечкенә өйдән гыйбарәт булып, хуҗасы Габбас әфәнде Биктимер углы бер сәүдәгәр иде.

Мөсафирханә йорты гаять зур вә мәйдан иде. Бу ханәдә тору өчен хакы бераз артык алынса да, ханәнең, аш вә йимәкнең ару-чисталыгы яхшы вә баерак кешеләрне җәлеп итәр иде. Атны сарай астында җирләштергән заманда мелланың күзенә гүзәл бер күренеш туры килде: йорт буенча бакчадан арттагы өйгә бер кыз узып бара!

Кыз урта буйлы, башында яхшы Казан калфагы киелмеш, өстендәге күк йон камзулы нәзек вә зифа буена яхшы ярашып тора. Муенында саф көмеш монетлар киелгән. Аягында тамбурлы читек-башмак, чәче вә күзләре, вә кашлары ялтыравык кара, йөзе нурлы, кызгылт ак, борыны кечкенә вә гүзәл. Азбарда беркем дә юк дип белеп, шәлене иңенә салып үтеп барганда, мелланың күзләре аңсыздан бу матурга төшеп зәвыкләнделәр. Бу нәзек бил вә гүзәл кыз мелланың күзенә тәмамән күренде.

Бу кыз мөсафирханә хуҗасы кызы гүзәл вә күркәм Хәнифә исемле иде. Мондый чибәр итеп Аллаһ яратса да ярата икән! Бу нечкә билне тамаша идәрәк, мелламыз хәйран калды, тормыш мәшәкатьләрен онытып, үз-үзене онытты. Өйгә якынлашканда кыз, сарай тарафына багып вә бердән мелланы күреп, оялдыгыннан көлде вә тиз үк шәл илә капланды, әмма бу көлешендә кып-кызыл иреннәре, вак энҗе тешләре мелланың күзеннән качмады. Хәнифә туташ өйгә кердектән соңра, мелла акылыны туплап: «Мин ни иттем, нәфесемә буйсынып кызга бактым, тәүбә-тәүбә», – дип фикер йөртте. Соңрак мелла шәһәргә чыгып, өй-йорт кирәкләрене алып вә башка эшләрне бетереп, янә мөсафирханәгә кайтты. Күрде ки, диваннар вә өстәлләрдә бик күп халык: сәүдәгәр вә гавам кешеләре утырмыш. Кайберәүләре исәп-хисап илә мәшгульдер. Мелла үзенә чәй китертеп өстәл янына утырды. Анда утырганнарның кайберләре мелла илә сөйләшүгә керештеләр.

Мөсафирлар утырган бу зур һәм киң бүлмә илә янәшә бер кечкенә бүлмә бар иде. Мөсафирлар бүлмәсе илә бу бүлмәнең арасы калын977 тактадан гыйбарәт иде, бу кечкенә бүлмәгә шулай ук арткы өйдән ишек бар иде. Арткы өй алдагы зур өй белән тоташ иде. Мелла мөсафирханәгә кергән вакытта Хәнифә туташ әлеге кечкенә бүлмәдә оек бәйләп утыра иде. Мелланың кергәнен белеп, вә янә бер күрмәк теләп, Хәнифә туташ, эшене куеп, өстәл эченнән кечкенә пычак чыгарды вә ике такта арасы табып, пычак илә шпалерны акрын һәм сиздермичә яра башлады. Бер-ике минуттан соң морадына иреште. Үз бүлмәсеннән мөсафирлар бүлмәсенә бер ярык ясады вә шул ярыктан егет мелланы бакмак илә хушланыр иде. Шул рәвешчә, татар җырында бик дөрес әйтелгән икән:

Ак эшләпә мамыктан, кызлар карый ярыктан,

Карамас иде ярыктан, бер күрергә зарыккан.

Һай бу йорттагы көтмәгәндә очрашу! Кыз егетләргә бик бакмыйдыр иде. Әмма йорттагы очрашу шпалерлар ярмага кызны мәҗбүр итте.

Гаҗәеп икенче туры килү: бу да мелламыз тугры ярыкка каршы утырмыш иде. Кыскасы, Хәнифә туташ тулы ләззәт илә ләззәтләнер, әмма теге бүлмәдә утырган җәмгыять, бу эштән хәбәрдар булмыйча, мелла илә сөйләшеп утырырлар иде. Мелладан шәригать мәсьәләләрен сорарлар иде, чөнки Хисаметдин мелла башка муллалар кебек киртек-миртек җавапланмас иде. Тугры вә хакыйкать җавап бирер иде. Мәсәлән, халыктан бересе хатыннар алмак турында сораштыргач, ул диде:

«Ислам шәригате икедән дүрткә кадәр хатын алмага рөхсәт бирсә дә, ләкин өйләнмәс борын үз хәлеңә карарга кирәк: ике хатын асрамага синең милкең бармы? Хатыннар хакында гаделлегең вә барчасына тигез дәрәҗәдә мәхәббәтең булырмы? Милкең вә гаделлегең булмыйча, ике хатын алсаң, хокукларыны бирмәсәң, гөнаһлы буласың».

Күзәтү эшендә булган Хәнифә туташ мелланың бу сүзләренә ишетеп бик разый-шат булды вә үз җенесе булган хатыннар хакында да мәгълүмат хасил итмәк өчен дикъкатене арттырып, колакларыны мөсафирлар бүлмәсенә салды. Хәнифә туташ үзе дә укыган кыз иде. Сөйләшеп утыру исә мелла ястү намазыны укырга керешкәнче дәвам итте.

III

«Н» авылына кайтабыз, хөрмәтле укучыларым. «Н» авылының өйләре кечкенә вә саламнан вә кайберләре агач тактасы илә ябылган булуны язган идек. Әмма шулай булса да, авылның аргы очында яхшы, бер йорт бар. Ул зур йорт таштан салынган булып, ике катлы вә башы тимер илә ябылмыштыр. Бу өй Гали бай Җаватовныкы иде. Гали бай бу губернада бөек һәм мәшһүр сәүдәгәр иде. Шәһәрдә агач склады вә «Нун»да йон юмак мастерское бар иде. Мәскәү сәүдәгәрләре вә фабрикчылар илә эш йөртүче кеше иде. Һәм авылда Гали байдан сүзе үтемле кеше юк иде: ул ни диде, шул булды, һичбер кеше аңа каршы торырга батырчылык итмәс иде. Ярты чакрым ераклыктан «нун»лылар Гали байга сәлам бирер иде.

Чөнки гавам халкы яхшы белер ки, байны олыласаң, аның кулында булган җирне вакытлы файдалануга (арендага) очсызрак хак илә алмак мөмкин.

Габбас аганың мөсафирханәсендә булуыбыздан өч көн соң кичке аш вакыты. Гали бай гаиләсе илә чәй эчәргә утырган вакытта гына, Бикбулат мулла әфәнде килеп керде.

– Әйдәгез, хуш киләсез, хәзрәт, чәй вакытына туры килдегез, яхшылык теләп киләсез! – диде Гали бай. Хәзрәт утырды.

– Эш илән килдем, егерме бишлек акчамны алыштырырмысыз?

– Яхшы, алыштырырмыз. Берәр чынаяк чәй эчеп алыйк. Бикбулат мулла Гали байга кияү буладыр, мулланың хатыны Гали байның кардәше иде.

– Әй син, Сибгатулла, сине өйләндермәк кирәк! – диде сүз арасында мулла Гали байның углына.

– Гаскәрлектән котылдың, дәүләтегез күп, атаң-анаң карт.

– Тап кыз! – дип җавап бирде Сибгатулла әфәнде.

– Сезгә авыл кызы ярамас, сезгә шәһәрнеке кирәк.

– Шәһәрдә Габбас аганың кызын бик мактыйлар, – дип сүзгә кереште Гали байның сәүдә эшләрендә баш хезмәтчесе. – Укыган, бик күркәм вә уңган дип сөйлиләр.

– Кызны күп кеше мактыйдыр, – диде Гали бай.

– Сезгә тиз бирерләр, яхшылап сорарга да өлгермәссез, мондый дәүләтле кияүгә бирү бөек бәхеттер, – диде Бикбулат мулла әфәнде.

Өйләнү мәсьәләсеннән соң, сүз гайбәтләргә күчте. Бикбулат мулланы укымаган дисәк, ялгышкан булырбыз, чөнки «гакает»лар күрмеш; галим дисәк, шулай ук хата булыр, чөнки галим кеше гайбәтләрдән качадыр. Ә Бикбулат мулла хәзер дә чәй янында: улсы яман, бусы ялганчы, ул бересе хәерсез, угыры дип сөйләнә-сөйләнә, үзеннән яхшыны тапмаеп, теле Хисаметдин меллага да тиде:

– Белермесез, – диде Бикбулат мулла, – наданыбыз никадәр ярамаслык эш эшләгән шәһәрдә?

– Ни ул ярамаслык? – сорады Гали бай.

– Безнең авылның ятим Мохтар теләнчене мирза Дәүләтгилдиев ярдәме белән полициягә яптырган. Үзе әйтер, Исламны сөям, әмма үзе ятимнәрнең ризыкларын кисәр. Бу-кәфер эшеннәндер, мин аны күрим генә, харап итәрмен. Аның бу эше-шәригатькә каршы килә торган эш. Монда дәлил таба алмас, ул сүз түгел, Ислам дошманыдыр.

– Ярый, син аны җиңеп атырсың, бездә мәҗлес булыр, кара, бәхәсләреңне яхшы хәзерлә, – диде Гали бай.

Гали бай үзе дә Хисаметдин мелланың җиңелеп калуын телидер иде. Чөнки Гали бай тыштан берни күрсәтмәсә дә, эчендә Хисаметдин меллага ачу тотып, сөймәс иде. Чөнки Хисаметдин башка муллалар кебек Гали байны олугламас иде. Мелла Хисаметдин пакь исламиятне сәүдегеннән вә саф исламиятнең таләбен үтәүче буларак, барча исламнар тигез булуына инанып, аның карашында бай вә фәкыйрь тигез иде. Шуңа күрә Хисаметдин мелланың бай исламга мәхәббәте фәкыйрь исламга мәхәббәтеннән артык түгел иде. Гали байны шулкадәр сөяр иде, никадәр фәкыйрь исламны сөяр. Гали байга исә бу мөнәсәбәт бик тә капма-каршы иде, чөнки укымышлыларыннан, муллаларыннан башлап гавамнарынача авылның барлык халкы аны олылап сөяр икән, фәкать бер Хисаметдин мелла аны бик олугламас вә туры килгәндә үзен Гали байга тигез кебек тотар.

Һәрхәлдә, икенче көн бай мәҗлесендә Хисаметдин мелла да булды, вә бай анасының үлүенә кырык көн үткәнгә Бикбулат мулла Коръән Кәримнән бераз укыгач, табынга чәй китерелде.

Бикбулат мулла түрдә утырган. Аннан соң шәкертләре җирле җиренчә җирләшкәннәр. Хисаметдин мелла каршында-самавыр янында Сибгатулла әфәнде кечкенә татар чашкаларына чәй ясау илә мәшгуль.

Сибгатулла әфәнде Хисаметдин мелла кебек яшь булса да, күркәмлеге юк иде.

Җәмәгать ул-бу турында сөйләшеп утырганда Бикбулат мулла күбрәк укыган бер шәкертенә күзе илә ишарә итте.

Шуннан соң әлеге шәкерт, Хисаметдин меллага мөрәҗәгать итеп, сүз башлады:

– Шәһәрдә яңа хәбәрләр юкмы?

Бу сорауны ишетеп, мәҗлестәгеләр, аеруча Бикбулат мулла белән Гали бай угылы, бу шәкерт Хисаметдинны харап итәр, дип эчләреннән сөенделәр.

Ләкин Хисаметдин, боларның эчке ниятләрен белмичә, «дикъкать итәрлек нәрсә юк», дип кенә җавап бирде. Теге шәкерт, сүзен дәвам итеп, болай диде:

– Авылыбызда сөйлиләр ки, ятим Мохтарны ябып куйганнар.

– Әйе, тугры хәбәр, – җавап бирде Хисаметдин мелла.

– Бәлки, тугры, әмма аның ябылуына сезнең сәбәпче булуыгызга без һич ышанмыйбыз.

– Әлбәттә, мелла Хисаметдин яптырмас, чөнки ул Исламны сөюче кеше; ятим теләнчеләрнең сәдака-ризыгын кисү исә наданлыктан килер вә кәфер эшедер, – дип бәян итте Бикбулат мулла вә шәкертләренә янә күз кысты. Укымышлы саналган шәкертләр бу ишарәне күреп меллага кырмавык кебек ябыштылар:

– Юк, дөрестән дә, сез Мохтарны пулисәгә яптыргансыз. Бу – бик зур наданлыктыр, бу – кәфер эшедер.

Бу кычкырышуны ишетеп, мәҗлестә булганнарның кайберләре, чәйләрене онытып, Бикбулат мулланың шәкертләреннән хәйран калдылар.

Хисаметдин шәкертләр белән болай никадәрле генә сөйләшәсе килмәсә дә, кәфер эше дигән сүзләренә чыдый алмыйча, болай җавап бирде:

– Монда ни бар, әфәнделәр? Мин яптырганлыгымны һич тә инкяр итмимен, мин яптырдым.

Бу җавапны ишетер-ишетмәс, Бикбулат мулла үзе һәм шәкертләре кычкырышып: «Бакың, бакың, яман эшне үзе дә инкяр итми. Һай залим! Ә үзе Исламны сөям дигән була тагы, бу яман эш исламияткә каршы ич», – диделәр.

– Исламны сөйгәнлегемнән пулисиягә алдырдым. Китапта боермыш ки, соранмак – фәкыйрьлеккә сәбәптер, – җавап бирде Хисаметдин.

– Китап кем, сән кем! – кычкырыштылар шәкертләр.

Хисаметдин мелла боларның хайванлыгыны күреп:

– Мин сезнең белән сөйләшәсем килми, ябышмагыз миңа, – диде.

Шул чак Гали байлар, Бикбулат муллалар, Хисаметдин сөйләшүдән качып җиңелде дип, янә бик шатландылар. Фәкать шәкерт саналганнар тагы да катырак ябыштылар: А! Сән сөйләшмәктән качасың. Кайсы китапта әйткән, соранмак фәкыйрьлеккә сәбәп дип? Сәнең китабындамы?

– «Шәрхе ширгател-ислам» китабында язылган: хәзрәте Расүл саллаллаһе галәйһи вә сәллам хәзрәтләре димешләрдер ки, үзе өчен бер кемсә сорамактан бер капу ачса, Аллаһ хәзрәтләре ачар аңа фәкыйрьлектән җитмеш капу. Мин исә Ислам кардәшемнең фәкыйрь булуын һич теләмим. Күрәсез, хәзрәте Расүл үзе дә кешедән соранмакны сөймәгән, – дип куйды Хисаметдин мелла.

Ләкин шәкерт саналганнар, бу җавапны ишетмичә, һаман кычкыруда иделәр. Вә соранмак-теләнмәкне гакылларына ярашлы күреп (чөнки тормышлары шул дәрәҗәгә якын иде ки, үзләре дә соранмактан кире тормаслар иде), хәдисне инкяр итәргә калкыттылар.

– Юк, юк, шундый хәдис булмас, син надан, гафил. Әйт хәдисне гарәпчә! – кычкырдылар шәкертләр.

– Мин әйтермен, әгәр бәхәсләшәсез икән, әдәп белән сөйләшегез, яисә дәлилләп сөйләгез, монда әдәпсезлек, бәхәс җире түгел.

Шәкерт саналганнар, барыбер бернәрсә дә аңламыйча: «Әйт, гарәпчәсен әйт», – диделәр.

Хисаметдин мелла хәдисне гарәпчә әйтәсе килмәде. Ләкин кунаклардан берсе: «Әйт инде, мелла, үзләренә», – диюенә күрә әйтте.

– Гарәпчәсе безгә кирәк-зарур түгел, мәгънәсен аңламак өчен төркичә дә җитәдер. Теләсәгез, гарәпчәсе болай, – дип, гарәпчә әйтеп күрсәтте.

Җиңүче булып чыгарга теләгәннәр, бу хәдисне ишетеп вә мелла Хисаметдин илә сүз көрәштерергә тәкатьләре җитешмәгәнлекне аңлап, тынып калырга мәҗбүр булдылар. Хисаметдин мелла исә бераз кайгылы булды. Кайгыруына сәбәп шул иде ки, Бикбулат ише муллалар мөдәррислек дәгъва итәләр! Моның кеби мөдәррисләрдә гомерне әрәмгә уздырып, шәкертлек итеп, кычкырышмактан гайре бер нәрсәгә дә өйрәнеп булмыйдыр. Көенечле булуына сәбәп: болар кеби шәкертләр бәхәснең нидән гыйбарәт икәнлеген белмиләр. Болар белмәсләр ки, бәхәстән морад кычкырышмак түгел. Бәхәстә дошманлык, мәхәббәт вә һәрбер хосусый мөнәсәбәт мөмкин булмаган бер эштер. Хәтта иң олуг дошманың бәхәстә хакыйкатьне исбат итсә, аның фикеренә кушылырга кирәклекне бу шәкерт саналганнар белмиләр иде. Әмма никадәрле кайгылы булса да, каршы яктагыларның авызларын каплавыннан Хисаметдин күңелендә бер юаныч тапты.

*(Дәвамы киләсе саннарда)*